# Фәнни Татарстан

ТАТАРСТАН ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
Г. ИБРАҺИМОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ

2023 3 (39)

ISSN 2499-9741
КАЗАН

***Журнал «2014–2022 елларга Татарстан Республикасында ТР дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү», «2023–2030 елларга Татарстан Республикасында ТР дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программалары кысаларында 2014 елдан кварталга бер сан нәшер ителә***

*Массакүләм мәгълүмат чарасын Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәт тарафыннан регистрацияләү турындагы таныклык ПИ № ФС77-65242 01.04.2016*

► **ЖУРНАЛНЫ ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ**
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ

► **ИДАРӘ:**
МИҢНУЛЛИН К.М., филология фәннәре докторы, профессор, идарә җитәкчесе (Казан)
АЛИШИНА Х.Ч., филология фәннәре докторы, профессор (Төмән)
АРСЛАНОВ М.Г., сәнгать фәннәре докторы, профессор (Казан)
БАҺАВЕТДИНОВ Ф.Н., хокук фәннәре докторы, профессор (Казан)
ВӘЛИЕВ Р.И., тарих фәннәре кандидаты, Татарстанның халык шагыйре (Казан)
ГЫЙЛӘҖЕВ И.А., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ЗАҺИДУЛЛИНА Д.Ф., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
ҖАМАЛЕТДИНОВ Р.Р., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
КЕРИМОВ И.А., филология фәннәре докторы, профессор (Симферополь)
МИҢНЕГУЛОВ Х.Й., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
МӨХӘММӘТШИН Р.М., сәяси фәннәр докторы, профессор (Казан)
НАСИПОВ И.С., филология фәннәре докторы, профессор (Уфа)
ӨНӘР МОСТАФА, фән докторы, профессор (Измир)
САЛӘХОВ М.Х., физика-математика фәннәре докторы, профессор (Казан)
САЛИХОВ Р.Р., тарих фәннәре докторы (Казан)
СИБГАТУЛЛИНА Ә.Т., филология фәннәре докторы, профессор (Мәскәү)
СӨЛӘЙМАНОВ Җ.Ш., техник фәннәр докторы, профессор (Казан)
ТӘСИН ҖӘМИЛ, Бабеш-Больяй университетының Тюркология һәм Үзәк Азияне өйрәнү институты директоры (Клуж-Напока, Румыния)
ТИМЕРХАНОВ А.Ә., филология фәннәре докторы (Казан)
ХУҖИН Ф.Ш., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ШӘЙДУЛЛИН Р.В., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ШАМИЛ-ОГЛЫ ЮЛАЙ, тарих фәннәре докторы, профессор (Астана)

► **БАШ РЕДАКТОР**
Ким Мөгаллим улы МИҢНУЛЛИН

► **БАШ РЕДАКТОР УРЫНБАСАРЛАРЫ:**
МӨХӘММӘТҖАНОВА Л.Х., ШӘРИПОВА А.С. (җаваплы секретарь)

► **РЕДАКТОРЛАР:**
ЗАҺИДУЛЛИН И.К. (тарих), СОЛТАНОВА Р.Р. (сәнгать), МИРХӘЕВ Р.Ф. (тел белеме), ГАРИПОВА Л.Ш. (әдәбият), ЯМАЛТДИНОВ И.И. (фольклор)

► **ЧЫГАРЫЛЫШ РЕДАКТОРЫ:**
ГАЛИУЛЛИНА Д.Р.

► **ГАМӘЛИ ХЕЗМӘТКӘРЛӘР:**
ШӘРИФУЛЛИНА Л.Г., АБДУЛЛИНА Н.Т., СӘЛАХОВА Ә.Ф., ЧУГУНОВ А.С.

**БУ САНДА**

## ТЕЛ БЕЛЕМЕ

*Миңнуллин Б.К.* XX йөз башы татар газета текстларының грамматик структурасы: үткән заман сыйфат фигыль формаларының кулланылыш үзенчәлекләре . . . . . . . . . . . . 7

*Мирхәев Р.Ф.* XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы татар мәгърифәтчелек прозасы әсәрләрендә *-ды* кушымчалы билгеле (категорик) үткән заман хикәя фигыльләрнең стилистик кулланылыш үзенчәлекләре . . . . . . . . . . . . . . . . . 13

*Сәфәров Р.Т.* Берничә йөкләтү юнәлеше кушымчасы белән килгән фигыльләрнең сүзлектә теркәлеше . . . . . . . . . . . . . . . . 21

*Галимова О.Н.* Терминологиянең үсеш күрсәткече буларак татар телле «Википедия» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 26

*Хөсәинова А.Я.* Татар телендә тел алды /ʒ/ сибилянты һәм тел уртасы /j/ сонантының үзара бәйләнеше. . . . . . . . . . 32

*Яруллина Л.И.* С. Рахманколыйның А.М. Горький һәм Ф.И. Шаляпин музее фондында саклана торган «Татарча-русча лөгать» (1913) сүзлеге . . . . . . . . . . . . . . . . . . 37

## ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕ

*Алиева Ә.Х.* Замандашлары иҗатында шагыйрь Габделмәннан Мөслими образы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 44

*Закирова И.Г., Даутова С.Б.* Нурлан Санжарның «Көтелмәгән кунак – Җүчи» романы: тарихи образлар һәм аларның заманча интерпретациясе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 53

*Миңнуллина Ф.Х.* Сугыштан соңгы еллар (1945–1950) татар драматургиясе: заман героен эзләү *(Т. Гыйззәт, М. Әмир, Р. Ишморат әсәрләре мисалында)* . . . . . 59

*Ганиева А.Ф.* А. Хәлимнең «Хунвэйбин» романында милләт образы: имагологик аспект . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 67

## ХАЛЫК ИҖАТЫ

*Мөхәммәтҗанова Л.Х.* Татарларның туй йоласы комплексында җырлар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 73

*Хөсәенова Г.Р.* Татарстан Республикасы Милли китапханәсендә саклана торган дастаннарга гомуми күзәтү. . . . . . . . . . . . . 84

## ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕ

*Хәйруллин Г.Т.* Нәбиҗан Турсун татарларның Көнчыгыш Төркестан республикасын төзү өчен көрәшүе турында (1944–1949) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 94

*Умудлу И.Б.* Идел-Урал буе татар морзалары Терегуловлар нәселе һәм Азәрбайҗан . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 105

*Зиннәтуллина А.Ә.* Мәрьям Акчурина-Солтанова һәм «Уфа мөселман ханымнар җәмгыяте» . . . . . . . . . . . . . 113

**МИЛЛИ МӘГАРИФ**

*Шәкүрова М.М.* XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы галимнәренең хезмәтләрендә рус һәм татар телләренә өйрәтүнең фәнни нигезләре . . . . . . . . . . . . . . . . . 121

**ТӨРКИ ХАЛЫКЛАР ФӘНЕ**

*Аманбаева З.С.* Башкорт халкының «Урал батыр» эпосында дуализм күренеше . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 128

**СӘНГАТЬ**

*Шкляева Л.М.* Ю.В. Павловның хәзерге чор иҗатында традицион лаклы миниатюра сәнгатенең үсеше . . . . . . . . . . . 133

*Петрова Л.Р.* Татар милли балет спектакле: сәхнә чишелешен эзләү мәсьәләсенә карата. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 137

*Җәләлиева А.К.* Хәмит Латыйпов – милли традицияләрне үстерүче . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 144

**ФӘННИ ЯДКЯРЛӘР**

*Әхмәдиев Ш.* «Тигезсезләр» пьесасы . . . . . . . . . . . . . . . . . . 149

**ШӘХЕСЛӘРЕБЕЗ**

*Кадирова Э.Х.* Галимәнең юбилее уңаеннан *(Резеда Рәхимовага – 90 яшь)* . . . . . . . . . . . . . . . . . 153

**ЯҢА КИТАПЛАР**

*Галиева Л.Ш.* Гаяз Исхакый көндәлекләре *(«Исхакый Г. Көндәлекләр: 3 китапта. 1 нче китап: 1919–1920» китабына рецензия)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 159

*Тулузакова Г.П.* «Шаляпин в Казани. Живопись, графика, скульптура. Каталог» китабына бәяләмә. . . . . . . . . . . . . . . . . 162

*Мортазина Л.Р.* Төрек галимнәре хезмәтләрендә татар хатын-кызлары мәсьәләсе *(Адилхан Адилоглуның «Ceditçilik Dönemi Kazan Tatar Edebiyatinda Kadin Hak ve Hürriyetleri Meselesi» китабына бәяләмә)* . . . . . . . . . . . . . 165

**ФӘННИ-ИҖТИМАГЫЙ ТОРМЫШЫБЫЗДАН**

**В НОМЕРЕ**

## ЯЗЫКОЗНАНИЕ

*Миннуллин Б.К.* Грамматическая структура татарского газетного текста начала XX века: особенности употребления форм причастия прошедшего времени . . . . . . . . . . . . . . . . . 7

*Мирхаев Р.Ф.* Особенности стилистического употребления глаголов определенного (категорического) прошедшего времени изъявительного наклонения с аффиксом *-ды* в произведениях татарской просветительской прозы конца XIX – начала XX века. 13

*Сафаров Р.Т.* Фиксация татарских глаголов с несколькими аффиксами принудительности в словарях . . . . . . . . . . . . . . . . 21

*Галимова О.Н.* «Википедия» на татарском языке как показатель развития терминосистемы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 26

*Хусаинова А.Я.* Соотношение переднеязычного сибилянта /ʒ/ и среднеязычного /j/ сонанта в татарском языке . . . . . . . . . . 32

*Яруллина Л.И.* С. Татарско-русский словарь Султана Рахманкулова в фондах Музея А.М. Горького и Ф.И. Шаляпина . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 37

## ЛИТЕРАТУРОВЕДЕНИЕ

*Алеева А.Х.* Образ поэта Г. Муслимова в творчестве современников . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 44

*Закирова И.Г., Даутова С.Б.* Роман Нурлана Санжара «Неожиданный гость – Джучи»: исторические образы и их современная интерпретация . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 53

*Миннуллина Ф.Х.* Татарская драматургия в послевоенные годы (1945–1950) *(на примере произведений Т. Гиззата, М. Амира, Р. Ишмурата)*. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 59

*Ганиева А.Ф.* Образ нации в романе А. Халима «Хунвэйбин»: имагологический аспект . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 67

## НАРОДНОЕ ТВОРЧЕСТВО

*Мухаметзянова Л.Х.* Песни в комплексе татарского свадебного обряда . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 73

*Хусайнова Г.Р.* Обзор татарских дастанов, хранящихся в Национальной библиотеке Республики Татарстан . . . . . . . . 84

## СТРАНИЦЫ ИСТОРИИ

*Хайруллин Г.Т.* Набижан Турсун о борьбе татар за создание Восточно-Туркестанской республики (1944–1949) . . . . . . . . . 94

*Умудлу И.Б.* Волго-Уральский татарский дворянский род Терегуловых и Азербайджан. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 105

*Зиннатуллина А.А.* Марьям Акчурина-Султанова и Уфимское мусульманское дамское общество . . . . . . . . . . 113

## НАЦИОНАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ

*Шакурова М.М.* Научные основы преподавания русского и татарского языков в трудах ученых второй половины XIX и первой четверти XX века. . . . . . . . . . 121

## НАУКА ТЮРКСКИХ НАРОДОВ

*Аманбаева З.С.* Дуалистическое мировоззрение в башкирском эпосе «Урал-батыр» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 128

## ИСКУССТВО

*Шкляева Л.М.* Художественная интерпретация традиционного искусства лаковой миниатюры в творчестве Ю.В. Павлова на современном этапе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 133

*Петрова Л.Р.* Татарский национальный балетный спектакль: к вопросу о поиске сценического решения . . . . . . . . . . . . . 137

*Залялеева А.К.* Хамит Латыпов – популяризатор народных традиций . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 144

## НАУЧНОЕ НАСЛЕДИЕ

*Ахмадиев Ш.* Пьеса Фатиха Амирхана «Неравные» . . . . . . . 149

## ПЕРСОНАЛИИ

*Кадирова Э.Х.* К юбилею ученого *(Резеде Рахимовой – 90 лет)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 153

## НОВЫЕ КНИГИ

*Галиева Л.Ш.* Дневники Гаяза Исхаки *(рецензия на книгу «Исхакый Г. Көндәлекләр: 3 китапта. 1 нче китап: 1919–1920»)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 159

*Тулузакова Г.П.* Рецензия на книгу «Шаляпин в Казани. Живопись, графика, скульптура. Каталог» . . . . . . . . . . . . . 162

*Муртазина Л.Р.* Проблемы прав и свобод татарских женщин в трудах турецких ученых *(рецензия на книгу Адилхана Адилоглу «Ceditçilik Dönemi Kazan Tatar Edebiyatinda Kadin Hak ve Hürriyetleri Meselesi»)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 165

## НАУЧНАЯ ЖИЗНЬ

УДК 811.512.145

***Б.К. Миңнуллин***

# ХХ ЙӨЗ БАШЫ ТАТАР ГАЗЕТА ТЕКСТЛАРЫНЫҢ ГРАММАТИК СТРУКТУРАСЫ: үткән заман сыйфат фигыль формаларының кулланылыш үзенчәлекләре

Статья посвящена разработке вопросов функционирования в текстах татароязычной арабографической периодической печати начала XX века одной из наиболее распространенных неличных форм глагола – причастия. Актуальность темы настоящей научной статьи обусловлена необходимостью исследования грамматических норм языка татароязычной арабографической периодической печати начала XX века, выполнявшей в рассматриваемый период, наряду с художественными произведениями, роль определенной платформы для функционирования старотатарского письменного литературного языка и его дальнейшего преобразования в национальный литературный язык. Благодаря результатам такого исследования формируется возможность прослеживания этапов функционирования форм причастий прошедшего времени в диахронии. В результате проведенного научного анализа нами выявлено, что в текстах исследованных газет, наряду с кыпчакским показателем причастия прошедшего времени на *-ğan,* соответствующего современному причастию татарского литературного языка на *-ган,* также зафиксировано функционирование ряда причастных форм, свойственных для огузских языков.

**Ключевые слова:** старотатарский литературный язык, татарская периодическая печать, язык газеты, грамматическая система, формы причастия прошедшего времени.

The article is devoted to the development of issues of functioning in the texts of the Tatar arabographic periodical press of the early XXth century of one of the most common non-personal forms of the verb – participle. The relevance of the topic of this article lies in the need to study the grammatical norms of the language of the Tatar periodical press of the early XXth century, which in the period under review served, like literary works, as a platform for the functioning of the old Tatar written literary language and its further transformation into a national literary language. As a result of such research, it is possible to trace the stages of functioning of past participle forms in diachrony. As a result of the conducted scientific analysis we have revealed that in the texts of the studied newspapers, along with the Kipchak indicator of the past participle on *-ğan,* corresponding to the modern participle of the Tatar literary language on *-ган,* the functioning of a number of participial forms characteristic of the Oguz languages is also recorded.

**Keywords:** old Tatar literary language, Tatar periodical press, newspaper language, grammatical system, past participle forms.

ХХ гасыр башы татар халкының үсешендә, милләт буларак формалашуында иң мөһим чорларның берсе булып санала. Беренче чиратта, бу әлеге чорда илебездә барлыкка килгән билгеле бер

иҗтимагый, сәяси һәм икътисади үзгәрешләр нәтиҗәсе булып тора. Татар халкының милли вакытлы матбугатының барлыкка килүе дә нәкъ менә әлеге үзгәрешләрнең бер нәтиҗәсе буларак кабул ителә. Шул ук вакытта, әйтелеп үткән үзгәрешләр өйрәнелә торган чорда иске татар әдәби телендә иҗат ителгән язма чыганакларның лексик һәм грамматик төзелешенә дә йогынты ясамый калмый. Мәсәлән, 1905–1917 елларда татар телендә гарәп графикасында басылып килгән вакытлы матбугат органнарының теле әле һаман да билгеле бер күләмдәге традицион гомумтөрки лексик һәм грамматик элементларның активлыгы белән характерлана: госманлы төрекчәсе аша кергән угыз компоненты белән катлауландырыла, зур күләмдәге гарәп һәм фарсы лексикасына нигезләнә, ләкин инде актив рәвештә татар гавами сөйләмә тел формалары һәм рус теле лексикасы белән баетыла башлый.

Әлеге фәнни мәкаләнең объекты булып XX гасыр башында чыгып килгән татар вакытлы матбугаты органнары, аерым алганда «Борһане тәрәккый» (1906–1911), «Вакыт» (1906–1918) һәм «Кояш» (1912–1918) газеталарының текстлары тора. Безнең фикеребезчә, нәкъ менә әлеге газета текстларына тукталуны фәнни тикшеренү нәтиҗәләренең объективлыгына уңай тәэсир итә торган шартларның берсе дип кабул итәргә мөмкин. Чөнки бу газеталарның һәрберсе 1905 елгы Беренче рус революциясеннән алып 1917 елгы Февраль революциясенә кадәрге чорда аз дигәндә биш ел дәвамында Россиянең татарлар күпләп яши торган һәм шул ук вакытта, идеологик, сәяси һәм лингвистик күзлектән чыгып караганда, күпмедер күләмдә аермалыкларга ия булган географик нокталарында, төгәлрәк әйткәндә, Әстерхан, Оренбург һәм Казан шәһәрләрендә чыгып килгән.

«Борһане тәрәккый», «Вакыт» һәм «Кояш» газеталары текстларында кулланылган үткән заман сыйфат фигыль формалары үз эченә кыпчак һәм угыз телләре өчен хас булган формаларны да алган күрсәткечләр төркеменнән гыйбарәт. Әлеге формалар арасында иң актив кулланылганы – кыпчак телләре өчен хас булган, аерым алганда, хәзерге татар әдәби телендә кулланыла торган *-ğan* кушымчалы үткән заман сыйфат фигыль. Моннан тыш газета текстларында угыз телләре өчен хас *-myš* кушымчалы үткән заман сыйфат фигыль, ә сирәгрәк *-an*, *-dyq* һәм *-maqda ulan (bulğan)* формалы сыйфат фигыльләрнең кулланылышы теркәлде. Тикшерелә торган газета текстларында *-ğan* кушымчалы үткән заман сыйфат фигыльнең кулланылышы аның хәзерге татар әдәби телендәге кулланылышыннан принципиаль дәрәҗәдә аерылмый, шуңа күрә безнең игътибарны күбрәк югарыда күрсәтелгән башка формалар җәлеп итә.

Әйтеп үтелгәнчә, *-myš* кушымчалы үткән заман сыйфат фигыль газета текстларында *-ğan* кушымчалы үткән заман сыйфат фигыль белән чагыштырганда сирәгрәк кулланыла. *-myš* формасының куллалыш ешлыгы «Борһане тәрәккый» газетасында иң югары күрсәткечкә ия булса, «Вакыт» газетасы текстларында әлеге форма регуляр

булмаган кулланышы белән аерылып тора. «Кояш» газетасында исә *-myš* кушымчалы үткән заман сыйфат фигыльнең кулланыш ешлыгы тикшерелгән газеталар арасында иң түбән күрсәткечкә ия. Шул ук вакытта тикшерелгән барлык газета текстларында да *-myš* кушымчалы үткән заман сыйфат фигыльнең кулланылу очраклары, әлеге форма кулланылган текстларда угыз телләренә, шул исәптән госманлы төрекчәсенә хас булган башка грамматик һәм лексик үзенчәлекләрнең актив рәвештә урын алуы белән ныгытыла. Иң элек әлеге факт *-myš* формасының көнбатыш угыз телләренең асыл үзенчәлекләрен тәшкил итә торган беренчел билгеләренә каравы белән аңлатыла [Грунина, 1991, с. 131].

*-myš* үткән заман сыйфат фигыль формасы хәзерге татар әдәби теленең грамматик системасы өчен хас күрсәткеч түгел, ә татар сөйләшләрендә исә ул чикләнгән кулланылышка ия [Юсупов, 2004, с. 111]. Шул ук вакытта, әлеге форманың XX гасырның беренче чирегенә кадәр төрки-татар һәм иске татар язма истәлекләрендә *-ğan* кушымчалы үткән заман сыйфат фигыль формасы белән параллель кулланылышта булуы мәгълүм [Татар әдәби..., 2017, б. 179, 744].

Тикшерелгән газета текстларында *-myš* кушымчалы үткән заман сыйфат фигыльнең заман мәгънәсе, *-an* һәм *-dyq* формаларыннан аермалы буларак, абсолют күрсәткечкә ия һәм эш-хәрәкәтнең затланышлы фигыль белдергән үтәлү вакытына бәйле түгел: *Orenburg okrugyndağy mäğärif mämurlary xäzer möselman mäktäblärenä 31 nče martda mäğärif ministry tarafyndan* ***tasdyjq qylynmyš*** *jaŋa pravilalarny kertmäk ilän mäšğüllär* [«Газеталардан», «Б.т.»[1], 1906, № 42]; *Iske tarixymyzğa ğaid ularaq rusča* ***jazylmyš*** *ni qadär äsär var isa cömläsenä tärcemä wä näšer itmäk lazemder* [«Болгар хәрабәләре...», «В.»[2], 1908, № 333]; *Bugen bu mäclesdä mözakäräjä* ***qunylmyš*** *mäktäb wä mädräsäläreŋ islaxy mäsäläse 20, 30 sänä qadär durmadan söjlände, jazyldy, fäqat bunlar häb käğydda, ğazätä sötünlärendä qaldy* [«Кырым идарә...», «К.»[3], 1916, № 928].

Атрибутив функциядә *-myš* формасы халәтне белдереп килгән сүзләргә карата аергыч функциясен үти: *Bijek Piter zamanynda Rusijä, Moskva ätrafyna tämamilä* ***cyjylmyš, nyğajmyš*** *ber xäldä ide* [«Полтава мөхарабәсе», «В.», 1909, № 488].

Югарыда китерелгән «Кояш» газетасыннан алынган мисалдан күренгәнчә, аның лексик һәм грамматик төзелеше башка мисалларда бирелгән текст өзекләреннән шактый аерылып тора. Аерым алганда, әлеге өзектә угыз телләре өчен, шул исәптән XX гасыр башы госманлы әдәби теленә хас булган лексик (*mözakärä* ‘фикер алышу, тикшерү’, *sänä* ‘ел’, *durmadan* ‘өзлексез’, *häb* ‘бөтен, барлык’, *käğyd* ‘кәгазь’, *ğazätä* ‘газета’, *sötün* ‘багана’, *para* ‘акча’ һ.б.)

---

[1] «Б.т.» – «Борһане тәрәккый» газетасы.

[2] «В.» – «Вакыт» газетасы.

[3] «К.» – «Кояш» газетасы.

һәм грамматик (*mözakärä**jä***, *mädräsälär**eŋ***, *dur**madan***, *čyqaryl**an*** һ.б.) күрсәткечләрнең активлыгы өйрәнелә торган чор татар язма әдәби теленең норма вариантлыгын булдыруга китерә торган күренешләрдән санала. Әлеге факт теге яки бу текстның лексик, грамматик һәм стилистик төзелеше формалашуда авторның телдә булган агымнарның кайсысына өстенлек бирүен ассызыклый.

*-myš* кушымчалы үткән заман сыйфат фигыльнең юклык формасы *-ma/-mä* кушымчасы ярдәмендә белдерелә. Әлеге форма газета текстларында сирәк очрый. Аның чагыштырмача югарырак активлыгы «Борһане тәрәкъкый» газетасы өчен хас: *Hičber xyjalğa **kilmämeš** Borhan Täräqyj gazetasy mäjdanğa čyqdy* [«Дәрел Әдәбдә...», «Б.т.», 1906, № 36].

«Борһане тәрәккый», «Вакыт» һәм «Кояш» газеталарында *-an* үткән заман сыйфат фигыль формасының очраклы кулланылышы күзәтелә. Ул кыпчак *-ğan* формасының угыз аналогы буларак билгеләнә [Грунина, 1991, с. 131] һәм, кайбер тюркологлар фикеренчә, *-ğan* формасының гадиләшкән варианты булып тора [Сравнительно-историческая..., 1988, с. 453]. *-an* формасы хәзерге татар әдәби теле һәм аның диалектлары өчен хас түгел. Әлеге форманың гомумән кыпчак телләре өчен хас булмавын исәпкә алганда, аның XX гасыр башы иске татар әдәби теленә, шул исәптән өйрәнелә торган чорга караган татар вакытлы матбугаты теленә килеп керүен госманлы әдәби теле йогынтысы белән аңлатырга мөмкин. *-an* формасы эзлекле рәвештә грамматик системаның төш элементы буларак бары тик «Борһане тәрәккый» газетасы текстларында гына очрый. Бу форманың төп үзенчәлекләреннән берсе – аның *ul*, *bul* фигыльләре белән актив кулланылышы.

Газета текстлары күрсәткәнчә, күпчелек очракта әлеге форма предмет яки затның конкрет вакыт аралыгына бәйле булмаган даими билгесен белдерә: *Adäm balasy här waqyt üzeneŋ xäjätene, wä xäjäteneŋ ruxy **ulan** xoquq mädänijäsene üze saqlamaq öčen tyryšmağa buryčlydyr* [«Хәят – тереклек саклау», «Б.т.», 1906, № 35]; *Uqučy äfändelärne ğaibanä mäsrur idäčäk ber cähät var isä o da Boxaranyŋ iske ğadäte **ulan** xajvanlarny ğaryz ändam idmäkder* [«Бохара әхвалендән», «В.», 1910, № 595]; *Adäm **ulmaq istäjän** ävlad milät istifadä idä belsen* [«Кырым идарә руханиясендә мөһим мөшәвәрә мәҗлесе», «К.», 1916, № 928].

Текстларда *-an* формасы, гадәттә, атрибутив функциядә кулланыла һәм процессның субъектын белдерә: *...veja bašqa iğanädä **bulynmaq istäjän** kemsälär* [«Игълан», «Б.т.», 1906, № 36]; *Šul program mädräsäneŋ saxiby **ulan** Äxmäd baj wä mädräsä idaräse tarafyndan qabul iteleb ğamälgä qujyldy* [«Мәдрәсә Хөсәениянең програмы», «В.», 1909, № 495].

Шулай ук газета текстларында *-an* формасы үзе белдергән процесс юнәлгән объектны белдерә: *Binaän ğaläjhi bu kičä čäršänbä kičäse ğomut möminin xaqynda ber šäp **ğafu** wä **räxmät ulan** Läjläi möbarai*

*qaderder* [«Ләйләи кадер», «Б.т.», 1906, № 39]; *Hämä xalyqlarnyŋ mäktäblärendä rus tele uqytyluny wä buŋa hämäse öčen* ***möštiräk ulan*** *xökümät tele dib qaralu lazem küreläder* [«Ибтидаи тәгълим», «В.», 1909, № 426]; ***Čyqarylan*** *paranyŋ lazem järlärä saryf idelmäse julyny düšenälem* [«Кырым идарә руханиясендә мөһим мөшәвәрә мәҗлесе», «К.», 1916, № 928].

Моннан тыш, газета текстларында процессның кайда башкарылуын, ягъни урынын ачыклап килгән *-an* үткән заман сыйфат фигыль формасы очрый: *Bez möselman küb* ***ulan*** *jerlärdä wäkil ulmağa laiq ulan kešemez var isä möselmandan sajlamağa tyryšamyz* [«Мөселманнарның иң кирәкле нәрсәләре», «Б.т.», 1906, № 31]; *Bezem milätneŋ mondajyn* ***möhlik ulan*** *qabaxät julğa kerüeneŋ säbäbläre tizräk möxakämä qylynyb tiješle čaralar kürelsen ide* [«Башкортлар вә маскарад», «В.», 1912, № 932].

«Борһане тәрәккый», «Вакыт» һәм «Кояш» газеталары текстларында исемләшкән *-an* формалы сыйфат фигыльләрнең кулланылышы сирәк күренеш: *...Matbuğatdan* ***mäxrüm ulan*** *mäsäl mesken bičara* [«Матбугат», «Б.т.», 1906, № 30].

*-an* кушымчалы үткән заман сыйфат фигыльнең юклык формасы газета текстларында чикләнгән кулланылышы белән аерылып тора һәм *-my-j/-mi-j* кушымчасы ярдәмендә ясала: *Ečendä läjläi qader* ***bulynmyjan*** *aj...* [«Матбугат», «Б.т.», 1906, № 30].

Югарыда әйтеп үтелгәнчә, *-an* формалы сыйфат фигыльләр «Борһане тәрәккый» газетасы текстларында гына шактый актив. Шул ук вакытта әлеге грамматик күрсәткеч угыз группасына караган төрки телләр өчен хас булган билге дип санала. Әлеге мәкаләдә китерелгән фактик материал күрсәткәнчә, *-an* формасы кулланылган текстлар угыз телләре, шул исәптән XX гасыр башы госманлы әдәби теленә хас булган башка грамматик (*xäjäten**e***, *mädänijäsen**e***, *düšen**älem*** һ.б.) һәм лексик (*ävlad*, *istifadä*, *istämäk*, *para*, *lazem* һ.б.) үзенчәлекләрнең актив булуы белән дә характерлана.

Шулай итеп, тикшерелгән материаллардан күренгәнчә, «Борһане тәрәккый», «Вакыт» һәм «Кояш» газеталарында басылган текстларда үткән заман сыйфат фигыль угыз һәм кыпчак телләре өчен хас булган берничә грамматик форма ярдәмендә белдерелә. Угыз телләре өчен хас булган формаларның, аерым алганда *-myš* һәм *-an* күрсәткечләренең актив кулланылышы ягыннан «Борһане тәрәккый» газетасы текстлары аерылып тора. Әлеге факт, беренче чиратта, географик сәбәпләр – газета нәшер ителгән Әстерхан шәһәренең татар халкының милли һәм рухи үзәге булган Казаннан еракта урнашуы белән аңлатыла. Моннан тыш, XX гасыр башы Әстерхан шәһәре төрле төрки халыкларның күпләп яшәү урыны буларак билгеле. Бу исә, үз чиратында, җирле татар халкының телендә традицион гомумтөрки тел формаларының активрак кулланылуына китерә торган нигез булып тора. Шулай ук, Әстерхан төбәге татарларының теленә, шул исәптән «Борһане тәрәккый» газетасының теленә дә, кырым татар теле көньяк

диалектының һәм кырым татар теле аша госманлы төрекчәсенең күпмедер дәрәҗәдә йогынты ясый алуын да исәпкә алырга кирәк. Әлеге мәсьәләдә хронологик факторның тәэсирен дә исәпкә алу кирәк. Билгеле булганча, «Борһане тәрәккый» газетасы XX гасырның беренче унъеллыгында басыла, «Вакыт» газетасының күпчелек саннары исә – икенче унъеллыгында нәшер ителә, ә «Кояш» газетасының басылу вакыты тулаем узган гасырның икенче унъеллыгына гына карый. Шул ук вакытта, нәкъ менә «Кояш» газетасы чыгып килгән вакыт аралыгы тарихка төрле иҗтимагый, сәяси һәм милли сәбәпләр аркасында иске татар әдәби теле кысаларында табигый рәвештә традицион гомумтөрки һәм угыз теле формаларын куллланудан гавами сөйләмә тел формаларын куллануга таба күчеш чоры буларак кереп калган.

**Әдәбият**


Башкортлар вә маскарад // Вакыт. 1912. № 932.

Болгар хәрабәләре һәм борынгы болгарлар // Вакыт. 1908. № 333.

Бохара әхвалендән // Вакыт. 1910. № 595.

Газеталардан // Борһане тәрәккый. 1906. № 42.

*Грунина Э.А.* Историческая грамматика турецкого языка. М.: Изд-во Москов. ун-та, 1991. 223 с.

Дәрел Әдәбдә сөйләнгән нотык // Борһане тәрәккый. 1906. № 36.

Ибтидаи тәгълим // Вакыт. 1909. № 426.

Игълан // Борһане тәрәккый. 1906. № 36.

Кырым идарә руханиясендә мөһим мөшәвәрә мәҗлесе // Кояш. 1916. № 928.

Ләйләи кадер // Борһане тәрәккый. 1906. № 39.

Матбугат // Борһане тәрәккый. 1906. № 30.

Мәдрәсә Хөсәениянең програмы // Вакыт. 1909. № 495.

Мөселманларның иң кирәкле нәрсәләре // Борһане тәрәккый. 1906. № 31.

Полтава мөхарабәсе // Вакыт. 1909. № 488.

Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков. Морфология. М.: Наука, 1988. 557 с.

Татар әдәби теле тарихы (XIII–XX йөз башы). Морфология. Грамматик категорияләрнең структур-субстанциональ үзенчәлеге һәм функциональ-стилистик мөмкинлекләре: язма традицияләр, норма һәм вариантлылык: III томда / фән. ред. Х.М. Хисамова. Казан: ТӘһСИ, 2017. Т. II. 888 б.

Хәят – тереклек саклау // Борһане тәрәккый. 1906. № 45.

*Юсупов Ф.Ю.* Морфология татарского диалектного языка. Категории глагола. Казань: Фэн, 2004. 592 с.



***Миңнуллин Бәхтияр Ким улы,***
*филология фәннәре докторы, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының гомуми лингвистика бүлеге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре, бүлек мөдире*

УДК 81'38

***Р.Ф. Мирхәев***

# XIX ГАСЫР АХЫРЫ – XX ГАСЫР БАШЫ ТАТАР МӘГЪРИФӘТЧЕЛЕК ПРОЗАСЫ ӘСӘРЛӘРЕНДӘ *-ДЫ* КУШЫМЧАЛЫ БИЛГЕЛЕ (КАТЕГОРИК) ҮТКӘН ЗАМАН ХИКӘЯ ФИГЫЛЬЛӘРНЕҢ СТИЛИСТИК КУЛЛАНЫЛЫШ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

Статья посвящена изучению стилистики произведений татарской просветительской прозы, в частности особенностей употребления в них глаголов определенного (категорического) прошедшего времени изъявительного наклонения с аффиксом *-ды*. Данные формы глагола, будучи одним из основных элементов грамматической структуры старотатарского языка, также играют важную роль в формировании стилистической структуры первых образцов татарской беллетристики. До настоящего времени в работах ученых они описывались лишь фрагментарно. При этом их стилистический потенциал оставался вне поля зрения языковедов.

**Ключевые слова:** стилистика, старотатарский письменный литературный язык, язык татарской просветительской прозы, изъявительное наклонение, глаголы определенного (категорического) прошедшего времени.

The article is devoted to the study of the stylistics of works of Tatar educational prose, in particular, the peculiarities of the use of verbs of a certain (categorical) past tense of the indicative mood with an affix *-dy* in them. These verb forms, being one of the main elements of the grammatical structure of the Old Tatar language, also play an important role in the formation of the stylistic structure of the first samples of Tatar fiction. Until now they have been described only in fragments in the works of scientists. At the same time, their stylistic potential remained out of sight of linguists.

**Keywords:** stylistics, Old Tatar written literary language, the language of Tatar educational prose, indicative mood, verbs of a certain (categorical) past tense.

Хәзерге татар тел белемендә хикәя фигыльнең түбәндәге формалары норма буларак аерып чыгарыла:

1) синтетик формалар: *-ды, -ган* кушымчалы үткән заман, *-а (-ый)* кушымчалы хәзерге заман, *-р, -ачак* кушымчалы киләчәк заман хикәя фигыльләр;

2) аналитик формалар: *-а (-ый) иде, -ган иде, -а (-ый) торган иде* үткән заман, *-ачак иде* киләчәк-үткән заман хикәя фигыль формалары [Татар грамматикасы, 2016, б. 116–132; Татарская грамматика, 1997, с. 100–124; Хисамова, 2015, б. 116–133].

Хикәя фигыльнең хәзерге татар әдәби телендә норма буларак кабул ителгән формаларының төрле дәрәҗәдә XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы татар әдәби телендә дә кулланылуы күзәтелә. Шуның белән бергә бу чорга караган иске татар язма текстларының тел тукымасын түбәндәге хикәя фигыль формалары да тәшкил итә:

1) синтетик формалар: *-мыш, -ыб* кушымчалы үткән заман, *-йур, -макда* кушымчалы хәзерге заман хикәя фигыльләр;

2) аналитик формалар: *-мыш иде, -ыб иде, -йур иде, -макда иде, -р иде* үткән заман хикәя фигыль формалары [Татар әдәби теле тарихы, 2017, б. 492–616].

Мәгълүм булганча, хикәя фигыльләр чынбарлыкта булып торган, булып узган яисә булачак эш-хәрәкәтләр турында объектив рәвештә хәбәр итәләр. Билгеле бер дәрәҗәдә бу аларның стилистик табигатендә дә чагылыш таба. Әлеге мәкалә кысаларында *-ды* кушымчалы билгеле (категорик) үткән заман хикәя фигыльләрнең XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында иҗат ителгән татар мәгърифәтчелек прозасы әсәрләрендә стилистик кулланылыш үзенчәлекләре тикшерелде.

Хәзерге татар әдәби телендә бу фигыльләрнең парадигматик мәгънәсе булып сөйләү моментыннан алда сөйләүченең күз алдында булган, тәмамланган, кабатланган эш-хәрәкәтләрне белдерү тора. Шул ук вакытта билгеле бер контекстта алар дәвамлы яки кабатланган эшләрне, нәтиҗәле үткән заман, киләчәк һәм хәзерге заман хикәя фигыльләрнең һ.б. мәгънәләрне дә белдереп килә алалар [Татар грамматикасы, 2016, б. 119–120; Татарская грамматика 1997, с. 106–109; Хисамова 2015, б. 181–182]. Чыганаклардан күренгәнчә, әлеге хикәя фигыльләр XIX гасырның икенче яртысы – XX гасыр башында татар әдәби теле хәрәкәт иткән барлык текстларда да урын алалар һәм әдәби норманың бер күрсәткече булып торалар. Биредә алар үзләренең һәм парадигматик, һәм синтагматик мәгънәләрендә кулланылалар [Миннуллин, 2022, с. 170–177; Татар әдәби теле тарихы, 2017, б. 494–515].

Мәгърифәтчелек прозасы әсәрләрендә *-ды* кушымчалы билгеле (категорик) үткән заман хикәя фигыльләр, нигездә, персонажлар тарафыннан үткәндә башкарылган, тәмамланган процессларны белдерү өчен кулланылалар. Стилистик яссылыкта алар укучыларны алга таба тасвирланачак вакыйгаларга алып керү һәм аерым персонажлар белән таныштыру чарасы буларак хезмәт итәләр: *Ике йыл бундан мөқаддәм менла Хисаметдин Госманлы йирендән тәхсиле ғыйлем илә wатаны Нуна* ***қайтды*** [Акъегет, 1886, б. 3]; *Қызны бер дәфға, ике дәфға, өч дәфға күреб, қызға зийадәчә* ***ғашыйқ улдым*** [Бигиев, 1887, б. 22]; *Ғаббас мелла йәшлегендә ғайәт дә зирәк wә шат wә һәрнәрсәгә һәwәсле wә һәр шәй қулындан килер мөстәғыйт бер бала иде исә дә, зан иделдеге қадәр кәмаләт кәсеб идә алмадыгы хәлдә мәдрәсәдән чықыб* ***имам улды*** [Фәхретдин, 1903, б. 4].

Алга таба *-ды* кушымчалы билгеле (категорик) үткән заман хикәя фигыльләр әсәрләрдә тасвирлана торган вакыйгалар белән тыгыз бәйләнештә булган процесслар турында сүз алып барганда җәлеп ителәләр: *Җомға намазыны уқыдықдан соңра Хисаметдин менла атны чанайа йигеб, бәғзы кирәк шәйләр алмақ ичүн* ***шәһәрә йулланды*** [Акъегет, 1886, б. 7]; *Атлар йитде. Тәфтишләр ғарәбәләрендән дөшеб,* ***номерга кереб китделәр*** [Бигиев, 1887, б. 8]; *Ғабделғафур*

*һәр қайулары илә мөсафәхә қылышыб-күрешеб, ... йаздығымыз мөәззинлә бәрабәр ...* ***йула чықдылар*** [Бигиев, 1890, б. 7]; ***Пароход соң дашышны вирде**, дусларым илә күрешеб йәнә дә **үз урыныма кердем*** [Фәхретдин, 1899, б. 14]; *Ғаббас мелланың сәфәрендән ике wә Йанбәғ шәһәрендән йазмыш улан соң хатындан бер ай үтдеге соңында, Ғайшә абыстай қулына чит мәмләкәт (Төркийә дәүләте) маркасы илә* ***бер мәктүб вирелде*** [Фәхретдин, 1903, б. 40].

Бер-бер артлы башкарыла торган процессларны белдереп килгәндә, *-ды* кушымчалы билгеле (категорик) үткән заман хикәя фигыльләр текстларда билгеле бер сөйләм агышын тудыру өчен хезмәт итәләр: *Ғаббас аға мөдәррис хәзрәтләрене тәғзыйм идеб* ***қаршы алды***. *Шәмси абыстай менла қадыныны қаршылаб* ***үз бүлмәсенә кертде***. *Бундан соңра қунақлара* ***сыйлар, хөрмәтләр башлады***. *Әүwәлән, ғадәтенчә, самавар* ***мәйдана чықды***. *Ашханәдә* ***ғайрәт wә хәрәкәт башланды***. *Қоймақлар, пәрәмәчләр бер-бер ардлы* ***пешмәйә башладылар***, *қамырлар басылыб, қатламалар, қош делләре* ***хазырланмаға башладылар*** [Акъегет, 1886, б. 35].

Язучылар *-ды* кушымчалы билгеле (категорик) үткән заман хикәя фигыльләрне персонажларның портретын тулыландыру, аларның рухи дөньясын һәм психологик халәтен ачып бирү чарасы буларак та файдаланалар: *Шу йирдә Хисаметдин менла* ***мөтәәссир улыб туқтады wә күзләре бераз суланды*** [Акъегет, 1886, б. 5–6]; *Хәдичә туташ да, бу кеби гүзәл мәслихәтне ишедеб, тәхте қаләмдә тәмам улмайачақ қадәр* ***шадланды*** [Бигиев, 1887, б. 23]; *Маһруй, следовательдән қайтқач, көне буйы һич дә* ***йимәк йимәде wә эчмәде***. *Кич улғач да, күзенә йоқы килмәйенчә, йарым кичәйә қадәр хили фикерләр қылыб,* ***йоқламады*** [Бигиев, 1890, б. 40].

Аерым очракларда персонажларның психологик халәтен ачып бирү өчен җәлеп ителгән *-ды* кушымчалы билгеле (категорик) үткән заман хикәя фигыльләр күчерелмә мәгънәдә кулланылып, җанландырулар (а) һәм метафоралар (ә) барлыкка китерүдә катнашалар:

а) *Фикерләр менланың* ***уйқусыны қачырды*** [Акъегет, 1886, б. 25]; *Йәш қыз ырақда бер қара шәй хәрәкәт итде кеби күреб күңеленә* ***қурқу дөшде*** [шунда ук, б. 35];

ә) *Сибғатулла әфәнде исә атасыйла хәбәрләшдекдән соңра үлек кеби ағарыб* ***қайғы wә әфкяр дәрйасына батды*** [Акъегет, 1886, б. 54]; *Гайниҗамал абыстай қурқыныб уйқулы-уйғанулы ашханәйә чықды wә Хәнифәйе таныб бераз* ***ғақлыны туплады*** [шунда ук, б. 58].

Моннан тыш алар персонажларның сөйләм үзенчәлекләрен тудырганда кулланылалар: *Сәғать 7 гә чақлы магазинда ултырдым, соңра ивгә қайту нийәте илә* ***магазиндан китдем***, *йулда Ғабденнәсыр әфәнде* ***туғры килде***, *Ғабденнәсыр әфәнде илә нумеренә кереб, байтақ чәй эчеб,* ***сөйләшеб ултырдық*** [Бигиев, 1887, б. 9–10].

Язучылар *-ды* кушымчалы билгеле (категорик) үткән заман хикәя фигыльләрне персонажларның көндәлек тормышындагы

вакыйгаларны күз алдына бастырганда да файдаланалар: *Биш-алты дәқыйқа кичдекдән соңра Муса әфәнде йирендән торыб, **тәһарәтләнергә чықды**. Нигмәтулла әфәнде дә тәһарәтләнеб тәмам булгач, Муса әфәндейә иқтида қылыб, **салаwаты фәҗерне әда қылдылар**. Бәгдә әс-салаwат, хадим **самавар-чәй кәлтерде**. Нигмәтулла әфәнде: «Инша аллаһ, бер нәрсә дә булмас», – диб, **самавыр йанына чәй эчү мақсуды илә ултырды**. Муса әфәнде дә: «Әстәгфирулла, әстәгфирулла!» – дийү **самавыр йанына ултырды*** [Бигиев, 1887, б. 14].

Текстларда -*ды* кушымчалы билгеле (категорик) үткән заман хикәя фигыльләр өчен хас стилистик үзенчәлекләр татар мәгърифәтчелек прозасы әсәрләренең аерылгысыз өлешен тәшкил иткән төрле стиль катламнарына мөнәсәбәттә дә чагылыш таба. Мәсәлән, публицистик чигенешләрдә алар:

а) риторик җөмләләрнең мәгънәви үзәген тәшкил итәләр: *Әфәнделәр! Бин йыллар кичде татар зыйаланмады әйтәсез. **Зыйаланмадық**, аныңчүн кем эчемездә мәглүмат таләбкярлеге йуқ иде* [Акъегет, 1886, б. 46]; *Хатынларымызның да арақы wә башқа мөскираты сәвәнләре йуқ дәгел, әмма «Гөнаһе кәбаир» улан бу йаманлық wә фәсадымыз бердән килеб **өстемезә дөшмәделәр**. Ана қарнындан бөйлә исерек wә сәрхуш **тугмады**. Аз-аз бер кечек шәйдән башланыб, әйтдегем кеби, йаманлықларымыз күпләнеб wә қуәтләнеб **бәрәкәт күтәрелде*** [Бигиев, 1890, б. 5–6]; *Нә чара ки, **тереклегемез алышынды, гадәтләремез башқаланды**. Беремез хәтта ки дөнйа тереклеге ичүн лазем улган һөнәрләрне инкяр идәр мәртәбәдә **фанатик (мөтәгассыйб) улды**. Икенчемез, йурганына күрә айақ озатмай wә үзене йахшы белмәй, **мода мөбтәлясе улды**. Өченчемез үзенең наданлықларыны дин исемендән халыққа **тәлқыйн әйләде**. Дүртенчемез, байлар хәтерене қалдырмаз ичүн, лазем wәгазьләрне әйтмәкдән **сөкүт итде*** [Фәхретдин, 1899, б. 12];

ә) риторик сораулар составында кулланылалар: *Йуқса безем галимләремез мәзкүр әсәрләре йазан зәваты кәрамдан да бәләнд бер **мәртәбәйә ирешделәрме**?!...* [Фәхретдин, 1903, б. 25]; *Башқа милләтләр кеби безләрә һәм гыйбрәт wә хәмийәт изһар идәчәк wақытлар һәнүз **йитмәдеме**?...* [шунда ук, б. 66].

Фәнни стиль катламында -*ды* кушымчалы билгеле (категорик) үткән заман хикәя фигыльләр авторлар тарафыннан:

а) укучыларга этнографик, конфессиональ һәм тарихи характердагы мәгълүматны җиткерү чарасы буларак җәлеп ителәләр: *Туқсан йәшендән узыб, 691 сәнәсендә **wафат улды*** [Фәхретдин, 1899, б. 17]; *Башқордлар. Бу төрекләр элек хәлләрендә бәдәwилек илә wақыт кичерерләр иде, ләкин соң заманларда, қарйәләр тәэсис идеб, **иген кәсебенә башладылар*** [шунда ук, б. 56].

ә) кешелек җәмгыяте үсеше өчен зур әһәмияткә ия булган тарихи вакыйгалар турындагы фәлсәфи характердагы җөмләләр составында кулланылалар: *Азийәдә wақыйг Һинд дәрйәсендән Аурупада мәвҗүд Пирәнә дагларына дәк гарәб йире ислам дәүләте улыб, бу*

*дәүләт дә исламийәт сайәсендә нәқадәр махир хакимләр, нәқадәр камил табибләр wә ғоләмәләр* ***мәйдана чықды****!* [Акъегет, 1886, б. 23].

Алга таба әлеге төр хикәя фигыльләр дини дискурс өчен хас булган экспрессив чигенешләрне тудыра торган җөмләләрнең нигезен тәшкил итәләр: *Әстәғфирулла, әстәғфирулла, әстәғфирулла, тәүбә! Йа Раббе, әгәр бәнем әғзамдин wә әфғалемдин wә әқwалемдин көфер хата wә насийан садир улдыйса,* ***тәүбә итдем, кайтдым, тәүбә итдем, кайтдым, тәүбә итдем, кайтдым, биздем****! Кяфернең көферлегендән wә ни нәрсә кяфер дине эчендә вардыр,* ***барчасындин биздем****! Қабул қылдым ислам динене wә ни нәрсә кем ислам дине эчендә вардыр,* ***барчасыны қабул қылдым****,* ***телем илә иқрар итдем****,* ***күңелем илә растға тотдым*** [Бигиев, 1887, б. 77].

Ә мәхәббәт хатларында алар хис-тойгыларны аңлату чарасы булып торалар: *Җаным Хәнифә ханым! Нурлы йөзеңе әүwәл күрдегем илә* ***wөҗүдем мөтәәссир улды****. Ләкин бу* ***иҗтихадым нафилә улды****. Зиһенемдә сине йөрәк бәғрем тасаүwыр идеб зәwықланмақдан үзүземне мәниға* ***тәқатем қалмады****...* [Акъегет, 1886, б. 24].

Моннан тыш, текстларда *-ды* кушымчалы билгеле (категорик) үткән заман хикәя фигыльләр күчерелмә мәгънәдә кулланылып, аерым стиль чараларын барлыкка китерәләр. Аерым алганда алар:

1) метафоралар булып киләләр: *Ләкин бердән ишеделмеш ике-өч мылтық садәсе қадынлар* ***сүзене кисде*** [Акъегет, 1886, б. 52]; *Ике данә кирпече wә балайы бер қапчыға қуйыб, Қабан күлендә әүwәл туғры килән бәкейә ақрынча у қапчығны ташламақла* ***баланы бөтен-бөтенә «тәмам» қылды*** [Бигиев, 1890, б. 33]; *Ничә айлар йатыб, сәламәтләнеб чықды wә аз қалды ошбуның сәбәбендән* ***ахирәт сәфәренә китмәде*** [Фәхретдин, 1903, б. 29];

2) градацияләр тудыруда катнашалар: ... *wафат итдегендә бөтен мәмләкәтләре* ***хәрәкәтә килде****, газеталары қаләмләрене күз йәшләренә батырыб* ***йаздылар****, йәш йөрәкләре* ***ағлатдылар****, мәрсийәләр* ***сөйләделәр****, мөнақабләрене wә тәрҗемәи хәлләрене* ***йаздылар****, мәшриқ wә мәғриб халықларындан тәғзийә телеграмлары* ***алдылар*** [Фәхретдин, 1903, б. 26]; *Муса ақчасыны андан* ***қарады****, бундан* ***эзләде, сорады, йалынды, ағлады****, йуқ, табылмады* [шунда ук, б. 34]; *Бу хатны ачдықында қуллары* ***тетрәде****, йөрәге* ***селкенде****, җөмлә тәне бер* ***қызды****, бер* ***өшеде*** [шунда ук, б. 41].

Татар мәгърифәтче язучыларының сәяхәтнамәләренә килгәндә, *-ды* кушымчалы билгеле (категорик) үткән заман хикәя фигыльләр биредә дә күпсанлы стилистик вазифаларны башкарып киләләр. Беренчедән, язучылар аларны җәмгыять тормышындагы уңай күренешләр турында сүз алып барганда метафоралар буларак кулланалар: *Ғолүме шәрғыйә wә фөнүне җәдидә тәхсил идән* ***хәмийәтле гәнҗләремез йитешде*** [Кәрими, 1908, б. 84]; *Кәнде милләтләре арасына да инсанийәт wә мәдәнийәт нәшерене wә бу сурәтлә wатан wә хөкүмәтең мөнафиғына хезмәт итмәге кәнделәренә*

*мақсад wә мәсләк иттихаз итделәр,* ***қаләмә сарылдылар*** [Кәрими, 1908, б. 84].

Икенчедән, әлеге төр хикәя фигыльләр сәяхәтнамәләрдә тарихи вакыйгалар турында мәгълүмат биргәндә җәлеп ителәләр: *672 сәнә миладийәдә Бикенде, Сәмәрканде, Кәше, Нәсәфе гарәбләр* ***фәтех итделәр*** [Бигиев, 1908, б. 4]; *9 нчы гасыр милади ахырында, хәлифәте Габбасийә заманында, 287 сәнә һиҗридә Бохарада Саманилар хөкүмәте* ***ибтида улынды*** [шунда ук]; *Саманилар дәүләтенең мөәссисе Исмәгыйль бине Әхмәд заманларында, 892–907 милади сәнәләр имтидадында Бохара иң бөйек қуәтенә* ***наил улды*** [шунда ук].

Өченчедән, язучылар аларны үзләренең юлдашлары һәм әңгәмәдәшләре белән кайчандыр булып узган вакыйгаларны җанландырганда файдаланалар: *Қарйәйә* ***кердек****, мәсҗеде җәмигы* ***кичдек****. Шу җамигың имамы мелла Сәйфулла хәзрәтләренең ханәсенә* ***йақын килдек****. Имамның ханәсе қарибендә ике адәм* ***күрдем****. Хәрәкәтләрендән бераз* ***шөбһәләндем****. Эшнең асылыны аңламақ ичүн арабамы* ***туқтатдым****. Белмәм, насыл, ул ике адәм бәне, бәнем арабамы* ***күрмәделәр****. Пәк аз бер wақытда, йарым дәқыйқа эчендә, күземез уңында имам ханәсенең башына* ***атәш тоташды*** [Бигиев, 1908, б. 19].

Дүртенчедән, *-ды* кушымчалы билгеле (категорик) үткән заман хикәя фигыльләр укучыларга географик, социаль-икътисади һәм мәдәни характердагы мәгълүматны җиткерү чарасы булып торалар: *Тимер йул 1880 сәнәдә ибтида улыныб, 1886 сәнәдә Аму-Дәрйайа, соңра, 1888 сәнәдә, Сәмәрқанда* ***wасыл улды*** [Бигиев, 1908, б. 48]; *Бурада голүме исламийәйә хезмәт идән гайәт чуқ зәват* ***дөнйайа килде*** [шунда ук, б. 88]; *«Әл-җәмиг әс-сахих» намында улан китабы йиде биң қадәр хәдисе мөштәмил улыб, галәме исламда «Китабы Хода» соңында* ***иң мөгтәбәр китаб улды*** [шунда ук, б. 97].

Бишенчедән, әлеге төр хикәя фигыльләр текстларда, бер-бер артлы башкарыла торган процессларны белдереп, сәфәр вакытында авторлар башыннан үткән вакыйгаларны тасвирлауда билгеле бер сөйләм агышын тудыралар: *Мәзары* ***кичдек****. Мөфти хәзрәтләренең ханәсенә* ***килдек****. Хәзрәте ишан мөфти җәнабләрейлә* ***күрешдек****. Гайәт икрамла бәне* ***истиқбал итде****. Хатырымы, хәлеме истифсар қылыб, тәгам софрасына бәне* ***дәгwәт итде*** [Бигиев, 1908, б. 71]; ***Гафу үтендем****. Мәмнүнийәтеме бәйан идеб* ***тәшәккер итдем****. Зәкятҗы хәзрәтләре икрамла бәне* ***озатды****. Регистаны тамаша итмәйә* ***китдем****. Бәңа бер рәхбәр* ***вирделәр*** [шунда ук, б. 75].

Алтынчыдан, язучылар аларга сәфәр вакытында күзәтелгән күренешләр һәм вакыйгалар турында сүз алып барганда мөрәҗәгать итәләр: *Wәзенендә хыйанәт идән, малында гайебе улан өч адәме хозуры рәисә* ***күтәрделәр****. Беренең хыйанәте шаһидләр шәһадәтейлә* ***сабит улды****. Рәис ун қамчы җәза* ***тәгйин итде****. Мөлаземләрең бере мәхкүме қулларындан тотыб* ***арқасына алды****. Дигәр бер мөлазем ачық улмыш арқайа дәрхаль* ***қамчы йагдырмайа башлады*** [Бигиев,

1908, б. 65]; *Самарадан хәрәкәт бәгдендә өйләдән соңра сәгать алтыларда Волга нәһере үзәренә ҡорылмыш* ***тимер күпердән кичдек*** [Кәрими, 1902, б. 7]; *Без чәйемезе тәмам идеб, Самарадан алдыгымыз газеталары уҡымага әлемезә алмыш идек, мәзкүр ике татарың бере йанымыза килеб* ***сәлам вирде*** [Кәрими, 1908, б. 12].

Җиденчедән, *-ды* кушымчалы билгеле (категорик) үткән заман хикәя фигыльләр авторлар тарафыннан аларның сәфәр вакытында очрашкан күренешләр тәэсире астында туган хис-кичерешләре турында сүз барганда да кулланылалар: *У сүзләр бәңа гайәт* ***агыр килде****. Буныңла ихйалары зийарәт итмәкдән* ***усандым*** [Бигиев, 1908, б. 79]; *Шу хәл бәнем күңелемә* ***гайәт мөнасиб килде*** [шунда ук, б. 102]; *Бән у мескинләре соң дәрәҗәдә* ***айадым*** [шунда ук, б. 104]; *Бу ҡарт адәмең сүзләре зийадәсейлә* ***хушымыза китде*** [Кәрими, 1902, б. 39].

Моннан тыш, әлеге төр хикәя фигыльләр текстларда риторик җөмләләр һәм сорауларның нигезен тәшкил итәләр: *Шөкерләр улсын, шимди татарларымызда үйлә гафләтләр азайыб, төшдән соң исә дә* ***татарның башына гаҡлы килде*** [Бигиев, 1908, б. 12]; *Бунлар нәрәдән* ***килделәр****? Wә нәрәйә китделәр, ничүн* ***өйлә улды****?* [Кәрими, 1908, б. 39]; *Әй, зыйалы мөселманлар! Әй, образауный җәванларымыз! Бу гаwам халҡымызың тәрәҡҡый wә уйганмасы, рәхәт wә сәгадәте ичүн без* ***нә йапдыҡ****?* [шунда ук, б. 84].

Нәтиҗә ясап әйткәндә, XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы татар мәгърифәтчелек прозасы әсәрләрендә *-ды* кушымчалы билгеле (категорик) үткән заман хикәя фигыльләр стилистик планда билгеле бер максатларда кулланылалар һәм күпсанлы вазифалар башкарып киләләр. Бу үз чиратында аларның әлеге аспектта бай потенциалга ия булулары һәм мәгърифәтче язучыларның үзләренең әдәби әсәрләрен һәм публицистик хезмәтләрен язганда, укучыларга эстетик һәм этик яктан йогынты ясау өчен тел системасының барлык ресурсларына да мөрәҗәгать итүләре турында сөйли.

**Әдәбият**

*Акъегет М.* Хисаметдин менла. Милли роман яки хикәя. Казан: Казан университеты табгыханәсе, 1886. 70 б.

*Бигиев З.* Өлүф, яки гүзәл кыз Хәдичә. Роман. Казан: Тип. Г.М. Вечеслава, 1887. 77 б.

*Бигиев З.* Гөнаһе кәбаир. Роман. Казан: Тип. Г.М. Вечеслава, 1890. 72 б.

*Бигиев З.* Мавәраэннәһердә сәяхәт (Транс-Оксанияйә сәфәр). Казан: типолитогр. И.В. Ермолаевой, 1908. 108 б.

*Кәрими Ф.* Яурупа сәяхәтнамәсе. Оренбург: Тип. «Вакыт», 1902. 191 б.

*Кәрими Ф.* Кырым сәяхәте. Оренбург: Тип. М.-Ф. Каримова, 1908. 116 б.

*Миннулин Б.К.* Специфика морфологической структуры текстов татарской периодической печати начала XX века: монография. Казань, 2022. 336 с.

Татар әдәби теле тарихы (XIII гасыр – XX йөз башы) / И.Б. Бәширова, Ф.Ш. Нуриева, Э.Х. Кадыйрова, Р.Ф. Мирхәев; [фәнни ред. Ф.М. Хисамова]. Казан: ТӘһСИ, 2017. II т.: Морфология. Грамматик категорияләрнең структур-

субстанциональ үзенчәлеге һәм функциональ-стилистик мөмкинлекләре: язма традицияләр, норма һәм вариантлылык. 888 б.

Татар грамматикасы: өч томда / [проект җит. М.З. Зәкиев]. Тулыландырылган 2 нче басма. Казан: ТӘһСИ, 2016. Т. II. 432 б.

Татарская грамматика: в 3-х т. Т. 2. Морфология. Казань: Татар. кн. изд-во, 1997. 397 с.

*Хисамова Ф.М.* Татар теле морфологиясе: югары уку йортлары өчен дәреслек. 2 нче басма. Казан: Татар. кит нәшр., 2015. 335 б.

*Фәхретдинов Р.* Сәлимә яки гыйффәт. Гафил бән Габдулла әсәре уларак бер хикәятдер. Казан: Тип. Б.Л. Домбровского, 1899. 80 б.

*Фәхретдинев Р.* Әсма яки гамәл вә җәза. Оренбург: Тип. М.-Ф.Г. Каримова, 1903. 130 б.

***Мирхәев Рифат Фирдинат улы,***
*филология фәннәре докторы, доцент, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының гомуми лингвистика бүлеге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

УДК 811.512.145

***Р.Т. Сәфәров***

# БЕРНИЧӘ ЙӨКЛӘТҮ ЮНӘЛЕШЕ КУШЫМЧАСЫ БЕЛӘН КИЛГӘН ФИГЫЛЬЛӘРНЕҢ СҮЗЛЕКТӘ ТЕРКӘЛЕШЕ

Подача залоговых форм глаголов в словарях тюркских языков остается малоизученной проблемой. В статье автором ставится вопрос о более подробном изучении словарной фиксации залоговых форм, в частности форм понудительного залога с несколькими аффиксами, дифференциация значений которых вызывает затруднения у носителей татарского языка. Как одно из решений указанной проблемы, предложены модели отражения залоговых форм в словарях татарского и др. тюркских языков.

**Ключевые слова:** татарский язык, лексикография, толковый словарь, словарная статья, залоги, залоговые аффиксы.

The presentation of collateral forms of verbs in dictionaries of Turkic languages remains a little-studied problem. In the article, the author raises the question of a more detailed study of the dictionary fixation of pledge forms, in particular, the forms of the imperative pledge with several affixes, the differentiation of the meanings of which causes difficulties for native speakers of the Tatar language. As one of the solutions to this problem, models of reflection of pledge forms in dictionaries of Tatar and other Turkic languages are proposed.

**Keywords:** Tatar language, lexicography, explanatory dictionary, dictionary entry, voices, voice affixes.

Кылынган гамәлнең субъекты белән объекты арасындагы мөнәсәбәтне белдерә торган грамматик категория буларак юнәлеш категориясе тюркологиядә дә, аерым төрки телләрдә дә шактый яхшы өйрәнелгән. Кагыйдә буларак, төрки телләрдә юнәлешнең *төп, төшем, кайтым, уртаклык* һәм *йөкләтү* формалары аерыла [Сравнительно-историческая…, 1988, с. 269]. Бу формаларның барысы да грамматикаларда җентекләп бәян ителгән, аларга ялгану ихтималы мөмкин булган аффикслар күрсәтелгән.

Хәзерге татар телендәге фигыль юнәлешләре монографик планда К.З. Зиннәтуллина тарафыннан өйрәнелгән [Зиннатуллина, 1969], аның материаллары татар һәм рус телләрендә басылган «Татар грамматикасы»нда кулланылган [Татар грамматикасы, 2002; Татарская грамматика, 1993]. Моннан тыш, татар телендә шул ук грамматика кабат нәшер ителде [Татар грамматикасы, 2016]. Юнәлешләрнең ясалыш ысуллары һәм төп мәгънәләре Ф.М. Хисамованың «Татар теленең морфологиясе» монографиясендә каралган [Хисамова, 2015]. Фигыль юнәлешләренең аерым мәсьәләләре күпсанлы мәкаләләрдә тикшерелгән.

Без күзәткән барлык хезмәтләрдә дә төп өйрәнү предметы буларак түбәндәгеләр карала: 1) юнәлеш формаларын билгеләү һәм

бер-берсеннән аеру; 2) юнәлешләрнең ясалыш ысуллары; 3) теге яки бу фигыль юнәлеш формаларының мәгънәләрен ачыклау [Татарская грамматика, 1993, б. 163–182; Хисамова, 2015, б. 209–216; Татар грамматикасы, 2016, б. 186–204]. Ягъни фигыльнең юнәлеш формалары морфология кысаларында гына өйрәнелә.

Шул ук вакытта юнәлеш категориясе лексикографиядә, аеруча аңлатмалы сүзлекләр төзү практикасында да кызыксыну уята.

«Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»нә кыска гына күзәтү анда фигыль юнәлешләре формалары бирелешендә берникадәр системасызлык булуын күрсәтә. Сүз уңаеннан, күпчелек төрки телләрнең аңлатмалы сүзлекләрендә дә шундый ук хәл күзәтелә. Сүз биш юнәлеш формасы да булган фигыльләрнең сүзлектә аерым формалары гына теркәлүе турында бара. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ннән мисаллар: *бизәү* (төп) һәм *бизәнү* (кайт.) теркәлгән, *бизәлү* (төш.), *бизәшү* (урт.), *бизәтү* (йөкл.) теркәлмәгән;

*юу* (төп), *юылу* (төш.), *юыну* (кайт.), *юдыру* (йөкл.) теркәлгән, уртаклык юнәлеше формасы *юышу* теркәлмәгән;

*уку* (төп), *укылу* (төш.), *укыну* (кайт.), *укыту* (йөкл.) теркәлгән, һәм шулай ук уртаклык юнәлеше формасы *укышу* ‘укырга ярдәм итү // бер-береңә уку’ теркәлмәгән.

Бу очракта күрсәтелгән сүзлекне төзү инструкциясенә мөрәҗәгать итәргә мөмкин. Анда фигыльнең мөстәкыйль мәгънәгә ия булган юнәлеш формалары теркәлә дип әйтелә [Татар теленең аңлатмалы..., 2015, б. 16; шулай ук карагыз: Инструкция по составлению..., 1982, б. 13]. Ягъни грамматик мәгънәгә ия булган юнәлеш формалары сүзлек берәмлеге буларак каралмый. Кызганычка, сүзлек төзегәндә бу принцип эзлекле рәвештә сакланмаган.

Юнәлеш формаларының ясалышын тагын бер проблемалы хәл дип санарга мөмкин. Беренче чиратта барлык тикшеренүчеләр юнәлеш формаларының күчемлелек-күчемсезлек категориясе белән бәйле булуын ассызыклый [Сравнительно-историческая грамматика..., 1988, с. 269]. Шулай итеп, барлык фигыльләр дә юнәлеш формалары ясый алмый. Аларның кайберләре ике яки берничә юнәлеш формасы ясый ала. Ягъни юнәлеш формаларын, мәсәлән, исемнәрдәге килеш категориясе белән чагыштырып булмый. Һәр исем барлык килешләр буенча төрләнә һәм, әлбәттә, лексикография күзлегеннән карагандა, сүзлектә һәр килеш формасын теркәүнең бернинди кирәге юк. Юнәлеш формаларына килгәндә исә, барлык формалар турында белешмәне кайдан табу мәсьәләсе ачык кала.

Шуңа бәйле рәвештә аңлатмалы сүзлекләрдә фигыльнең берничә кушымчалы юнәлеш формаларын теркәү мәсьәләсе тагын да актуальләшә. Татар телендә берничә юнәлеш кушымчасы белән кулланылган фигыльләр тиешле дәрәҗәдә өйрәнелмәгән. Берничә йөкләтү юнәлеше кушымчасы белән килгән фигыльләрнең фәнни тасвирламасы, кагыйдә буларак, түбәндәге фикерләр белән чикләнә: «...что касается глаголов, уже имеющих в своем составе тот или иной залоговый

аффикс, то и они могут приобрести аффикс понудительности. Исключения не составляют и сами понудительные формы» [Зиннатуллина, 1969, с. 202].

Тюркологиядә кабул ителгәнчә, йөкләтү юнәлеше инде булган нигезгә кушыла барган һәр яңа йөкләтү юнәлеше кушымчасы ситуациядә катнашучылар санын арттыра. Мәсәлән, төрек телендә *öl-mek* үлергә (төп), *öl-dür-mek* (үз куллары белән) үтерергә (1 кушымчалы йөкл. юн.), *öl-dür-t-mek* (кемдер аша) үтертү (2 кушымчалы йөкл. юн.), *öl-dür-t-tür-mek* (берничә кеше аша) үтерттерү (3 кушымчалы йөкл. юн.) [Понудительный залог…].

Татар теле материалына кечкенә анализ хәзер һәрвакыт бер, ике яки аннан да күбрәк йөкләтү юнәлеше булган фигыль формалары арасында семантик аерманың сиземләнеп бетелмәвен күрсәтә. Мәсәлән, *үтер-ү* һәм *үтерт-ү*, *китер-ү* һәм *китерт-ү* кебек сүзләрнең мәгънәләрендәге аерма ачык күренә. Әмма күпчелек очракта мондый берничә юнәлеш кушымчасы белән кулланылган сүзләрнең семантикасы нивелирланган. Матур әдәбиятта моңа мисаллар күп: *эчер-ү* (үз куллары белән) һәм *эчерт-ү* (инициатор булырга, ләкин үз кулы белән эчермәскә). Кагыйдә буларак, икенче мәгънә игътибарга алынмый. Халык җырларын башкаручылар бер очракта «кара бөдрә чәчләремне *үрдерәсем* килмидер» дип, икенче очракта «кара бөдрә чәчләремне *үрдертәсем* килмидер» дип әйтәләр һәм *үрдер-ү* «үрергә рөхсәт, мөмкинлек бирү яки мәҗбүр итү» һәм *үрдерт-ү* «инициатор булу, әмма үрү эшендә турыдан-туры катнашмау» сүзләрендә аерма сизмиләр.

Юнәлеш формалары бары тик грамматик категория буларак каралганлыктан, татар һәм башка төрки телләрнең аңлатмалы сүзлекләре югарыда күрсәтелгән нюансларны берничә йөкләтү кушымчасы булган фигыльләр семантикасында чагылдырмый. Шуңа күрә:

– нинди фигыльләр йөкләтү юнәлеше кушымчалары кабул итә ала?

– теге яки бу фигыль ничә йөкләтү юнәлеше кушымчасы кабул итә ала?

– төрле сандагы йөкләтү кушымчасы булган фигыльләр арасындагы мәгънә аермасы нәрсәдә? һ.б. сорауларга җавап бирә торган ышанычлы һәм фәнни яктан тикшерелгән белешмәлек юк.

Безнеңчә, нәкъ сүзлекләр системалы мәгълүмат бирә һәм күрсәтелгән яки яңа барлыкка килгән сорауларга җавап бирә алыр иде. Югарыда әйтелгәнчә, төрки телләрнең барысында да юнәлеш формалары бөтен фигыльдән дә ясалмый. Һәр телдә берничә йөкләтү юнәлеше кушымчасы белән ясала торган фигыльләр ясалышында да үзенчәлекләр бар. Бу исә шушы тел вәкилләренә дә, аны чит тел буларак өйрәнүчеләргә дә аңлатма бирүне таләп итә.

Бу очракта нәрсә тәкъдим итәргә була соң?

Бер яктан, фигыльнең һәр юнәлеш формасын, шул исәптән берничә юнәлеш кушымчасы булган фигыльләрне дә вокабула буларак теркәргә мөмкин булыр иде. Бу вариантның өстенлеге шунда ки,

сүзлектән файдаланучы үзен кызыксындырган сүзне җиңел таба алачак, аның гомумән барлыгын билгели алачак һәм, кирәк булганда, аның лексик мәгънәсе, кулланылыш контексты һ.б. белән таныша алачак. Шул ук вакытта мондый бирелешнең кимчелекләре дә юк түгел: лөгатьлек артык киң булачак, юнәлеш формалары белән генә аерыла торган фигыльләрне аңлату урынына башка формаларга сылтамалар урын алачак, сүзлектән файдалану ниндидер ребус чишүгә әвереләчәк.

Икенче яктан, төрки телләргә кардәш булмаган кайбер телләрнең сүзлекләрендә тикшерелә торган мәсьәләнең берникадәр хәл ителгәнлеген күрәбез. Болар, беренче чиратта, – безнең өчен яхшы аңлаешлы рус теленең аңлатмалы сүзлекләре. Д.Н. Ушаков редакциясендәге «Толковый словарь русского языка», С.И. Ожеговның «Словарь русского языка» кебек тулы типтагы аңлатмалы сүзлекләрдә грамматик формалар өчен сүзлек мәкаләсендә аерым зона бүленгән һәм кирәкле мәгълүмат шунда бирелгән. Мәсәлән, **МЫТЬ** сүзлек мәкаләсенең мондый зонасында түбәндәге мәгълүмат бар:

– **вымыть** һәм **помыть** тәмамланган төр (совершенный вид) формалары һәм аларның төрләнеш үзенчәлекләре турында мәгълүмат;

– **мыться** кайтым юнәлеше формасы һәм шуннан ясалган тәмамланган төр формалары **вымыться** һәм **помыться**;

– баш сүзнең тиешле мәгънәләреннән барлыкка килгән исемнәр **мытьё** һәм **мойка**;

– ниһаять, **моечный** сыйфаты.

Бу зонада күрсәтелгән формалар, кагыйдә буларак, шулай ук вокабулалар буларак та тәкъдим ителгән, һәм өстәмә мәгънәләре булмаса, алардан **МЫТЬ** сүзенә сылтама бирелгән [Ожегов, 2003].

Мондый очракта кулланучы телдә булган барлык сүз формаларын һәм аңардан ясалган яңа сүз формаларын сүзлектән таба ала. Чөнки бит, мәсәлән, тулы типтагы аңлатмалы сүзлектә фигыльнең теге яки бу юнәлеш формасы булмавы бу форманың гомумән булуын шик астына куя.

Төрки телләр өчен андый зонаның булуы иң уңышлы вариант булыр иде дип уйлыйбыз. Мондый зона булганда, телдәге барлык формаларны, аларның һәр мәгънәсен тасвирлап бирүнең кирәге калмас иде.

Ничек кенә булмасын, татар теленең һәм башка төрки телләрнең аңлатмалы сүзлекләрендә берничә йөкләтү кушымчасы булган фигыльләрне һәм гомумән фигыльләрнең юнәлеш формаларын бирү мәсьәләсе җентекле анализ таләп итә. Яңа сүзлекләр төзегәндә фигыльнең барлык юнәлеш формаларын да исәпкә алуны телнең тулылыгын чагылдыру ягыннан әһәмиятле үзенчәлек дип саныйбыз, чөнки һәр фигыльгә юнәлешләрнең һәр формасы да хас түгел. Аларның булуы яки булмавы һәр аерым милли телнең аңлатмалы сүзлекләрендә расланырга яки кире кагылырга мөмкин.

**Әдәбият**

*Зиннатуллина К.З.* Залоги глагола в современном татарском литературном языке. Казань: Татар. кн. изд-во, 1969. 232 с.

Инструкция по составлению татарско-русского словаря полного типа (в трех томах). Казань, 1982. 88 с.

*Ожегов С.И., Шведова Н.Ю.* Толковый словарь русского языка. 4-е изд., дополненное. М.: ООО «ИТИ Технологии», 2003. 944 с.

Понудительный залог от переходных глаголов. Электронный ресурс: https://turkilan.readymaker.ru/lessons/forced_voice_from_transitive_verbs (мөрәҗәгать көне: 15.08.2023).

Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков. Морфология. М.: Наука, 1988. 560 с.

Татар грамматикасы: өч томда. Т. II. Морфология. М.: Инсан, Казан: Фикер, 2002. Б. 224–254.

Татар грамматикасы: өч томда. Т. II. Морфология. Тулыландырылган 2 нче басма. Казан: ТӘһСИ, 2016. Б. 186–208.

Татарская грамматика: в 3-х т. Т. II. Морфология. Казань: Татар. кн. изд-во, 1993. 397 с.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: 6 томда. Т. I (А–В). Казан: ТӘһСИ, 2015. 712 б.

*Хисамова Ф. М.* Татар теле морфологиясе: югары уку йортлары өчен д-лек. 2 нче басма. Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. Б. 209–216.

***Сәфәров Ринат Таһир улы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикография бүлеге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре, бүлек мөдире*

УДК 81'374

***О.Н. Галимова***

# ТЕРМИНОЛОГИЯНЕҢ ҮСЕШ КҮРСӘТКЕЧЕ БУЛАРАК ТАТАР ТЕЛЛЕ «ВИКИПЕДИЯ»

В статье исследуются названия животных, употреблённых в статьях «Википедии»: рассматриваются проблемы подбора иноязычному зоониму эквивалента на родном языке, синонимия терминов, заимствования, диалектизмы. Как показывает анализ, «Википедия» на татарском языке является ещё одним доказательством развития терминосистемы на современном этапе, в основном, за счёт заимствований и калек.

**Ключевые слова:** термин, терминология, названия животных, Интернет, зооним, татарский язык.

The article examines animal names in Wikipedia articles: they examine the problems of foreign-language zoonym equivalent choosing in their native language and synonymy of terms, borrowing and dialectisms. As the analysis shows, Wikipedia in the Tatar language is another proof of the development of the terminology system at the present stage, mainly due to borrowing and loan translation.

**Keywords:** term, terminology, animal names, Internet, zoonym, Tatar language.

Билгеле булганча, «Википедия» популяр мәгълүмат чыганагы булып тора. Ул кулланучыга энциклопедик стильдә тәкъдим ителә. Аның тагын бер отышлы ягы – мәгълүматның төрле телләрдә бирелүе. Татар кешесе дә мондагы аерым өлкәләргә караган материал белән ана телендә таныша ала. Биредә тупланган информация белгечләр тарафыннан бик үк ышанычлы дип саналмыйча, өстәмә материаллар белән ныгытылырга тиеш дип табылса да, ул милли телләрнең Интернетта урын алуы ягыннан игътибарга лаеклы дип уйлыйбыз. «Википедия» мәкаләләренең сыйфаты мәсьәләсе яңалардан саналмый. Мөһим бәяләү критерийларыннан актуальлек, ышанычлылык, объективлык, тулылык, релевантлык, стиль, укылу-укылмау дәрәҗәсен күрсәтергә мөмкин [Дрибас]. Энциклопедик характерда булганга, мәкаләләргә махсус атамаларның мул кулланылуы хас. Терминнарның ана телендәге дөрес эквивалентын бирү мәгълүматның ышанычлылыгын, укылу дәрәҗәсен күтәрә.

Тәкъдим ителгән мәкаләдә «Википедия»нең татарча мәкаләләрендә хайван атамаларының һәм классификация терминнарының кулланылуы каралачак. Әлеге мәсьәлә Интернет чорында милли телләрнең үсешен өйрәнү, Интернетта кулланылу үзенчәлекләрен билгеләү ясслыгында актуаль яңгырый, чөнки электрон аралашу технологияләре һәм Интернет үсешенең милли телләргә йогынтысы зур [Тарса, 2014, с. 288; Петрухина, Дедов, 2019, с. 139]. Галимнәр Интернетта-

гы мәгълүматны да лингвистик материал буларак куллану кирәклеген ассызыклыйлар. Мәсәлән, М.Эпштейн бөтендөнья челтәренең яңа сүзләрне мизгел эчендә күпсанлы кулланучыларга җиткерүен әйтә, ә инде бу сүзнең кулланылу ешлыгын күзәтеп бару аның уңышлы яки уңышсыз булуын ачыкларга ярдәм итә дип саный [Эпштейн, 2006]. Е.В. Петрухина һәм О.В. Дедов Интернеттагы тел материалларын өйрәнүнең телне динамикада күзәтү мөмкинлеген бирүен әйтәләр [Петрухина, Дедов, 2019, с. 139–140].

Хайван атамаларының Интернетта махсус текстларда кулланылуы татар телендә беренче тапкыр өйрәнелә, бу – хезмәтнең яңалыгы. Анда зоология терминологиясенең яңа атамалар белән баюы, диалекталь атамалар һәм терминнар, терминнарның синонимлыгы мәсьәләләре карала. Анализ өчен материаллар «Википедия»дә урнаштырылган мәкаләләрдән системалы рәвештә хайваннар дөньясын классификацияләүгә (патшалык, тип, астип, класс, отряд, семьялык, ыруг, төр) нигезләнеп алынды. Шул рәвешле, хайваннар, хордалылар, умырткалылар, имезүчеләр һ.б. классификация терминнары һәм төр атамалары һәм шул терминнар белән аталган мәкаләләрдә очраган зоонимнар, шулай ук казылдык хайван атамалары каралды. Алар сүзлекләр, фәнни, фәнни-популяр әдәбияттагы атамалар белән дә чагыштырылды.

Хайван атамалары турындагы татарча мәкаләләргә күзәтү аларның өч типта булуын күрсәтә:

– татар телендә булган чыганакларның күчермәсе;

– татар телендәге чыганаклардан төзелгән мөстәкыйль мәкалә. Боларда чыганак буларак мәктәпләр өчен төзелгән биология дәреслеге (Захаров В.Б., Сонин Н.И. Биология. Тере организмнарның күптөрлелеге = Биология Многообразие живых организмов. – 7 нче басма. – М.: Дрофа, 2003.), «Татар энциклопедиясе», И.И. Рәхимов һәм К.К. Ибраһимованың «Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы» (Казан, 2007) китабы, «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге» (20015– 2021) кулланылган;

– чит (рус) телдәге мәкаләнең яисә чыганакларның тәрҗемәсе.

Татар телендәге чыганакларны күчерү һәм татар телендәге чыганакларны кулланып, мөстәкыйль мәкалә төзү юлы белән эшләнгән мәкаләләрдә хайван һәм классификация атамаларының, кагыйдә буларак, хаталы кулланылышы күзәтелми. Аларда, рус телендәге мәкаләләрдән аермалы буларак, Татарстан территориясенә хас төрләр турында мәгълүмат та булырга мөмкин. Мәсәлән, «Инфузорияләр»мәкаләсендә [Инфузорияләр] шундый информация бар. Әлбәттә, мондый мәкаләләр рус телендәге мәкаләләр белән чагыштырганда мәгълүматны, бер яктан, азрак бирә (мәсәлән, татар телендәге материалда атаманың этимологиясе ачыкланмый, систематика китерелми, соңгысы, үз чиратында, русча атамаларның татарча эквивалентларын булдыру кирәклеге мәсьәләсен дә китереп бастыра), икенче яктан, җирле материал белән аерылып тора.

Чит телдән тәрҗемә ителгән мәкаләләрдә терминнар мәсьәләсе бераз катлаулана. Терминологиясе әле тиешле дәрәҗәдә эшләнеп бетмәгән өлкәләр турындагы текстларда рус телендәге атамаларның татар эквивалентларын хаталы тәкъдим итү күзәтелә. Мисал өчен, «Динозаврлар» мәкаләсендә *птицетазовые* һәм *ящеротазовые* классификация атамалары ялгыш *кош ләгәнлеләр* һәм *кәлтә ләгәнлеләр* дип калькалаштырылган [Динозаврлар], гәрчә русча *таз* сүзенең татар телендәге эквиваленты *оча* булса да. «Сөйрәлүчеләр» мәкаләсендә әзер терминны кулланмыйча, калька ясап яңасын булдырырга тырышу күзәтелә. Терминнар системасында инде үз урынын алган, сүзлекләргә теркәлгән, дәреслекләрдә кулланыла торган, *тәңкәтирелеләр* термины урынына *тәңкәлеләр* сүзе тәкъдим ителә [Сөйрәлүчеләр]. Мондый очраклар терминологияне чуарлый, аның төзеклегенә зыян китерә.

Әзер мәкаләләр саны азрак булу сәбәпле, һәр очракта да сылтамалар аша керү мөмкинлеге чикләнгән, бигрәк тә классификация терминнарының сылтамалары еш кына актив түгел. Ләкин белгән атамалар нигезендә күп кенә хайваннар һәм аларның төрле төркемнәре турында байтак мәгълүмат табып була. Мәсәлән, «Имезүчеләр» мәкаләсендә *умырткалылар*, *бүре, юлбарыс, сусар, кәҗә, антилопа, тиен, байбак, тычкан, кәҗә, антилопа, болан, беренчел җәнлекләр, клоакалылар, берьюллылар, чын җәнлекләр, сумкалылар, плаценталылар* атамалары [Имезүчеләр], «Чыпчыксыманнар» мәкаләсендә *купшыл, күкшә, саескан, урман тургае, камыш чыпчыгы, сыерчыклар, песнәкләр, нарат чыпчыклары, чебенче кошлар, чәберчекләр, ал сыерчыклар, яр* һәм *шәһәр карлыгачлары, кара каргалар, чыпчыклар, миләш чыпчыклары, козгын, ала карга, кара карга, саесканнар, кимерүчеләр, бакалар* атамалары кулланылган [Чыпчыксыманнар]. Аларның күпчелеген татар кулланучысы яхшы белә. Шунысы да әһәмиятле: «Википедия» яңа терминнар да тәкъдим итә яисә чагыштырмача яңа, әле махсус сүзлекләргә дә теркәлмәгән атамаларның кулланылышын арттыру, аларны активлаштыру вазифасын да үти. Мисал өчен, «Татар энциклопедиясе»ндә бирелгән *кабырчыклы амёбалар, иркен йөзүче керфеклеләр, беркетелүче имүчеләр* кебек атамаларны куллана. Сирәк яисә искерәк чыганакларда гына булган атамалардан файдалану да терминологияне татарчалаштыруга хезмәт итә. Мисал өчен, грек теленнән алынма *хамелеон* сүзе чыганакларның күпчелегендә бар: «Биологиядән русча-татарча аңлатмалы сүзлек»тә [Биологиядән русча-татарча аңлатмалы сүзлек, 1998, с. 602], биология дәреслегендә [Биология, 2017, с. 124] әлеге сүз «тиресенең төсен үзгәртергә сәләтле кәлтәсыман сөйрәлүче хайван» мәгънәсендә теркәлгән. Аның татар эквиваленты *соран* «Татарча-русча сүзлек»тә [Татарско-русский словарь, 2007, с. 246], Р. Әхмәтьяновның «Татар теленең этимологик сүзлеге»ндә [Әхмәтьянов, 2015, с. 168], Д. Тумашеваның «Себер татарлары диалекты сүзлеге»ндә [Тумашева, 1992, с. 192] табыла. Бу рептилионим «Википедия»дә «Сөйрәлүчеләр» мәкаләсендә

дә кулланылган [Сөйрәлүчеләр]. «Кимерүчеләр» мәкаләсендә «карчыга кошлар семьялыгыннан куе көрән төстәге кечерәк ерткыч кош» мәгънәсендә *көчегән* (рус. *подорлик*) орнитонимы бар [Кимерүчеләр]. «Җир-су хайваннары» мәкаләсендә русча *червяга* сүзенә эквивалент буларак *селәүчән* сүзе тәкъдим ителә [Җир-су хайваннары]. Ул, билгеле булганча, *суалчан* сүзенең фонетик варианты булып тора һәм диалектларда «яңгыр суалчаны», «бабасыр» мәгънәләрендә таралган [Татар теленең зур диалектологик сүзлеге, 2009, с. 570]. Сүзлекләрдә, фәнни-популяр әдәбиятта «Африка, Азия һәм Америка тропикларында яшәүче, тышкы кыяфәтләре белән эре яңгыр суалчанына охшаш аяксыз җир-су хайваны» мәгънәсендә *суалчансыман амфибия* атамасы очрый [Азбука природы, 2001, с. 79]. Ул тәкъдим ителгән атамадан озынрак, әмма *селәүчән* сүзе татар телендә әйтеп үтелгән мәгънәләрдә актив кулланылуы сәбәпле, аны терминнар системасына яңа мәгънәдә беркетү уңышлы булмас.

Мәкаләләрдәге зоонимнарны өйрәнү аларда әле яңа калькалаштырылган яки чит телдән алынган атамаларның булуын күрсәтә: *ак муенлы карга*, *Сомали каргасы, куак козгыннары, акантодлар, плакодермнар* һ.б. Казылдык хайван атамаларының исә «Википедия»дә бары алынмалары гына кулланылган. Мәсәлән, *платеозавр мусзавр, синозавроптерикс.* Бу өлкәгә караган классификация терминнарының да чит тел нигезләреннән ясалуы мәгълүм: *целурозаврлар, птерозаврлар, липидозаврлар, герререзаврлар, сальтопуслар, синтарзуслар, тератозаврлар* һ.б. [Динозаврлар]. Болар исә терминологиянең бүгенге көндә алынмалар һәм калькалар хисабына баюына бер дәлил булып тора.

Кайбер урыннарда, татарча атаманы бирмичә, бары латинчасын гына куллану очраклары күзәтелә. Әлеге күренеш фәнни стильгә яисә терминологиясе эшләнеп бетмәгән, әле үсү этабында булган өлкәләргә хас.

«Википедия» синонимик атамаларны теркәү ягыннан да игътибарга лаек. Хәзерге чорда терминологиядә синонимик «шартлау» күзәтелә [Лаптев, Татаринов, 2000, с. 70]. Галимнәр аны объект турындагы фәнни белемнәрнең күләме арту һәм фән үсешенең законлыклы нәтиҗәсе дип саныйлар [Лейчик, 2006, с. 98–106]. Татар телендә хайван атамаларының да, классификация терминнарының да мәгънәдәшләре бар. Хайваннарның систематик категорияләре фәндә еш кына дублетлар белән атала: *имезүчеләр – җәнлекләр, инфузорияләр – керфеклеләр, җир-су хайваннары – амфибияләр, сөйрәлүчеләр – рептилияләр, кильсөяклеләр – оча торганнар, кильсөяксезләр – йөгерә торганнар, йөзә торганнар – пингвиннар* һ.б. «Википедия»дә дә мондый очраклар киң чагылыш тапкан, шул исәптән татар телендә кулланыла торган синонимик хайван атамаларын да чагылдыру омтылышы күзәтелә. Әмма мәгънәдәш булмаган сүзләрне мәгънәдәш дип теркәү, ялган синонимия очраклары да бар. Мәсәлән, «Бакыр елан» мәкаләсендә баш сүзгә синоним итеп *шома*

*тузбаш* серпентонимы китерелә [Бакыр елан]. Ләкин бу терминнарның беренчесе сүзлекләргә рус телендәге *медянка* сүзенең эквиваленты буларак теркәлгән, икенчесе русча *уж гладкий* атамасының тәрҗемәсе була.

Шул рәвешле, татар телле «Википедия» әле камил дәрәҗәдә түгел. Атамаларны кулланудагы хаталар да шул турыда сөйли. Мәкаләләрне терминологик яссылыкта өйрәнү аның терминологиясе әле эшләнеп бетмәгән өлкәләрне ачык чагылдыруын күрсәтә. Шунысы да әһәмиятле: ул әлеге өлкәләрдә яңа атамалар тәкъдим итә. «Википедия» бүгенге көндә терминологиянең, нигездә, алынмалар һәм калькалар хисабына баюын тагын бер кат дәлилли. Ул әзер атамаларны гына түгел, гомумән татар телен уңайлы, үтемле форматта кулланучыга тәкъдим итү юлы булып тора һәм шуңа да зур игътибар сорый.

**Әдәбият**

Азбука природы: Рыбы. Земноводные. Пресмыкающиеся. Русско-татарский, татарско-русский словарь биологических терминов / сост.: А.Б. Халидов, В.И. Гаранин. Казань: Магариф, 2001. 79 с.

*Әхмәтьянов Р.Г.* Татар теленең этимологик сүзлеге: 2 томда. 2 т.. Казан: Мәгариф – Вакыт, 2015. 567 б.

Бакыр елан. URL: https://tt.wikipedia.org/wiki/Бакыр_елан (мөрәҗәгать көне: 8.09.2023).

Биологиядән русча-татарча аңлатмалы сүзлек / ред.: Ф.Г. Ситдиков, Р.К. Зәкиев. Казан: Мәгариф, 1998. 655 б.

Динозаврлар. URL: https://tt.wikipedia.org/wiki/Динозаврлар (мөрәҗәгать көне: 28.08.2023).

*Дрибас Л.* Использование «Википедии» в научной работе: быть или не быть // Молодой учёный. URL: https://moluch.ru/information/wiki (мөрәҗәгать көне: 28.08.2023).

Җир-су хайваннары. URL: https://tt.wikipedia.org/wiki/Җир-су_хайваннары (мөрәҗәгать көне: 8.09.2023).

Имезүчеләр. URL: https//tt.wikipedia.org/wiki/Имезүчеләр (мөрәҗәгать көне: 8.09.2023).

Инфузорияләр. URL: https://tt.wikipedia.org/wiki/Инфузорияләр (мөрәҗәгать көне: 28.08.2023).

Кимерүчеләр. URL: https://tt.wikipedia.org/wiki/Кимерүчеләр (мөрәҗәгать көне: 8.09.2023).

*Лаптев В.Д., Татаринов В.А.* Новые пути описания терминологии // Терминологический вестник. М.: Московский лицей; Русский филологический вестник, 2001. № 1. С. 68–71.

*Латюшин В.В., Шапкин В.А.* Биология: Хайваннар. 7 сыйныф: татар телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен д-лек. Казан: Татар. кит. нәшр., 2017. 304 б.

*Лейчик В.М.* Терминоведение: предмет, методы, структура. М.: КомКнига, 2006. 256 с.

*Петрухина Е.В., Дедов О.В.* Интернет как источник лингвистической информации для изучения динамики русского словообразования // Вестн. Том. гос. ун-та. Филология. 2019. № 57. С. 137–159.

Сөйрәлүчеләр. URL: https://tt.wikipedia.org/wiki/Сөйрәлүчеләр (мөрәҗәгать көне: 8.09.2023).

*Тарса Я.* Интернетовские словари жаргона как источник информации для лексикографа // Проблемы истории, филологии, культуры. 2014. № 3. С. 288–289.

Татарско-русский словарь: в 2-х т. Т. 2. «Т.» (М–Я). Казань: Магариф, 2007. 726 с.

*Тумашева Д.Г.* Словарь диалектов сибирских татар. Казань: Казанский университет, 1992. 256 с.

Хайваннар. URL: https://tt.wikipedia.org/wiki/Хайваннар (мөрәҗәгать көне: 8.09.2023).

Чыпчыксыманнар. URL: https://tt.wikipedia.org/wiki/Чыпчыксыманнар (мөрәҗәгать көне: 8.09.2023).

*Эпштейн М.* Русский язык в свете творческой филологии разыскания // Знамя, 2006. № 1. URL: https://magazines.gorky.media/znamia/2006/1/russkij-yazyk-v-svete-tvorcheskoj-filologii-razyskaniya.html (мөрәҗәгать көне: 29.08.2023).

***Галимова Ольга Николаевна,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикография бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 81′282

***А.Я. Хөсәинова***

# ТАТАР ТЕЛЕНДӘ ТЕЛ АЛДЫ /ʒ/ СИБИЛЯНТЫ ҺӘМ ТЕЛ УРТАСЫ /J/ СОНАНТЫНЫҢ ҮЗАРА БӘЙЛӘНЕШЕ

В данной статье анализируются особенности бытования переднеязычного консонанта /ʒ/ и среднеязычного сонанта /j/ в татарском литературном языке и его диалектах. Прослеживаются вопросы первичности /ʒ/ и /j/. Рассматриваются примеры употребления данных согласных в диалетных лексемах, где они занимают различные позиции в слове..

**Ключевые слова**: сибилянт /ʒ/, сонант /j/, соотношения звуков, диалектная фонетика, татарские диалекты.

This article analyzes the peculiarities of the existence of the anterior-lingual consonant ʒ and the middle-lingual sonant j in the Tatar literary language and its dialects. The questions of primacy of ʒ and j are traced. Examples of the use of these consonants in dialect lexemes, where they occupy different positions in the word, are considered.

**Keywords:** sibilant ʒ, sonant j, sound ratios, dialect phonetics, Tatar dialects.

Бүгенге көндә төрки телләрнең тартыклар системасы гомуми планда тулысынча өйрәнелгән дип әйтергә мөмкин. Шул ук вакытта аерым төрки телләрнең, шул исәптән татар теленең дә, консонантизмы билгеле бер аспектларда тиешле дәрәҗәдә тикшерелмәгән дияргә дә нигез бар. Мәсәлән, татар диалектлары тартыклар системасының формалашу һәм үсеш тарихы белән бәйле кайбер мәсьәләләр әле дә ачык килеш кала бирә.

Татар гомумхалык теленең консонантизм системасы үзенчәлекле бер күренеш тәшкил итә. Биредә аерым фонемаларны тикшерү, аларның әдәби телдә һәм диалектларда чагылышын билгеләү, тартыкларның үзара тәэсирен, сузыклар белән бәйләнешен анализлау тел белеменең актуаль юнәлеше булып тора. Әлеге мәкаләдә татар әдәби телендә һәм аның диалектларында /ʒ/ һәм /j/ тартыкларының кулланылу үзенчәлекләрен чагыштырма планда өйрәнү максаты куелды. Биредә авазлар транскрипциясен бирүдә без халыкара фонетик алфавит билгеләрен кулландык.

/j/ сонантының беренчел булу проблемасы тюркологиядә, аерым алганда, татар тарихи лингвистикасында төп мәсьәләләрнең берсе санала. Борынгы төрки телләрдә башлангыч позициядә тартыкларның түбәндәге тәңгәлләшүе күзәтелә: /j/ ~ /ʒ/ ~ /d/ ~ /č/. Кайбер галимнәр (В.А. Богородицкий, Н.З. Гаджиева, В.В. Радлов һ.б.) /j/ авазы – беренчел, ә /ǯ/, /ž/, /č/, /z/, /s/ сонантлары – *j* ава-

зының үсеш вариантлары, дип саный [Богородицкий, с. 106–107], чагыштырыгыз, татар телендә *jaqa/ʒaqa* (воротник) бабатөрки телендә *jaka* (ворот, край); татар телендә *ʒep/jep* (нитка), бабатөрки телендә **jɨp/*jip* (нитка) һ.б. Башка кайбер галимнәр (Г. Дерфер, А.В. Дыбо, К.Г. Менгес, О.А. Мудрак һ.б.) фикеренчә, борынгы төрки /j/ гомумалтай /ǯ/ яки /d́/ дан үсеш алган [Сравнительно-историческая..., 1984, с. 261, 256–259], чагыштырыгыз, татар телендә *bijY* (бию), бабатөрки телендә *bYdi-* (танец); татар телендә *øjlæ* (обеденное время, середина дня), борынгы төрки телдә *ød, øδ* (небольшой отрезок времени) һ.б.

Төрки телләр чагыштырма-тарихи грамматикасының алтынчы томында тикшеренүчеләр түбәндәге нәтиҗәгә киләләр: анлаут позициядә традицион рәвештә реконструкцияләнгән төрки */j/ бабатөрки */ʒ/, /č/ анлаутының фонологик вариантына туры килә. Бу борынгы төрки телдә сүзнең абсолют башында шаулы тартыклар гына булу һәм күпчелек төрки телләрдә сонант башлангычны кулланмау белән аңлатыла [Сравнительно-историческая..., 2006, с. 25].

Н.А. Баскаков төрки анлаутта /j/ фонемасының тотрыксыз характерга ия булуын билгели: төрки телләрдәге */j-/* фонемасына анлаут позициядә юкка чыгу күренешләре хас [Баскаков, с. 50].

Л. Җәләй үзенең хезмәтләрендә /j/~/ʒ/ консонантларның гомумтөрки телдәге вариатив кулланылышы иң элек XI гасырга караган язма истәлекләрдә күзәтелүен ассызыклый. Шулай ук автор, аерым фактларга нигезләнеп, /ʒ/ның татар теленә болгар теленнән күчкәнлеген раслый, һәм, аныңча, /j/ – кулланылыш варианты гына түгел [Җәләй, б. 17]. Шулай итеп, автор /ʒ/ тартыгының мөстәкыйль рәвештә барлыкка килүен күрсәтә.

В. Хаков бу мәсьәләне түбәндәгечә дәлилли: /ʒ/ урынында /j/ куллану фактын кыпчак язма чыганаклары раслый; тюркологиядә /j/ фонемасының киң кулланылышы кыпчак телләренә хас, дигән фикер таралган [Хаков, б. 115].

Ф. Хисамова фрикатив, йомшак һәм җайлы әйтелә торган /ʒ/ тартыгы – татар теленең үзенчәлеге, дигән нәтиҗәгә килә [Хисамова, 2012]. Татар диалектологлары фикеренчә, әдәби телдә /j/ урынына /ʒ/ куллану – татар теле урта диалектының дифференциаль билгеләреннән берсе. Көнбатыш диалектның аерым сөйләшләрендә әдәби /ʒ/ га чыжылдаучы яңгырау /ǯ/ туры килә.

/ʒ/ авазы – шаулы, бер фокуслы, ярык, яңгырау. Татар сүзләрендә ул анлаутта да, инлаутта да очрый: мәсәлән, *җыр – ʒыр* (песня), *кәҗә – kəʒə* (коза). Ауслаутта ул бары тик алынма сүзләрдә генә кулланыла: *таҗ – таʒ* (корона).

Анлаутлы ярык /ʒ/ татар теле урта диалектының барлык сөйләшләрендә диярлек актив: *җаулык* (тат. әдәби яулык) – *ʒawlɯq*, *җаңгыр* (тат. әдәби яңгыр) – *ʒaNgɯr*, *җапрак* (тат. әдәби яфрак) – *ʒapraq*, *җалкын* (тат. әдәби ялкын) – *ʒalqɯn*, *җәшел* (тат. әдәби.

яшел) – *ʒœшɛl*, *жҫөгерә* (тат. әдәби йөгерә) – *ʒøgɛrœ* һ.б. Урта диалектның аерым сөйләшләрендә ярык /ʒ/ сүз уртасында да барлыкка килә: *Мәрьжҫәм* (тат. әдәби Мәрьям) – *Мœрʒœм* (Марьям), *Ильжҫә* (тат. әдәби Илья) – *Ilʒœ* (Илья), *аржҫак* (тат. әдәби аръяк) – *арʒaq* (другая сторона), *алжҫу – alʒu* һ.б. (керәшен татарлары сөйләше).

/ʒ/ тартыгы диалекталь /ǯ/ (дж) аффрикатының вариантларыннан йомшаклыгы һәм әйтелеш төсмерләре белән аерыла: *жҫәй – ʒœj* (лето), *жҫил – ʒil* (ветер), *жҫир – ʒir* (земля) һ.б. /ǯ/ авазының әлеге диалекталь варианты, нигездә, көнбатыш диалектның (кузнецк, ләмбрә һ.б. сөйләшләр), шулай ук урта диалектның кайбер сөйләшләренә хас: *джҫерәк* (тат. әдәби йөрәк) – *ǯɛrœk* (сердце), *джҫаулык* (тат. әдәби яулык) – *ǯaulшk* (платок), *джҫефәк* (тат. әдәби ефәк) – *ǯɛфœk* (шёлк) һ. б.

Кайбер сөйләшләргә ике сузык аваз арасында /z̡/ ~ /ʒ/ чиратлашуы хас: *хужа – xuz̡a – xuʒa* (хозяин)*, бажа – baz̡a – baʒa* (свояк) һ.б.

/j/ авазы – палаталь ярык сонант. Позициясе чикләнмәгән. Сузык аваз белән кушылып, иҗексез сузык авазга күчә: *чәй – t͡ʃaj* (чай), *яхшы – jaxʂш* (хорошо) һ.б.

Татар әдәби телендәге башлангыч /j/ фонемасына урта диалектның күп кенә сөйләшләрендә, югарыда билгеләп үтелгәнчә, /ʒ/ тартыгы туры килә: *жҫул* (тат. әдәби юл) – *ʒul* (дорога), *жҫал* (тат. әдәби ял) – *ʒal* (отдых), *жҫегерме* (тат. әдәби егерме) – *ʒɛgɛrme* (двадцать) һ.б. Палаталь төркем лексемаларында /ʒ/ әйтелә: *жҫир – ʒir* (земля), *жҫиләк – ʒilœk* (ягода), *жҫилкән – ʒilkœn* (парус) һ.б.

Татар теленең көнбатыш диалектында борынгы төрки сүзләрдә /ʒ/ авазы юк, ә гарәп-фарсы алынмаларда /z̦/ аффрикаты кулланыла, югарыда китерелгән мисалларда /j/ әйтелә: *jir* (земля), *jilœk* (ягода), *jilkœn* (парус) һ.б.

Интервокаль позициядә /*j*/ саклана. Мәсәлән, татар әдәби телендә, урта диалектта *ajaq*, көнбатыш диалектта *ajak*. Татар сөйләшләрендә *aʒaq* яки *az̡aq* формаларының вариантлары бүгенге көндә теркәлмәгән диярлек. Шул ук вакытта аларның борынгы заманда да булуы ихтимал, моны *azaq* (ахыры) (шушы ук тамырга барып тоташа) кебек мисаллар дәлилли. Ү. Байчура билгеләп үткәнчә, татар әдәби телендә һәм диалектларында *аю – aju* (медведь), *койо – qojo* (колодец), *ияк – ijœk* (подбородок), *кием – kijɛm* (одежда) кебек сүзләрдә сакланган интервокаль /j/ күрше сузыкларның яңгыраш буенча ассимиляциясе белән аңлатыла. Хәзерге әдәби телдә фрикатив /ʒ/ һәм урта тел сонанты /j/ның кулланылу активлыгы бертигез. Бу уңайдан, тикшеренүчеләр фикеренчә, /j/ ~ /ʒ/ чиратлашуы, нигездә, тар тел алды авазлары алдында бара, ә киң авазлар алдында /j/ авазы саклана [Байчура, с. 126–128]. Ф. Хисамова /ʒ/ авазының киң һәм ярым тар сузыклар алдында да еш кулланылуын әйтә. Мәсәлән: 1) фрикатив /ʒ/ тар сузыклар алдында кулланыла: *жҫил – ʒil* (ветер), *жҫиләк – ʒilœk* (ягода), *жҫиң – ʒiŋ* (рукав), *жҫиңел– ʒiŋɛl* (легкий);

2) киң һәм ярым тар сузыклар алдында, нигездә, тел уртасы /j/ сонаты әйтелә: *ялкау – jalqfaw* (ленивый), *яңгыр – jaNgɯr* (дождь), *йолдыз – joldoz* (звезда), *ялкын – jalqɯn* (пламя), *яшел – ʒæşɛl* (зеленый), *югал – jugal* (исчезни) һ. б; в) шулай ук ярык /ʒ/ киң һәм ярым тар сузыклар алдында еш әйтелә: *җай – ʒaj* (повод, случай), *җайлы – ʒajlɯ* (удобный), *җәй – ʒæj* (лето), *җәйләw – ʒæjlæw* (долина, пастбище), *җылы – ʒɯlɯ* (теплый), *җуй – ʒuj* (потеряй, удали), *җәнлек – ʒænlɛk* (зверь), *җепшек – ʒɛpşɛk* (мокрый) һ. б. [Хисамова, 2012].

Баба төрки телдәге /ʒ́-(j-)/ тартыкларының рефлекслары булып /j-, ž-/ авазлары, диалектларда моннан тыш тагын ž́/[dʒ́] авазлары да тора. Мәсәлән, сүз башында әдәби телдәге /ʒ/ һәм /j/ авазларына *z* авазының тәңгәл килүе күзәтелә: *zøri* (тат. әдәби йөри) (ходит), *zasadɯ* – (тат. әдәби ясады) (изготовил, сделал), *zɯraq* – (тат. әдәби ерак) (далеко) һ. б. *z~j* тәңгәллеге ʒләштерү аша бара, ягъни j > ʒ > *з*. Бу күренеш, мәсәлән, казан арты керәшеннәре, минзәлә сөйләшләренең кайбер урынчылыкларында да очрый.

Шулай итеп, ʒләштерү күренеше урта диалектның төп дифференциаль билгеләреннән санала, казан арты сөйләшләрендә шактый системалы рәвештә чагыла, /j/ сонанты, нигездә, көнбатыш һәм көнчыгыш диалектларда кулланыла, дип нәтиҗә ясарга була. Шуңа карамастан, соңгы вакытта төрле диалект сөйләшләренең бер-берсенә йогынтысы һәм әдәби телнең аларга тәэсир итүе нәтиҗәсендә, татар теле диалектларында барлык позицияләрдә дә /ʒ/ һәм /j/ авазларының параллель кулланылышы күзәтелә. Мәсәлән, әдәби телнең йогынтысы нәтиҗәсендә, аеруча яшь буын телендә, хәзерге көндә ʒләштерүнең системалылыгы берникадәр югала бара. Бу хәл составында калын сузыклар булган сүзләргә карый: *ʒaulɯq/jaulɯq* (платок), *ʒul/jul* (дорога)*, ʒomşaq/jomşaq* (мягкий)*, ʒomorqa/jomorqa* (яйцо) һ.б.

Күргәнебезчә, сөйләшләрдәге тикшерелгән авазларның синхрон анализы уртак билгеләр барлыкка килүен, диалектларның үзара һәм татар әдәби теленә дә якынаюын күрсәтә.

**Әдәбият**

*Баскаков Н.А.* Историко-типологическая фонология тюркских языков / отв. ред. Э.Р. Тенишев. М.: Наука, 1988. 208 с.

*Байчура У.Ш.* Звуковой строй татарского языка. Ч. 1. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1959. 185 с.

*Богородицкий В.А.* Введение в татарское языкознание в связи с другими тюркскими языками. 2-е изд., испр. и доп. Казань: Татгосиздат, 1953. 220 с.

*Җәләй Л.* Татар теленең тарихи фонетикасы буенча материаллар. Казан: Таткнигоиздат, 1954. 108 б.

Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков: фонетика / отв. ред. Э.Р. Тенишев. М.: Наука, 1984. 488 с.

Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков. Пратюркский язык-основа. Картина мира пратюркского этноса по данным языка / под ред. Э.Р. Тенишева и А.В. Дыбо. М.: Наука, 2006. 912 с.

*Сулейманова Д.Д.* Историческая фонетика тюркских (башкирского, татарского) и баскского языков: сравнительно-сопоставительный анализ: дис. ... канд. филол. наук: 10.02.20. Уфа, 2016. 280 с.

*Хаков В.* Татар әдәби теле тарихы. Казан: Казан ун-ты нәшр., 1993. 325 с.

*Хисамова Ф.М.* История щелевых согласных ч (ç) и җ (ʒ) в татарском языке. 2012. [Электронный ресурс] Режим доступа: история щелевых.pdf - Яндекс. Документы (yandex.ru) (мөрәҗәгать көне: 11.09.23).

***Хөсәинова Алинә Җәмил кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының ареаль лингвистика бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 81'374

***Л.И. Яруллина***

# С. РАХМАНКОЛЫЙНЫҢ А.М. ГОРЬКИЙҺӘМ Ф.И. ШАЛЯПИН МУЗЕЕ ФОНДЫНДА САКЛАНА ТОРГАН «ТАТАРЧА-РУСЧА ЛӨГАТЬ» (1913) СҮЗЛЕГЕ

В фондах Музея А.М. Горького и Ф.И. Шаляпина хранится книжная коллекция, в которой есть труды, написанные на арабской графике. Этот материал, безусловно, является достаточно интересным объектом для изучения как в историко-культурном, так и в лингвистическом аспектах. Данная статья посвящена анализу одного из таких изданий, хранящегося в фондах музея. В работе рассматривается специфика передачи вокализма в татарско-русском словаре Султана Рахманкулый.

**Ключевые слова:** музейный фонд, коллекция, арабская графика, татарский язык, словарь, вокализм, графема.

In the Museum of A.M. Gorky and F.I. Chaliapin there is a book collection that contains works written in Arabic script. This material is of course quite an interesting object for study in both historical, cultural and linguistic aspects. This article is devoted to the analysis of one of these publications stored in the museum's collections. The work examines the specifics of the transmission of vocalism in the Tatar-Russian dictionary of Sultan Rakhmankuly.

**Keywords:** museum fund, collection, Arabic graphics, Tatar language, dictionary, vocalism, grapheme.

А.М. Горький һәм Ф.И. Шаляпин музее – Россиянең комплекслы профильле иң эре музейларының берсе. Ул күренекле рус язучысы, прозаик, драматург һәм җәмәгать эшлеклесе Алексей Максимович Горький (1868–1936) белән бөек рус артисты Федор Иванович Шаляпинның (1873–1938) тормышы һәм иҗатына багышланып, 1960 елдан федераль әһәмияткә ия булган тарихи һәйкәлләр реестрына кертелгән.

Музей үз фондында тарихи-мәдәни әһәмияткә ия булган 60 меңнән артык берәмлек саклый. Әйберләр фондында А.М. Горькийның, Ф.И. Шаляпинның мемориаль предметлары коллекциясе, татар язучыларының мемориаль истәлекләре һәм тарихи-көнкүреш коллекцияләре урын ала. Шулар арасында А.М. Горький белән Ф.И. Шаляпинның мемориаль предметлары коллекциясе аеруча зур әһәмияткә ия.

Фонд материаллары белән эш актуаль һәм гаять әһәмиятле юнәлешләренең берсен тәшкил итә. Ул үз эченә материаллар туплау, аларны барлау, саклау, теркәү, опись төзү кебек күптөрле процессларны ала.

Бүгенге көндә музей фондында, А.М. Горькийның һәм Ф.И. Шаляпинның мемориаль предметларыннан тыш, XIX гасыр ахыры – XX гасыр башына караган татарча фәнни хезмәтләр, сүзлекләр һәм матур әдәбият китаплары, газеталар һәм журналлар саклана. Музейга төрле елларда килгән әлеге язма мирас бүгенге көндә тулысынча диярлек системалаштырылган. Һәм ул шартлы рәвештә фәнни хезмәтләр, матур әдәбият әсәрләре, сүзлекләр, каталоглар, дини темага язылган китаплар, календарьлар дигән төрләргә бүленеп карала ала.

Музейда Г. Алпаровның «Хәреф вә имламыз» (1912), Г. Ибраһимовның «Татар сарыфы» (1915), «Имла, тел, әдәбият мәсьәләләре» (1924), Җ. Вәлидинең «Татар теленең грамматикасы» (1919), Һ. Максудиның «Төрки нәхүе» (1910), М. Корбангали, Г. Батталның «Ана теле методикасы» (1918) һ.б. фәнни китаплар саклана. Фондта урын алган сүзлекләрдән Г. Сәйфуллинның «Кечек лөгать» (1912), С. Җантуринның «Лөгать» (1911), С. Рахманкулов һәм Г. Кәрамның «Тулы рус-татар сүзлеге», С. Рахманколыйның «Татарча-русча лөгать» (1913) кебек хезмәтләрен атап үтәргә кирәк.

Болардан тыш музей фондында Г. Тукай, З. Бәшири, Һ. Такташ, Г. Ибраһимов, Г. Исхакый, Г. Коләхмәтов, Н. Думави, Ф. Әмирхан, С. Габделрәхимов, З. Кәримия, М. Гафуриларның «Үрнәк», И.В. Ермолаев, И.Н. Харитонов, Б.Л. Домбровский, бертуган Кәримовлар, Л.П. Антонов лито-типографияләрендә, «Мәгариф», «Өмид», «Милләт» матбагаларында гарәп графикасында дөнья күргән китаплар да саклана. Гомумән, музей фондындагы китаплар игътибарны үзләренең тематик төрлелекләре белән дә җәлеп итәләр.

Тел тарихы һәм татар тормышын диахроник яссылыкта өйрәнүчеләр өчен кызыклы чыганаклар саналган, XX гасыр башына караган гарәп графикасындагы газета-журналлар музей фондының аерым бер өлешен тәшкил итә. Алар арасында «Тәрҗемән» (1904. № 92, № 41, № 89), «Вакыт» (1907. № 204; 1910. № 581, № 618, № 674, № 693, № 695), «Йолдыз» (1909. № 412; 1915. № 1495, № 1490), «Аң» (1913. № 7, № 8, № 11, № 12; 1916. № 2, № 3), «Мәгариф» (1919. № 3; 1923. № (11) 1, № (12) 2, № (20–19) 10–9; 1924. № 1–2), «Сөембикә» (1914. № 21; 1915. № 4; 1916. № 5, № 8, № 9, № 10, № 12, № 13, № 20–21, № 22, № 23, № 24; 1917. № 11–12), «Шура» (1909. № 1–24) һәм башка газета-журналлар теркәлгән. Гомумән, фондта саклана торган мондый материаллар шактый кызыклы өйрәнү-тикшерү объектлары булып торалар һәм бай фактик материал туплауда ярдәм итәләр.

Китап фонды коллекциясендә аерым игътибар сораган шактый кызыклы хезмәтләрнең берсе – Солтан Рахманколыйның «Татарча-русча лөгат»е (1913).

С. Рахманколый, беренче чиратта, укучыга тәрҗемәче һәм журналист буларак билгеле [Бәширов, б. 157–159]. Тәрҗемә эшенә 1907 елдан керешкән автор А.С. Пушкиннан «Дубровский», «Алеко, яки Чегәннәр», «Борис Годунов», И.С. Тургеневтан «Яһүди», «Төтен», В.

Гюгодан «Вөждан газабы», шулай ук «Телләр тарихы», «Хәйванат» кебек фәнни-популяр жанрдагы әсәрләрне дә тәрҗемә итеп бастыра.

Солтан Рахманколый – татар мәгарифе өлкәсенә дә зур өлеш керткән шәхес. Аның «Татарча-русча лөгат»е, 210 битлек булып, 1913 елда Казанда И.Н. Харитонов лито-типографиясендә дөнья күрә. Автор әлеге басманың кереш сүзендә болай дип яза: «Бундан ике ел мәкъдам рус әлифбасы тәртибилә, ягъни рус сүзләренә татарча мәгънә бирелүб, “Русча-татарча мөкәмәл лөгать” китабы дөньяга чыкмыш иде. Бу лөгать китабы буенча татар сүзләренә русча мәгънә табу мөмкин булмыйча, рус сүзләренә татарча мәгънәләре генә табыладыр. Хәлбукә, рус сүзләренә татарча мәгънәләрен белү һәрвакыт кирәкле эш булган шикелле, татар сүзләренә русча мәгънә табу да атлаган саен тугры килмәкдәдер. Бенаэ галиә бу ихтияҗны йиңеләйтү ниятилә, татар әлифбасы тәртибилә татар сүзләренә русча мәгънә бирелүб, 10000 сүзне хавый ошбу «Татарча-русча лөгать китабы» язылды. Китабда ят лисанләрдән мәэхуз булган сүзләрнең кайсы телдән алынганлыклары күрсәтелде» [Рахманколый, б. 2].

Сүзлек үз эченә кеше тормышының төрле өлкәләренә караган, чоры өчен актуаль һәм шактый актив булган лексик берәмлекләрне ала. Әлеге хезмәт сүз һәм мәгънә җәһәтеннән генә түгел, ә лексик берәмлекләрнең язылыш үзенчәлекләре нисбәтеннән дә игътибарга лаек. Шул сәбәпле «Татарча-русча лөгать» китабында вокализмның бирелешенә берникадәр тукталып үтәргә булдык.

С. Рахманколыйның сүзлегендә сузык авазларны язуда бирү өчен, ی , وُ , و , ه , ا графемалары һәм او ,ای ,اوُ ,ئه диграфлары кулланыла.

Мәдле әлиф (**آ**) абсолют сүз башында килә һәм язуда **[а]** авазын гына күрсәтә: آباغا (абага – папоротникъ) (б. 3), آتا-آنا (ата-ана, родители) (б. 4), **آچلق** (ачлык – голодъ) (б. 5), **آداش** (адаш – одноименецъ, однофамилецъ), **آغاچ** (агач – дерево) (б. 13), **آغم صو** (агымсу – река, проточная вода) (б. 14), **آق قوش** (аккош – лебедь), **آقلق** (аклык – чистота) (б. 15), **آلطن** (алтын – золото) (б. 16), **آلماغاچ** (алмагач – яблоня), **آنالق** (аналык – материнство) (б. 17), **آول** (авыл – деревня) (б. 19), **آیرلمق** (аерылмак – разлучаться) (б. 20).

Мәдсез әлифнең (**ا**) вазифалары күбрәк булып, ул түбәндәге авазларга билге булып йөри. Сүз башында: **[а]** – **الماشو** (алмашу – обмен, размен) (б. 17), **ایرم** (аерым – отдельно), **ایراتا** (аерата, хосусый – особенно, исключительно), **ایرلو** (аерылу – разлука), **ایغر** (айгыр – жеребец) (б. 20). **[ә]** – **اخلا قلی** (әхлаклы – нравственный) (б. 22), **الفبا کتابی** (әлифба китабы – азбука) (б. 26). **[э]** – **ات بالاسی** (эт баласы – щенок, собачёнка), **اتمك** (этмәк – толкать, толкнуть), **اچکی** (эчке – внутренний) (б. 21), **اچمك** (эчмәк – пить) (б. 22), **ارله وچی خاتون** (эрләүче хатын – пряха) (б. 23), **المك** (элмәк – вешать, повесить) (б. 26). **[и]** – **اثبات قیلمق** (исбат кылмак – доказать, доказывать) (б. 21), **اختیارلی** (ихтыярлы – вольный, самостоятельный) (б. 22), **اسم** (исем – имя) (б. 24). **[ы]** – **اچقندرمق** (ычкындырмак – отцеплять, выпустить), **اچقنمق** (ычкынмак – отцепляться, слетать, вылетить) (б. 22), **ارغاق** (ыргак – крюк, крючок),

**ارم** (ырым – суеверный, обычай, суеверие), **ارمچی** (ырымчы – колдунъ), **ازغش** (ызгыш – ссора, спор) (б. 23), **اشانمق** (ышанмак – верить, доверять) (б. 24). **[о]** – **الوغلق** (олуглык – гордость, высокомерие) (б. 27) **[ө]** – **امید** (өмид – надежда, вера) (б. 27).

Сүз уртасында ا **[а]** һәм **[ә]** авазларын белдерә. Мисал өчен, **آلباصتی** (албасты – домовой) (б. 15), **اورمانلق** (урманлык – лес, леса, лесистая местность), **اورناشمق** (урнашмак – поместиться) (б. 31), **اوصاللق** (усаллык – жестокость, бесчеловечность) (б. 34), **بالان** (балан – калина) (б. 49), **سوزچان** (сүзчән – разговорчивый) (б. 119), **کابسته** (кәбестә – капуста) (б. 169), **کاکره یمك** (кәкрәймәк – искривляться), **کاوش** (кәвеш – калоши) (б. 170), **یاناشه** (янәшә – смежный, соседный) (б. 204).

Сүз ахырында исә бары **[а]** авазына гына билге булып йөри: آلما (алма – яблоко), **آلقا** (алка – серьги, серёжки), **آنا** (ана – мать, мама) (б. 17), **اورتا** (урта – середина, средний) (б. 30), **اومارطا** (умарта – улей) (б. 37), **قز بالا** (кыз бала – девочка) (б. 49), **چاباطا** (чабата – лапоть (лапти)) (б. 88).

Мәдле һәм мәдсез әлифләрдән тыш, **[а]** һәм **[ә]** авазларын сүзлектә **ئه** диграфы**,** **ه (ہ)** хәрефе дә белдерә. Мәсәлән, сүз башы позициясендә **ئه** диграфының **[ә]** авазын белдерүен карыйк: **ئه بی** (әби – бабушка), **ئه ته چ** (әтәч – петух), **ئه رکمه ن** (әрекмән – лопух), **ئه رم مایی** (әрем мае – репейное масло), **ئه رله ن** (әрлән – кроликъ), **ئه شه کیلك** (әшәкелек – испорченность, негодность) (б. 45), **ئه یلانچك** (әйләнчек – вертячка) (б. 46).

**ه (ہ)** хәрефе дә сүз уртасында һәм ахырында **[а], [ә]** авазларын язуда белдерү өчен кулланыла: **[а]** – **چاره سز** (чарасыз – невольно, невольный) (б. 89). **[ә]** – **اورمه کوچ** (үрмәкүч – паук), **اورمه له مك** (үрмәләмәк – ползать, ползти), **اورنه ك** (үрнәк – образец, модель) (б. 31), **اوزگه رش** (үзгәреш – изменение, перемена) (б. 32), **اوزه ك** (үзәк – центр, середина, корень) (б. 33), **اوله ن** (үлән – трава) (б. 37). **[а]** – آطنه کیچ (атна кич – четверг) (б. 13), **آقچه** (акча – деньги), **آلابوطه** (алапута – полынь) (б. 15), **باقچه** (бакча – сад) (б. 49), **چغشقه** (чыгышка – къ выходу) (б. 93), روسچه (русча – по-русски) (б. 112), **طشقه** (тышка – наружу) (б. 139), **فایده** (файда – польза, прибыль, выгода) (б. 150), **قرمسقه** (кырмыска – муравей) (б. 160). **[ә]** – **ایوگه** (өйгә – домой) (б. 44), **اوزگه چه** (үзгәчә – по другому, другим образом) (б. 32), **اوستکه** (өсткә – наверх, вверх) (б. 33), **اوکچه** (үкчә – пятка, каблук) (б. 36), **فرشته** (фәрештә – ангел) (б. 150).

**[у]** авазын язуда күрсәтү өчен автор **او** диграфына һәм **و** хәрефенә мөрәҗәгать итә. **او** бары сүз башында гына кулланыла. Мәсәлән, **اوبرلی قارچق** (убырлы карчык – ведьма, колдунья) (б. 27), **اوراق** (урак – серпъ), **اورام** (урам – улица) (б. 30), **اورمان** (урман – лес, роща) (б. 31), **اوزمق** (узмак – пройти, проходить) (б. 32), **اوصاق** (усак – осина), **اوغچ** (угыч – тёрка) (б. 34), **اویماق** (уймак – капёрсток) (б. 39).

**و** сүз уртасы һәм ахыры өчен характерлы: **دوستلق** (дустлык – дружба) (б. 108), **صاندوغاچ** (сандугач – соловей) (б. 129), **طوتاش** (туташ – барышня), **طورغای** (тургай – жаворонокъ) (б. 141), **قوزغالاق**

(кузгалак – щавель) (б. 165), **قوناق** (кунак – гость) (б. 167), **ماتورلق** (матурлык – красота, изящество) (б. 183), **موللق** (муллык – обилие, изобилие) (б. 191), **الماشو** (алмашу – обмен, размен) (б. 17), **اوزشو** (узышу – состязание), **اوشبو** (ошбу – этот, настоящий) (б. 33), **اوقتو** (укыту – учение, обучение) (б. 35), **صاتو** (сату – продажа) (б. 127), **صلو** (сылу – красивый, изящный), **صو** (су – вода) (б. 131), **طاتو** (тату – согласный, мирный) (б. 135).

**[ү]** авазы язуда шулай ук **او** һәм **و** билгеләре ярдәмендә белдерелә. Сүз башында әлеге вазифаны **او** диграфы үти: **اوجه ت** (үҗәт – упрямый, непослушный), **اوچ آلمق** (үч алмак – мстить, отомстить) (б. 29), **اورده ك** (үрдәк – утка) (б. 30), **اوزکشی** (үз кеше – свой человек) (б. 31), **اوسملك** (үсемлек – растение, растительность) (б. 33), **اوگت** (үгет – проповедь, уговаривание), **اوگی آنا** (үги ана – мачеха) (б. 36), **اولچه و** (үлчәү – весы, измерение) (б. 37).

**و** сүз уртасы һәм ахыры өчен хас: **بورك** (бүрек – шапка) (б. 55), **چوكچ** (чүкеч – молотокъ) (б. 95), **سوزچان** (сүзчән – разговорчивый) (б. 119), **كوبلك** (күблек – многочисленность), **كوبه له ك** (күбәләк – бабочка), **كوپر** (күпер – мостъ) (б. 172), **اوله شو** (өләшү – раздача) (б. 37), **بور كو** (бөркү – душно, душный) (б. 55), **توزو** (түзү – терпение), **توزه تو** (төзәтү – исправление, ремонтъ) (б. 71), **چيگو** (чигү – вышивание) (б. 97), **كتو** (көтү – стадо, толпа) (б. 170), **كيتو** (китү – уходъ, отъездъ) (б. 177), **كيينو** (киенү – одевание, костюмировка) (б. 180).

**[о]** авазын язуда бирер өчен автор **اوُ** ,**او** диграфларын һәм **وُ** ,**و** графемаларын файдалана. **او** һәм **اوُ** сүз башы позициясендә киләләр: **اوجماح** (оҗмах – рай), **اوُچلى** (очлы – острый), **اوچقن** (очкын – искра) (б. 29), **اوخشاش** (охшаш – сходство), **اورلق** (орлык – зерно, семя) (б. 30), **اوزاق** (озак – долго, долгий) (б. 32), **اوُزوُن** (озын – длинный), **اوزونلق** (озынлык – длина), **اوستالق** (осталык – искусство, специальность, мастерство) (б. 33), **اوُن** (он – мука) (б. 38), **اويوق** (оек – чулок) (б. 39).

Сүз уртасында **[о]** авазын **و** һәм **وُ** графемалары белдерә: **بور چاق** (борчак – горохъ), **بورصق** (борсык – барсукъ) (б. 55), **توقماچ** (токмач – лапша) (б. 72), **دوشمان** (дошман – враг) (б. 108), **طوُرنا** (торна – журавль), **طوزلى** (тозлы – солёный) (б. 141), **قوللق** (коллык – рабство, неволя) (б. 166), **قوُياش طوتلووى** (кояш тотылу – затмение солнца, солнечное затмение) (б. 168), **موُڭ** (моң – мелодия, гармония) (б. 191).

**[ө]** авазы сүз башында шулай ук **او** һәм **اوُ** хәрефләре ярдәмендә күрсәтелә: **اوچ قرلى** (өч кырлы – трёхгранный), **اوچ پوچماقلى** (өчпочмаклы – трехугольный) (б. 29), **اوُرمك** (өрмәк – лаять), **اوره ك** (өрәк – привидение, призрак), **اوره نگى** (өрәңге – клён) (б. 31), **اوُزلمك** (өзелмәк – разрываться, оборваться) (б. 32), **اولكه** (өлкә – государство, область), **اولوش** (өлеш – доля, часть) (б. 37).

Сүз уртасында **[ө]** авазын **و** һәм **وُ** графемалары белдерә: **بوركوت** (бөркет – орёлъ) (б. 55), **توُرگه ك** (төргәк – свёртокъ), **توُرمه** (төрмә – тюрьма, арестный домъ) (б. 70), **چيه توُشى** (чия төше – вишнёвая

косточка) (б. 97), دوگی (дөге – рисъ) (б. 109), سوينچ (сөенеч – радость) (б. 120), كوتوچی (көтүче – пастух), كُوزگی (көзге – зеркало) (б. 174).

**[ы]** авазын сүз уртасында һәм ахырында язуда күрсәтү ى графемасына йөкләнә: صاريلق (сарылык – желтизна) (б. 127), صييق (сыек – жидкий, водянистый) (б. 133), قاراڭغيلق (караңгылык – темнота, тьма, мракъ), قارشيلق (каршылык – ослушание, противоречие) (б. 155), قوريلق (корылык – засуха) (б. 165), اوقتوچی (укытучы – учитель, преподаватель), اوقوچی (укучы – читатель) (б. 35), اومارطه چی (умартачы – пчеловод, пчеляк) (б. 37), اوينچی (уенчы – музыкант) (б. 39), بالقچی (балыкчы – рыбак) (б. 50), جييلمالی (җыелмалы – складной) (б. 88), بالالر چاناسی (балалар чанасы – салазки) (б. 91), صاتوچی (сатучы – продавецъ) (б. 127), طابشلی (табышлы – прибыльный) (б. 135).

**[е]**, нигездә, ачык иҗекләрдә генә күрсәтелә, сүз уртасында һәм ахырында, үзенең калын пары кебек үк, ى ярдәмендә белдерелә: كشيلك (кешелек – человечность) (б. 171), كمچيلك (кимчелек – недостаток) (б. 172), كيريلك (кирелек – упрямство) (б. 177), ايكنچی (игенче – хлебопашецъ, земледелецъ), ايلچی (илче – посолъ, послан) (б. 43), جير جيله گی (җир җиләге – клубника) (б. 87), چانچكی (чәнечке – вилка, колючка) (б. 91), كشی (кеше – человек, субъект) (б. 171), كوڭللی (күңелле – весёлый, забавный, интересный) (б. 174). Кайбер очракларда мәдсез әлифкә дә сүз башында әлеге авазны белдерү бурычы йөкләнә: انيكاش (энекәш – младший брат) (б. 27).

**[и]** авазы сүз башында ایـ диграфы ярдәмендә күрсәтелә: ايتكچی (итекче – сапожникъ), ايدل (Идел – Волга) (б. 40), ايرته (иртә – утро) (б. 41), ايسكی (иске – старый, старинный), ايشكه ك (ишкәк – весло) (б. 42), ايكمه ك (икмәк – хлеб) (б. 43), ايمه ن (имән – дуб) (б. 44).

Сүз уртасы һәм ахыры позицияләрендә әлеге вазифа ى хәрефенә йөкләнә: تيزلك (тизлек – скорость, быстрота) (б. 75), تيگزلك (тигезлек – равенство) (б. 76), جيل (җил – ветер), جيله ك (җиләк – ягода) (б. 87), چيكسز (чиксез – безграничный, неограниченный), چيكله وك (чикләвек – орех) (б. 97), شيكه ر (шикәр – сахаръ) (б. 126), كيبتچی (кибетче – лавочникъ) (б. 176), كيچه (кичә – вечер) (б. 177), ميله ش (миләш – рябина) (б. 192) , چركی (черки – мошка) (б. 93), فانی (фани – невечный) (б. 150), فنی (фәнни – научный) (б. 152), نه نی (нәни – маленький) (б. 196).

Шул рәвешчә, С. Рахманколыйның «Татарча-русча лөгать» сүзлеге, XX йөз башы орфографик традицияләрнең чагылышы булып, хезмәттә сузык авазларны язуда күрсәтү өчен традицион гарәп графемалары да, диграфлар да файдаланыла. Әлеге сүзлектә автор иске имлага да, яңа имлага да таянып эш итә. Аларны куллануда нинди дер бер системалылык күзәтелми.

Гомумән алганда, С. Рахманколыйның «Татарча-русча лөгать» сүзлеге татар теленең язу тарихын өйрәнүдә шактый кызыклы лингвистик чыганак булып тора һәм музейның китап фондында саклана торган мондый төр хезмәтләр алга таба да төрле аспектта өйрәнүне таләп итә.

**Әдәбият**

*Бәширов Ф.* Солтан Рахманколый (1888–1916) – язучы, тәрҗемәче, сүзлекләр төзүче // Татар әдипләре, мәгърифәтчеләре (XX йөз башы): Библиографик сүзлек. Казан: Алма-Лит, 2005. Б. 157–159.

*Мәһдиев М.* Солтан Рахманколыйның иҗат эшчәнлеге // Казан утлары. 1966. № 11. Б. 128–138.

*Мортазина Л.* Рахманколыйлар калдырган хәзинә // Шәһри Казан. 2008. 6 май.

*Назипова Г.Р., Гаврилова М.Ф.* Музей А.М. Горького и Ф.И. Шаляпина / Г.Р. Назипова, М.Ф. Гаврилова. Казань: Free Design, 2019. 38 с.

*Рахманколый С.* Татарча-русча лөгать. Казан: И.Н. Харитонов лито-типографиясе, 1913. 210 б.

Татар педагогик фикере антологиясе: 2 томда. 1 т. (борынгы төрки чор – XX гасыр башы) / ред.: Ф.М. Солтанов, М.М. Гибатдинов, Л.Р. Мортазина. Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. 407 б.

*Шляхтина Л.М.* Основы музейного дела: теория и практика: учеб. пособие. 2-е изд. стер. М.: Высш. шк., 2009. 183 с.

***Яруллина Ләйсән Илсур кызы,***
*филология фәннәре кандидаты,*
*А.М. Горький һәм Ф.И. Шаляпин музееның*
*музей предметларын саклаучысы*

УДК 82.091

*Ә.Х. Алиева*

# ЗАМАНДАШЛАРЫ ИҖАТЫНДА ШАГЫЙРЬ ГАБДЕЛМӘННАН МӨСЛИМИ ОБРАЗЫ

Данная статья посвящена изучению рукописского сборника – письменного памятника татарской литературы XVIII века. В сборнике представлены литературные образцы творчества доселе не изученных авторов: «Ода» Р. Абузарова; «Исторический очерк о восстании Пугачёва» Г. Габдулманнанова и стихи Г. Муслимова, живших в XVIII веке.

В произведениях первых двух авторов отражаются отдельные эпизоды крестьянской войны 1773–1775 гг., а в центре событий похвала личным подвигам и героизму в бою Г. Муслимова, идеализируются его человеческие черты и достоинства как военноначальника. В статье, основываясь на исторические факты и архивные документы, расскрывается сложная и противоречивая судьба героя-поэта, старшины Г. Муслимова.

В работе анализируются жанры и стили их произведений. В стихах Г. Муслимова прослеживается осведомленность поэтическими приемами и умелое их применение, знания гаруза и арабо-персидской поэзии. Основу его стихов составляют нравственные раздумья, а основной пафос не только мольба к Богу, но и якобы покаяние за свои «грехи»; открытие современникам состояния своей души.

На основе анализа установлено, что творческое наследие авторов XVIII века, включенное в данный рукописный сборник, представляется как живое изображение, дневник того времени. Они являются редкими литературно-историческими памятниками и новыми источниками для изучения татарской литературы XVIII века.

**Ключевые слова:** письменный памятник, Габдулманнан Муслимов, Рахимкул Абубакиров, Габдулжалил Габдулманнаннов, восстание Пугачёва, ода, поэзия, исламское богословие, суфизм, татарская литература XVIII века.

This article is devoted to the study of the manuscript collection – a written monument of the Tatar literature of the XVIII century. The collection contains literary samples of creativity of hitherto unstudied authors: «Ode» by R. Abuzarov; «Historical essay on the Pugachev uprising» by G. Gabdulmannanov and poems by G. Muslimov, they all lived and worked in the 18th century.

The works of the first two authors reflect individual episodes of the peasant war of 1773–1775, and in the center of events praise the personal exploits and heroism in battle of G. Muslimov, his human traits and dignity as a military leader are idealized. Based on historical facts and archival documents, the article reveals the complex and controversial fate of the hero-poet, foreman G. Muslimov.

The work analyzes the genres and styles of their works. In the poems of G. Muslimov, awareness of poetic techniques and their skillful application, knowledge of garuz and Arab-Persian poetry can be traced. The basis of his poems is moral reflections and the main pathos is not only a prayer to God but also supposedly repentance for one’s «sins»; revealing to his contemporaries the state of his soul.

Based on the analysis, it was established that the creative heritage of the authors of the 18th century and included in this handwritten collection is presented as a living image, a diary of that time. They are rare literary and historical monuments and new sources for studying Tatar literature of the 18th century.

**Keywords:** written monument, Gabdulmannan Muslimov, Rakhimkul Abubakirov, Gabdulzhalil Gabdulmannanov, Pugachev's uprising, ode, poetry, Islamic theology, Sufism, Tatar literature of the 18th century.

Татар әдәбиятының үткәндәге бай мирасын чагылдырган яңа чыганаклар, моңарчы фәндә билгеле булмаган авторлар һәм алар иҗатының матур үрнәкләре әледән-әле табылып тора. Шундыйларның берсе – Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәгендәге шактый күләмле (140 битлек) бер кулъязма китап-җыентык [Язма мирас үзәге, 39 колл.]. Бу кулъязма китапта моңарчы өйрәнелмәгән өч авторның иҗат үрнәкләре теркәлгән. Баштагы өлеше (68 б.) – «Пугачёв хәрәкәте турында тарихи очерк» [Язма мирас үзәге, 39 колл., б. 3 а–34 б; XVIII гасыр татар әдәбияты, 2006, б. 173–193] дип исемләнгән. Үзенчәлекле жанрда иҗат ителгән бу әсәрнең авторы – Габделҗәлил Габделмәннан углы. Язмаларының нигезе итеп ул XVIII гасырның икенче яртысында иҗат иткән шагыйрь Рәхимкол Әбүбәкер углының үзенең чордашы, шул заман татар җәмгыятендә шагыйрь буларак та, һәм 1773–1775 еллардагы крестьяннар сугышында хөкүмәт гаскәрләре сафында торып катнашкан хәрби җитәкче буларак та халык арасында танылган шәхес – старшина Габделмәннан Мөслимов һәм Емельян Пугачёв турында язган шигырьләрен алган. Без аны шартлы рәвештә «Мәдхия» дип атадык [XVIII гасыр татар әдәбияты, 2006, б. 169–172]. Рәхимкол Әбүбәкер углының биредә теркәлгән кырык сигез юллык шигырьләре, нигездә, Г. Мөслиминең башыннан узган хәлләрне, аның сугышларда күрсәткән батырлыкларын сурәтләүгә, нәсел-чыгышын мактауга, дөньяда кылган эшләрен олылауга корылган. Чынлап та, автор героен гыйлемлектә, фидакярлектә, тугрылыкта, дошманнары белән сугышта үз-үзен аямаучы, пәһлеванлыкта тиңе юк гайрәт иясе итеп сурәтли. Аның кешелек сыйфатларын да идеаллаштыра. Шигырьләре югары стильдә язылып, теле дә катлаулы, чуар, гади укучыга аңлашылмый диярлек.

Рәхимкол Әбүбәкер углының «Мәдхия»се хакында, «Пугачёв хәрәкәте турында очерк» эчендә иллюстрация рәвешендә файдаланылу фактыннан чыгып фикер йөрткәндә, биредә тулысынча урын алмыйча, зур әсәрнең бер өлеше дип тә уйларга нигез бар. Аның башка күчермәләре дә, автограф нөсхәсе дә әлегә кадәр фәндә мәгълүм түгел [Алиева, 1992, б. 25–31].

Габделҗәлил Габделмәннан углының бу тарихи очеркы исә борынгыдан килгән традицион язмалар стилендә – һәрбер дүртьюллыкка берничә битлек шәрех рәвешендә язылган. Шул рәвешле, ул шигырьләргә аңлатма-комментарийлар биреп бара һәм Пугачёв хәрәкәте

турында киңәйтелгән күзәтүләр ясый. Ике автор да бер позициядән торып фикер йөртә. Максатлары – Г. Мөслимовка дан җырлау. Аны яуда батыр, гайрәтле сәрвәр, тормышта гадел, гыйлем иясе шәхес итеп күрсәтү.

Сугыш хәрәкәтләренең аерым эпизодларын, таралу киңлеген тасвирлау, ике якның да хәрби җитәкчеләрен характерлау – сурәтләнгән вакыйгаларның әле яңалыгы, күптән түгел генә булып үткәнлеге хакында сөйли. Димәк, әсәрнең язылу датасы да шул чорга кайтып кала дип уйларга нигез бар.

Нәтиҗәдә шигъри мәдхия һәм проза синтезыннан торган, аерым шәхесне мактауга корылган, бер үк вакытта тарихи чынбарлыкны конкрет детальләр, реаль фактлар нигезендә яктырткан әсәр барлыкка килгән.

Билгеле булганча, үткән гасырлар шигъриятендә мәдхия (касыйдә) жанры гаять популяр булган. Нигездә, моның ише югары өслүбтә, купшы телдә, риторик пафос белән сугарылган әсәрләр үз чорының ханнарына, сугыш-бәрелешләрдә геройлык күрсәткән каһарманнарга, дин әһелләренә атап язылалар. Аларда шәхесләргә бәя бирелә, ул кылган гамәлләргә дан җырлана. Кайчак, әлбәттә, геройга бик үк хас булмаган сыйфатларны күпертеп күрсәтү, булмаганны бар итеп күрү теләге, гипербола да мул файдаланыла. Шулай да мәдхия һәм мәрсияләр күпмедер күләмдә шул чор кешесен, җәмгыять тормышын, кешеләрнең үзара мөнәсәбәтен ачуда кыйммәтле тарихи һәм әдәби чыганак булып торалар. Г. Мөслими турында сөйләгәндә дә без әлеге мәдхияләргә һәм документларда китерелгән фактларга таяндык.

Кульязма җыентыкта әсәрләре урын алган өченче автор – Г. Мөслими шәхесенә тукталабыз. Аны өйрәнүдә төп чыганаклар итеп, замандашларының әсәрләреннән тыш, архив материалларын, рәсми документларны, рапортларны күрсәтергә була.

Иң элек Г. Мөслиминең кем булуын ачыклап китик.

Габделмәннан Мөслим углы Мөслимов (1724–1784 елдан соң) – XVIII гасырның уртасында яшәгән һәм иҗат иткән шагыйрь. Кульязмадагы материаллардан аңлашылганча һәм тарихи документлар раславынча, ул Уфа өязе Исәт олысының старшинасы булган, үз заманы өчен шактый тирән белемле, укымышлы зат булып саналган. Моңа аның чыгышы белән мулла нәселеннән булуы да сәбәпче булган, күрәсең. Һәрхәлдә, замандашларының истәлекләрендә аның зирәк акыллы, хәйләкәр, тапкыр булуы хакында кабатлап әйтелә.

Безнең өчен иң кызыклы һәм игътибарга лаеклысы шул: тышкы рәвеше, торткан тәхете буенча кырыс табигатьле гаскәр башлыгы шактый оста язучы, каләм иясе дә булган. Шигъриятнең шул чор кануннарын, гарузны яхшы үзләштергән, гарәп-фарсы поэзиясеннән дә хәбәрдар булган. Сакланып калган шигырьләре (4 кисәктән тора, җәмгысы 876 юл) шул хакта сөйлиләр.

Белүебезчә, Пугачёв явында меңләгән татарлар һәм башкортлар катнашкан. Алар крестьяннар юлбашчысы, мәрхәмәтле халык патшасы Пётр Фёдорович икеләтә коллыкта, аяныч, авыр тормыш сөргән халыкларга һәм милли азатлык, һәм шәхси ирек бирер, дип чын күңелдән ышанып, фетнәчеләр ягына кушылганнар. Әмма бу чорда ук инде Россия патшаларының ныклы таянычы – бишенче колоннасы – татар һәм башкорт феодалларының чагыштырмача бай, привилегияле, абруйлы катламы булган. Боларның күпчелеген әлеге татар һәм башкорт гаскәриләре җитәкчелеге тәшкил иткән.

Әлеге кульязма китапта Пугачёвка каршы көрәшкән патша яклы гаскәр башлыкларының исемлеге китерелә. Өфе өязе Дуван волосте Себер юлы старшинасы Солтанморат Янышев татарлардан һәм башкортлардан торган үч алу отрядлары башлыгы булып, 1773 елның октябреннән 1774 елның ноябренә чаклы Пугачёвка каршы көрәшә. «Тугрылыклы» хезмәте өчен Сенат указы белән олы бүләккә лаек була. Аңа һәм бертуган энесе Бәхтияргә май һәм күн эшкәртү заводлары төзергә һәм җитештерелгән товарны Россия империясенең төрле тарафларында сатарга рөхсәт бирелә.

Уфа өязенең мишәр старшинасы Аблай Исмаилов та 1774–1775 елларда Каранай Муратов җитәкләгән фетнәчеләр отряды белән Нугай юлында сугыша. Мәннан Тупеев, Вәлишә Шәрипов, Сөләйман Күзкәев кебек, ул да баштан ахырынача Пугачёв явына каршы көрәш алып бара. Нугай юлы старшинасы Алибай Морзагулов та Пугачёвка каршы торган. Әмма ул, башкалардан аермалы буларак, хәйләкәрлек тактикасына күчкән: бер караганда хөкүмәт гаскәре ягына, икенче караганда фетнәчеләр ягына авышкан. Ә инде 1774 елның көзеннән Алибай Башкортстанда крестьян чуалышларын бастыруда актив катнашкан. 1774 17 июлендә ул генерал П.И. Голицынга бирелгән һәм тулысынча хөкүмәт гаскәре ягына күчкән.

Габделмәннан Мөслимов та – югарыда искә алынган патша яклы каһарманнарның берсе, һәм, әйтергә кирәк, иң күренеклесе. Әлеге кульязмада Мөслимовның замандашлары – Рәхимкол Әбүбәкер углы белән Габделҗәлил Габделмәннан углы аның тормыш юлын, кылган гамәлләрен тасвирлыйлар.

Аларның сүзләренә караганда, Габделмәннан гаять гайрәтле, көчле булган. Физик тазалыгы, күрәсең, аның характерына да күчкән: ул үз-үзенә нык ышанган, ихтыяр көченә ия, тәкәббер, каты бәгырьле һәм куркусыз йөрәкле кеше буларак сурәтләнә. Кульязмада аның яшь вакытында әллә нинди маҗаралар кичерүе, алардан исән-сау, җиңеп, ныгып чыгуы хакында языла. Батыр егетнең дошманнары, көндәшләре аның бу гаярьлеген күреп һәм башкисәргә әверелеп баруыннан шүрләп, аңа төрле киртәләр корып карыйлар. Әмма Габделмәннан аларның барысын да җиңеп бара.

Пугачёв кузгалышы башлануга Г. Мөслимов, старшина буларак, үз гаскәренә җитәкчелек итә һәм фетнәчегә каршы көрәшә. Башлыча ярлы крестьяннардан торган отрядның күпчелеге, күрәсең, Пугачёв

ягына авыша бара, көннәрнең берендә алар старшина Мөслимовны Пугачёвка тотып бирәләр. Әмма хәйләкәр Мөслимов югалып калмый, үзе дә Пугачёвны патшасы һәм башлыгы итеп таный, Оренбургны камап алган гаскәр арасында отряд җитәкчесе булып, шәһәрне штурмлауда фетнәчеләр ягында торып катнаша.

Биш ай чамасы вакыт узганнан соң, ул хәрби йомыш белән Уфага җибәрелә. Шул тарафка юл тотканда Михельсон[1] отрядына юлыга, аңа кушылып, Сакмар буенда барган хәрби хәрәкәтләрдә катнаша. Һәм азаккача кыйбласын үзгәртми.

Күренә ки, бу кеше патшага һәм тәхеткә тугрылыклы хезмәт итә. Пугачёвны эзәрлекләп, Казан Кремле диварлары янына килеп җитә. Михельсон аны иң ышанычлы командирларыннан саный, алай гына да түгел, кульязма авторлары Михельсонның Г. Мөслимов күрсәткән батырлыкларга, фидакярлеккә соклануы турында язалар: *«Ул дәхи аның җәнкен* (сугышуын) *бераз тамаша әйләде. Күрде ки, үзе тирләмеш, әлендә кылыч тотар, һәркем, мөтәвәҗҗиһ улса* (аңа таба караса), *угыннан качарлар, буның дәхи егетлек җәүһәре тибрәнеп, гаскәрә әмер әйләде. Бер арадан саф-саф булып, дошманга ыргылдылар. Бер гаҗәеп җәнк* (орыш, сугыш) *улды. Күргәннәр хәйран калдылар. Кан җир йөзене япты. Ул көнне Хак Сөбханә Тәгалә аңа ярдәм итте. Ләгыйньнәрне кире сөреп, җөмләсен тар-мар итеп, ничәләрен катыйль әйләде, ничәләрен әсир әйләде»* [Язма мирас үзәге, 39 колл., б. 29 а]. Азактан, Пугачёв кулга алынып, әсирлеккә төшкәч тә, бу җиңүнең төп каһарманнары итеп, Михельсон һәм Габделмәннан Мөслимов күрсәтелә. *«Анлар ... Емельян ләгыйньне дотып, бәнд әйләделәр* (бәйләделәр) *вә дәхи шаһ Екатеринайә күндерделәр... Михельсонә вә Мәнданә шаһы газыйм алтын вә көмеш хәлгать* (бүләк) *вирде. Җөмләсе гани улдылар, дәүләткә вә гыйззәткә ирештеләр»* [Язма мирас үзәге, 39 колл., б. 30а]. Шагыйрь исә болай яза:

*Һәм Саричун кальгасында чикди гаскәр ул ләгыйнь,*
*Ирешүбән кыйлдыларың җәнк, форсат улды бер дәмин.*

*Кырдылар һәм дустак идеп ул ләгыйньнең кәндисен.*
*Шуның өчен әһле шәүкәт улды Мәндан бик һәмин.*

[Язма мирас үзәге, 39 колл., б. 30 б]

(Һәм Царицын крепостена гаскәре белән чигенде ул ләгыйнь.
Барып җиткәч һөҗүм ачты. Бер арада җай чыкты, ул
ләгыйньнең гаскәрен кырдылар, ә үзен тоткын иттеләр.
Мәндан бик тиз арада көч-куәт иясе булып танылды.)

[1] Михельсон Иван Иванович (1740–1807) – Россия империясе гаскәр башлыгы, кавалерия генералы. Әсәрдә искә алынган вакытта подполковник, җәза бирүче карательләр корпусы башлыгы була.

*Шаһы газыйм кәндү күрде ни лә мәшһүр бу җәван.*
*Тәрк идептер хезмәтичүн һәм юлында башы, җан.*

*Аның ичүн симе-зәрдән вирде аңа бигиран.*
*Гыйззәт илә дуст, исме улды Мәндан бу әван.*

[Язма мирас үзәге, 39 колл., б. 34 б]

(Бөек падишаһ үзе күрде – бу егет гаять көчле һәм гаярь,
Хезмәтенә тугрылык юлында ул башын һәм җанын куяр.
Шуңа күрә аңа күп итеп алтын-көмеш бирде,
Мәндан шул вакыт дан-дәрәҗәгә иреште.)

Мәдхияче Рәхимкол Әбүбәкер углы Г. Мөслимовка, аның батырлыкларына патетик рухта мәдхия, дан җырлый. Проза өлешен, комментарийлар язган Габделҗәлил Габделмәннан углы да аннан калышмый. Әсәр үзенчә югары пафос, сугыш героикасы белән сугарылган. Төп каһарман әкияти герой яки дастан-кыйсса геройларын хәтерләтә. Хикәяләү рәвеше бигрәк тә сугыш баталияләрен тасвирлаганда аерым бер интонация, пафос ала. Аерым урыннарда сүз нииндидер мифик яу, Гали батыр, Сәетбаттал гази сугышларын хәтерләткән кебек була. Биредә шуны искәртәсе килә: һичшиксез, ике автор да борынгы Шәрык дастаннары, халыкта кульязмаларда һәм телдә таралган кыйссалар белән таныш булганнар һәм Г. Мөслимов каһарманлыкларын тасвир кылганда бу әзер калыплардан, таныш тәгъбирләрдән мул файдаланганнар. Менә 7–8 строфа:

*Дәште Кыпчак үзәсендә йите йирдә һәм гайа,*
*Әйләде җәнк дошман илә, сани Рөстәм дастан!*

*Һәрберендә күрде зәхмәт һәм тәнендин акты кан.*
*Хак Тәгалә саклады, чөн дүнде андин саг-әман.*

[Язма мирас үзәге, 39 колл., б. 23 б]

(Дәште Кыпчак даласында җиде җирдә бик төгәл,
Дошман белән көч сынашты – дастаннарда
Даны калган икенче Рөстәм батырны хәтерләтте.
Һәрберсендә яраланды һәм тәненнән каны акты.
Ходай Тәгалә саклады, ул исән-имин котылды.)

Мәдхиянең ахыры без күнеккән традицион югары тондагы касыйдә-мәдхиядән аерылып, башка төрлерәк яңгыраш алган. Автор аны кыйсса, әкиятләргә хас бәхетле финал белән тәмамлый. Әкияти батыр ир-атны, кылган батырлыклары өчен, Аллаһ әкияти гүзәл кыз Сәхибҗамал белән кавыштыра. Яшьләр бер күрүдә бер-берсенә гашыйк булып, бәхетле гаилә корып җибәрәләр.

Габделмәннан Мөслимовның Пугачёв явын бастырудагы роле замандашлары иҗатында киң чагылыш таба, төрле яклап мактала. Шул ук вакытта аның крестьяннар хәрәкәтенә кадәр булган эшчәнлеге дә тарихи документларда теркәлеп калган: Башкортстан дәүләт

архивының Исәт провинциясе канцеляриясе фондында (60 эш, б. 57) 1772 елга караган үтенеч язуы саклана, аны гаскәри Әдерәш Мөслими язган. Биредә ул: «Старшина Мөслимов әтиемне камчы белән кыйнады һәм чыбык белән суктырды, шул җәзадан әтием озак тормыйча дөнья куйды», – дип белдерә.

Икенче бер документ (шул ук фондта 60 эш, б. 52) 1775 елның 16 сентябрь датасы белән теркәлгән. Ул Г. Мөслимовның башбаштаклыкларын тикшерү шаһитлары Шәриф Усманов, Аит Ямбетов, Борис Мансуров һ.б. биргән мәгълүматлар, күрсәтмәләр, шикаятьләрдән гыйбарәт.

Корманай авылы кешесе Әмин Сәитов күрсәтүенчә, үзе ясаклы татарлар авылы Аккүздә булган вакытта, старшина Г. Мөслимов кушуы буенча (есаул шулай раслый), аның амбарларыннан булган бар нәрсәсен алып киткәннәр (250 пот бодай, 180 пот арыш, 180 пот солы, 150 пот арпа, 80 пот бәрәңге, һ.б.) [Материалы по истории... , 1949, т. 1].

Старшина Г. Мөслимов өстеннән судларга ук барып җиткән тикшерү эшләре протоколларын, аерым шәхесләрнең, аннан зарланып язган шикаятьләрен тагын санап китәргә мөмкин булыр иде [Документы ставки..., 1975].

Күренә ки, реаль документларда Габделмәннан Мөслимовның җәмгыять тормышындагы кылган гамәлләре башка яктан да ачыла. Һәм алар, әлбәттә, алда телгә алынган кульязма авторларыннан аермалы буларак, әлеге затның гади халыкны ничек җәберләвен дә фаш итәләр.

Авторның тәрҗемәи хәлен, аның каршылыклы шәхесен, тормыш юлын ачыклый торган мәгълүм фактлар белән танышканнан соң, аның кульязма китапта тәкъдим ителгән иҗат үрнәкләренә игътибар итик. Тугыз йөзгә якын юл тәшкил иткән шигырьләре тулысынча суфичылык рухында [XVIII гасыр татар әдәбияты, б. 125–168]. Әмма Г. Мөслимовның азатлык хәрәкәтенә карата фикере каршылыклы. Аның шәхси сыйфатлары, тормышы үзенең шигырьләрендә дә, чордашларының язмаларында да киң яктыртыла.

Г. Мөслиминең тәрҗемәи хәле турында аерым мәкаләләрдә бераз мәгълүмат бирелсә дә [Алеева, 1994, б. 22–29], иҗаты әле фәндә җентекләп өйрәнелмәгән. Шигырьләрендә ул үзенең каршылыклы тормыш юлы турында уйлана, үзенә үзе хөкем чыгара кебек. Эчтәлегеннән күренгәнчә, шигырьләрен ул олыгайгач, гомеренең соңына якынлашкач язган булса кирәк. Алар гадәти суфичылык рухы белән сугарылган. Татар әдәбиятында күптәннән кулланылган традицион алым – Аллаһны мактау, аның Барлыгын һәм Берлеген тану, фәрештәләрен, пәйгамбәрләрен олылау. Аның Коръәндә күрсәтелгән төп сыйфатларын санап китүенең максаты да реаль тормыш чынбарлыгына аптыраудан, югалып калудан, буталчык, җәбер-золым тулы бозык дөньяны күрсәтүдән туган. Шуларның барысыннан да котылу юлы –

бары тик Аллаһтан, Аның ярлыкавына, Аңа ялвару, тәүбә кылуга бәйле. Яшьлегендә ул гаскәри кеше буларак та, үзенең күп гөнаһлар кылганлыгын аңлый булса кирәк, шуңа да, күпме генә үтенсә дә, Аллаһның җиңел генә гафу итүенә ышанычы нык түгел.

Әхлакый уйланулар шигырьләренең нигезен тәшкил итә. Төп пафос та бары тик Аллаһка гына ялварудан гыйбарәт түгел. Ул замандашларына үзенең рухи халәтен ачарга тели. «Мин гөнаһлар кылдым, яман эшләр эшләдем, шуңа да Аллаһка сыенам. Син гыйбрәт ал, начар булма, син яхшы бул. Дөрес юл ул – Аллаһка табынуда, аның юлыннан чыкмауда», – дип үгетли.

*Гадәт бетми, явыз эшкә вармаңыз.*
*Күңелне явыз эшкә вирмәңез, –*
[Язма мирас үзәге, 39 колл., б. 70 а]

дип, киләчәктә шундый бозыклыклар эшләмәскә чакыра:

Шигырьләре аша Г. Мөслими тормыштагы явызлыкны бетерүгә үз мөнәсәбәтен белдерә. Аныңча, адәм баласы начар эшләрне, гөнаһларны булдырмаска тырышырга тиеш. Моның өчен яшьтән үк туры, хак юлда булырга, читкә тайпылмаска чакыра. Олыгайгач, искә төшеп, кылган гамәлләрең өчен күпме генә үкенсәң дә, аларны төзәтергә соң булуы бар, ди.

*Фәһеме вар гыйбрәт өчен карый,*
*Олуг йыгач әүвәл баштан корый.*

*Әгәр чыкса җиһанә куәтле бада,*
*Яше калып, олы агачны аудара.*
[Язма мирас үзәге, 39 колл., б. 45 а]

Ягъни ул – үзе моңа мисал. Шулай да ышанычны югалтмаска кирәк, Аллаһның кодрәте киң, үз-үзеңне дөрес юлга күндер, изге гамәл кыл, ул кичерер, ди автор. Г. Мөслиминең алга сөргән төп фикере – беренче чиратта үз кимчелекләреңне төзәтү. Үз-үзеңне тәрбияләү ярдәмендә яманлыкның бетәсенә ышана кебек шагыйрь һәм шуңа өнди дә. Тагын ул, гөнаһ диңгезе булган бу дөнья кысасы беләнчикләнмичә, үзеңне үлгәннән соң булган дөнья өчен дә әзерләргә кирәк, дигән караш үткәрә. Монысы исә ислам дине өйрәтүләренең нигезе булып тора.

XVIII гасыр ядкяре буларак, Г. Мөслими шигырьләре кайсы яклары белән безгә якын соң, ни өчен аларны моңарчы «дини суфичылык идеологиясен тарата» дип читкә тибәреп килгәннәр?

Безгә калса, шигъриятне, һәм ул чор тарихын азмы-күпме чамалаган, аңа битараф булмаган кеше йөрәгендә, Г. Мөслими шигырьләрен укып, тормыш мәҗбүрияте аркасында герой кичергән фаҗига өчен әрнү белән бергә, олы җанлылык, элекке хаталарыңнан ваз кичү, мәрхәмәтлелек, сабырлык, тәүбә-истигъфар хисләре уяна. Югыйсә,

шигырьләре тышкы формасы, шигърият нәзакәтлелеге ягыннан шактый уртакул. Әмма бу саргайган кәгазьләрне, дини вәгазьләрне кулга алып, хәзерге хәрефкә күчергәндә, андагы Ә. Каргалый, Ш. Зәки, Һ. Салихов, М. Акмулла кебек шагыйрьләргә хас кайнар дәрт, чиксез инану-иман бармакларны «пешерә». Хәер, югарыда китерелгән икешәр юллы ике строфа гына да Г. Мөслимидә шигри образлылык хасияте булуы хакында сөйли булса кирәк.

XVIII гасырда язылган бу кульязма җыентыкка тупланган әсәрләр исә безгә шул чорның бер җанлы тасвирламасы, көндәлеге буларак кадерле. Рәхимкол Әбүбәкер углының «Мәдхия»сендә, каршы дошман лагеренда булуга карамастан, рыцарь романнарына хас мавыктыргыч итеп язылган әкияти герой маҗаралары шактый шома, әдәби яктан камил һәм матур күрсәтелгәннәр, шуңа күрә бу кульязма әсәр XVIII гасырның сирәк сакланып калган әдәби-тарихи истәлекләре рәтендә саналырга хаклы.

Габделҗәлил Габделмәннан углының «Пугачёв хәрәкәте турында тарихи очерк»ының тагын бер әһәмиятле үзенчәлеге шунда ки: ул проза һәм поэзия катнашмасы булып тора. Башлыча, поэзия, көйле жанрлардан торган борынгы татар әдәбияты, күрәсең, инде шигъри калыпка гына сыеп бетә алмый. Җанлы тарихи вакыйгаларны, аларда катнашкан каһарманнарның батырлыкларын тасвирлау өчен махсус проза-комментарий өлеше кирәк була башлый. Моның белән әдәбият фәлсәфи тирәнлеккә, гомумиләштерүгә ирешә бара. Ә инде яңа гасырда гөрләп чәчәк аткан кыйсса-дастан жанрларында поэзия белән прозаның болай үзара мәгънәле берегүе җанга ләззәт, эстетик зәвык бирә торган гүзәл җимешләр барлыкка китерә.

**Әдәбият**

*Алиева Ә.* XVIII гасыр әдәбиятының онытылган бер мәдхиясе // Әдәбият чыганаклары һә текстология. Казан: РФА КФҮ Г. Ибраһимов исем. ТӘһТИ, 1992. Б. 25–31.

*Алиева Ә.* Г. Мөслими шигырьләреннән үрнәкләр // Әдәбият чыганакларын барлаганда. Казан: РФА КФҮ Г. Ибраһимов исем. ТӘһТИ, 1994. Б. 22–29.

Документы ставки Е.И. Пугачёва, повстанческих властей и учреждений, 1773–1774 гг. М.: Наука, 1975. 523 с.

Материалы по истории Башкирской АССР. М.-Л., 1949. Т. 1. С. 147–202.

XVIII гасыр татар әдәбияты. Поэзия. Казан: Матбугат йорты, 2006.

ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге, 39 колл., 1 тасв., 28 сакл. бер.

***Алиева Әнисә Хәниф кызы,***
*филология фәннәре кандидаты,ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының текстология бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 821.512.122

***И.Г. Закирова,***
***С.Б. Даутова***

# НУРЛАН САНЖАРНЫҢ «КӨТЕЛМӘГӘН КУНАК – ҖҮЧИ» РОМАНЫ: тарихи образлар һәм аларның заманча интерпретациясе

В статье рассматривается роман казахского писателя, кинодраматурга Нурлана Санжара «Неожиданный гость – Джучи», опубликованный в 2019 году в Алматы. Роман основан на исторических источниках. Через образы двух великих женщин – матери Чингисхана Оэлун и его первой жены Борте описываются сложные события того времени. Автор по-новому объясняет события, старается раскрыть тайны, связанные с историей той эпохи. Образ Джучи автор стремится раскрыть как идеального правителя. Однако образ, несмотря на название романа, ни только не является главным, но и полностью не раскрыт, описывается фрагментарно, отдельные описываемые события не характеризуют Джучи хана как полководца и тем более как личность. Не описаны в романе отношения Джучи-хана с его сыном Бату, другими детьми, его отношения с женщинами, женами, даже с его матерью Борте.

**Ключевые слова:** исторический роман, Золотая Орда, Нурлан Санжар, Джучи хан, Чингиз хан.

The article examines the novel «The Unexpected Guest – Jochi» by the Kazakh writer and film playwright Nurlan Sanzhar, published in 2019 in Almaty. The novel is based on historical sources. Through the images of two great women – Genghis Khan's mother Hoelun and his first wife Borte, the complex events of that time are described. The author explains the events in a new way and tries to reveal the secrets associated with the history of that era. The author seeks to reveal the image of Jochi as an ideal ruler. However, the image, despite the title of the novel is not only not the main one but also not fully disclosed, it is described in fragments, the individual events described do not characterize Jochi Khan as a commander much less as a person. The novel does not describe the relationship of Jochi Khan with his son Batu, other children, his relationships with women, wives, even with his mother Borte.

**Keywords:** historical novel, Golden Horde, Nurlan Sanzhar, Jochi Khan, Genghis Khan.

Алтын Урда ханнары династиясенә нигез салган Җүчи хан, Чыңгыз ханның олы улы, Шәрык чыганакларында Җочи, Җучи, Җүчи, Йочи, Жошы, Туши, Души, Тоссук хан исемнәре белән мәгълүм. Җүчиның гомер еллары төгәл билгеле түгел, ул якынча 1180/82–1225/26 елларда яшәгән. Ул – Алтын Урда тарихында иң каршылыклы һәм харизматик фигураларның берсе. Тарихи чыганаклар аны батыр сугышчы һәм атаклы гаскәр башлыгы буларак тәкъдим итә, серле үлемен тасвирлый. XIII гасырга караган «Юань-чао би-ши»дә һәм язма чыганакларда аның тууы, тормышы, атасы һәм туганнары белән мөнәсәбәте бәян ителә. Аларда Җүчиның шәхесе төрле тарихи

ракурсларда сурәтләнә: полководец, дипломат һәм үз олысының беренче ханы. Шул ук вакытта, атасы Чыңгыз хан һәм улы Бату хан белән чагыштырганда, ул күпмедер дәрәҗәдә күләгәдә кала. Бу – матур әдәбиятка да кагыла, аның Алтын Урдада идарә иткән нәсел варисларына багышланган әдәби әсәрләр шактый. Чыңгыз хан, Җүчи династиясеннән Бату, Бәркә һәм башкаларның сәяси биографияләре буенча тарихи романнар басылып чыга. Бу җәһәттән Җүчинең тормыш юлына, сәяси эшлекле һәм хөкемдар буларак эшчәнлегенә тиешле игътибар бирелми. XIII гасырның беренче чирегендә – Yeke Mongγol Ulus барлыкка килгән вакыттагы тарихи вакыйгаларда Җүчи хан зур роль уйный, ул гаскәр башлыгы буларак Чыңгыз хан гаскәренең барлык хәрби кампанияләрендә катнаша. Җүчи олысының барлыкка килүе XIII гасыр башында Чыңгыз хан империясе оешу белән турыдан-туры бәйләнгән.

Алдарак Алтын Урда тарихы һәм шәхесләре тарихи чыганакларда һәм фольклорда яктыртылса, соңрак бу тема тарихи романнарга күчә. Язучылар тарихи вакыйгаларны документаль характердагы язма чыганакларга, елъязмаларга, сәяхәтнамәләргә таянып бәян итә. Әмма бу чыганаклар тарихи темага әдәби әсәр иҗат итү өчен нигез булган очракта да, үткән заман турында җитәрлек мәгълүмат бирмиләр. Тарихи роман жанрының үзенчәлекләреннән берсе – үткәнне әдәби чаралар ярдәмендә сурәтләү. Язучы үз эшендә файдаланган фактик материалны, шул вакыйгаларны, чорның вазгыятен, яшәеш-көнкүрешне мөмкин кадәр тулырак һәм тирәнтенрәк ачу өчен, иҗади тулыландыра. Шул рәвешле, бу төр әсәрләр тарихи фактларның һәм иҗади башлангычларның синтезын тәшкил итәләр. Әдәби әсәрләр, беренче чиратта, кеше характерын сурәтләүгә игътибар бирәләр. Һәр чор һәм тарихи шәхес мәдәни-тарихи, иҗтимагый-сәяси һәм фәнни парадигмалар белән үзара бәйләнештә өйрәнелә, шуңа бәйле рәвештә тарихи чор, кеше/шәхес турында билгеле бер күзаллау белән характерлана.

Казакъ язучысы, кинодраматург Нурлан Санжарның бер-бер артлы дөнья күргән ике романы да – «Көтелмәгән кунак – Җүчи» (2019) һәм «Бату-хан» (2021) – тарихи язма чыганакларга нигезләнеп иҗат ителгән. Әлеге әсәрләрне шушы чыганакларның, төгәлрәге, аларда тасвирланган вакыйгаларның яңача интерпретациясе дип карарга мөмкин. Бу мәкаләдә әдипнең «Көтелмәгән кунак – Җүчи» романын тикшерәбез.

«Көтелмәгән кунак – Җүчи» романында ыру-кабиләләр арасындагы бәрелешләр, аерым халыкларны юк итү кебек зур тарихи вакыйгалар да, берничә кеше арасындагы мөнәсәбәтләр дә чагыла. Бу – Тимучинның беренче хатыны Бөртәне мәркәт кабиләсе урлап китеп, аннан кайтканда хатынның йөкле булуы һәм әсирлектән соң туган баланың атасы кем булу турындагы сорауның җавапсыз калуы; Тимучинның атасының анасы Ван ханга кеш тун бүләк итүе; Тимучинның кардәше Чагатай белән каршылыгы, Өүләннең сугыш ятимнәрен тәрбияләве, Таян ханның үги анасы Гурбесуның Ван ханның

башын олылау ритуалы, найманнарның үз эчендәге таркаулыгы һәм монголларның аларны тар-мар итүе, Җүчинең Сыгнак шәһәрен яулап алуы һәм ау вакытында үлүе. Автор тарихи чыганакларга таянып, Җүчи образын яңача ачарга омтыла, басып алу сугышларының фаҗигасын, Җүчи олысы төзелгән чорны тасвирлый. Нурлан Санжар, Алтын Урданың мәгълүм шәхесе Җүчи, аның анасы Бөртә, әбисе Өүлән образлары, алар белән бәйле вакыйгаларны сурәтләү аша, укучының игътибарын намус, кешелеклелек, шәфкать кебек кыйммәтләрне ачуга юнәлтә. «Көтелмәгән кунак – Җүчи» романының эчтәлеге дә шушы проблемаларны сәнгатьчә аңлатуга багышлана.

Автор романның Чыңгыз ханның анасы турында «Ана теле» дигән киносценарий язу идеясеннән башлануын әйтә [Танкаева]. Җыелган материал күп булып, эш барышында ул роман булуга дәгъва кыла. Әмма бу материал, нигездә, Чыңгыз ханның анасы Өүлән (Өүлән монг. / Оэлун рус.) һәм Чыңгыз ханның хатыны Бөртә турында булып, романның исеменә чыккан Җүчи образы икенче планда кала. Гомумән, Нурлан Санжар романда хатын-кыз образларына зур игътибар бирә, кечкенә кыздан башлап гомеренең ахырына җиткән өлкән яшьтәге ана – һәрберсе хатын-кыз образының берәр сыйфатын ачуга хезмәт итә.

Нурлан Санжар ана теле образын «Көтелмәгән кунак – Җүчи» романының лейтмотивы итеп калкыта. Әсәрдәге вакыйгалар шушы образ ярдәмендә аңлатыла, ул әсәрнең төп идеясен дә ача. Ана теле – ул туган тел, әмма ата теле түгел, тәрбияләп үстергән ананың теле, балага тәрбия, тормыш кануннары, рухи кыйммәтләр шушы тел ярдәмендә сеңдерелә. Ягъни шәхес формалашуда төп рольне ана уйный. Халык булсын өчен – ана теле кирәк, дәүләтнең нигезе – ана теле булган халык. Әмма телне дә, рухны да хатын-кыз, ана саклый. Бу фикер белән тулысынча килешеп тә, романның нинди телдә язылуын игътибарсыз калдырсак, дөрес булмас иде. Автор, ана теленең әһәмиятен һәм ролен дәүләтчелек нигезе белән бәйләгән романын рус телендә язуы белән нәрсә әйтергә тели икән? Икеле стандартлар, бер-берсенә туры килмәгән, хәтта инкяр иткән күренешләр романның башыннан ахырына кадәр дәвам итә.

Романның төп герое Тимучинның анасы Өүләннең прототибы – тарихи Өүлән, чыгышы белән монголларның коңгырат ыруына караган олхонут кабиләсеннән булып санала. Коңгыратлар (кунграт/унгират/кунгират/хонгхират/хонгират/хунгират) монгол халыкларының бер ыруы булып, соңрак төркиләр этногенезында да катнаша. Нурлан Санжар, коңгыратларны – төрки кабилә, үзенең героен да төрки чыгышлы итеп күрсәтә, геройның исемен дә төркиләштерергә омтыла. Шул рәвешле, Өүләннең туган теле төрки тел булып чыга, Өүлән белән монгол Есугейдән туган Тимучин да ярым төрки, ярым монгол була. Төрки телле Өүлән балаларына да үзенең ана телен өйрәтә [Санжар, с. 73]. Чыңгыз ханның һәм аның балаларының теле турында бәхәсләр дәвам итә. Нурлан Санжарның бу бәхәсне үзенчә хәл итүе,

тарихи чыганаклар белән расланмаган очракта да, гипотеза буларак яшәргә, әлбәттә, хаклы.

Өүлэн, бер яктан, телне, тел аша халыкның рухын саклаучы ана буларак тасвирланса, романда аның зирәклек, шәфкатьлелек һәм мәрхәмәтлелек кебек сыйфатлары да ачыла. Безнең көннәргә кадәр сакланган язма чыганаклар буенча, Чыңгыз ханның әнисе яу вакытларында юк ителгән ыру-кабиләләрнең исән калган ятим балаларын тәрбияли. «Юань-чао би-ши» дә Өүлэннең үз балаларыннан башка, мәркәт кабиләсеннән Кучу, тайчиутлар кабиләсеннән Кокочу, татарлардан Шикикан-Хутуху һәм җүрхиннәрдән Бороуле исемле дүрт ятим ир бала үстерүе турында мәгълүмат теркәлгән. Өүлэн тәрбияләгән бу балалар соңрак Чыңгыз хан гаскәрендә нойоннар, ягъни югары хәрби җитәкчеләр булалар һәм ул төзегән империядә төп урыннарны билиләр. Шулай итеп, Өүлэн монгол халкының гуманизм, ана мәхәббәте, батырлык символына әверелә.

Нурлан Санжар Өүлэннең тагын бер сыйфатын ассызыклый: бу аның улы Чыңгыз белән гаять якынлыгы, улына һәрвакыт киңәшләре белән ярдәм итүе. Зирәк ана улының бөек хөкемдар булып җитешүендә, үзәкләштерелгән дәүләт төзүдә, бер дәүләт кысаларында төрки кабиләләрнең һәм монголларның берләшүендә үзеннән зур өлеш кертә. Чыңгыз хан таркау кабиләләрне берләштереп, бердәм законнар булдыра, административ реформа үткәрә, салымнар системасын, ясакның тиешле күләмен билгели, аны җыю өчен административ үзәкләр оештыра. Өүлэн кабиләләрне тынычландыру сәясәте алып бара, башка кабиләләр белән элемтәләрне үстерә. Булачак хөкемдарның уңышлары нәкъ ананың зирәк киңәшләренең нәтиҗәсе буларак аңлатыла. Мәсәлән, романда Өүлэннең үзенә кодалары, Тимучинның хатыны Бөртәнең аналары бүләк иткән кара кеш тунны, мөнәсәбәтләрне яхшырту һәм үз ягына тарту өчен, керәитләр ханы Тогурулга бүләк итүе тасвирлана [Санжар, с. 143].

Нурлан Санжар үзенең романында «Юань-чао би-ши»дә бирелгән мәгълүматны яңарта. Ул яу үткән җирләрдән Өүлэннең исән калган балаларны эзләп йөрүен, коткаруын, аларны тәрбияләвен тасвирлый. Бу эшне, Тимучин өйләнгәннән соң, Бөртә дә дәвам итә. Өүлэн сугышның бөтен фаҗигасын аңлый, әмма сугыш – ирләр эше, хатын-кызныкы – бала табу, аны үстерү, тәрбияләү, ди ул, килене Бөртәне дә, башкаларны да сабырлыкка өндәп [Санжар, с. 62]. Ул Чыңгыз хан кырып узган кабиләләрнең исән калган балаларын коткарып, бераз булса да улының да гөнаһларын киметергә дә омтыла. Икенче яктан, әлеге исән калган балалардан, Нурлан Санжар язганча, беренче булып һөҗүмгә барачак, күпме кешене һәлак итәчәк, сугышларда үзләре дә беренчеләрдән булып үләргә тиешле каа-саклар, ягъни сугышчылар тәрбияләнә, аларны коткару бик шартлы була. Шул рәвешле, Өүлэн, бер яктан, үтерү-яуны кабул итмәсә, икенче яктан, үзе дә үтерер һәм үтерелер өчен сугышчылар үстерә.

Нурлан Санжар романда казакъ этнонимын һәм халыкның этногенезын аңлатырга омтылып, үз интерпретациясен тәкъдим итә. Ул казакъ сүзенең килеп чыгышын каа-сак дигән ике компоненттан торган лексема белән бәйли. Автор аңлатуынча, монгол телендәге *каа* компоненты *бөек* дигәнне аңлата, төрки телдәге *сак* сүзе *сугышчы* дигән мәгънәгә ия. Романда каа-сакларның сугыш балалары, монгол сугышчыларының төрки хатын-кызларны көчләүдән туган балалар булуы бәян ителә. Әмма зур бер этносның башын сугыш һәм көчкә бәйләү белән килешүе кыен.

Романда Җүчи, әсәрнең исеменә чыгуы белән, төп герой булырга дәгъва белдерсә дә, ул Өүлэн һәм Бөртә күләгәсендә кала. Автор Җүчинең тууын бәян иткән тарихи чыганакларга таянып, аның Тимучинның баласы булмавын, ә Бөртә әсирлеккә төшкәннән соң тууын яза. Тимучинның хатыны Бөртәгә булган ихтирамы, мәхәббәте, бу баланы үзенеке дип танырга көч бирсә дә, ул күпләр, хәтта үзенең кардәшләре өчен дә «мәркәт әсирлеге кунагы» булып кала. Роман Җүчинең үлеме белән бәйле вакыйганы алдан уйланылган һәм әзерләнгән тозак буларак аңлата.

Нурлан Санжар Җүчине мәрхәмәтле, гадел шәхес һәм хөкемдар буларак күрсәтергә омтыла. Тарихи чыганаклар да аның Чыңгыз ханның басып алынган халыкларга каршы мәрхәмәтсезлеген кабул итмәве турында язалар.

Җүчинең атасы белән мөнәсәбәте дә романда ахырына кадәр ачылып бетми.

Романда шактый катлаулы тарихи вакыйгалар тасвирлана, алдан хәзерлеге булмаган укучы әлеге вакыйгаларда югалып калачак. Күпсанлы геройлар, аларның исемнәре, топонимнар, яу-сугышлар буталчыклык тудыра.

Автор геройлар барасы юлларның озын булуын хәбәр итә, ләкин вакыт һәм пространство аралыгы күрсәтелми, тарихи вакыйгалар еш кына аерым эпизодлар буларак килеп керә, аларның гомуми масштабы билгеләнми. Автор хикәяләүне бер пункттан икенчесенә күчерә, табигать күренешләре һәм сезоннар алмашыну тасвирланмый, геройларның психологик халәте тиешенчә ачылмый. Мондый вакыт-урын һәм ераклык характеристикаларын исәпкә алмау, тасвирлауда детальләштерүнең системалы булмавы, ягъни абстракт хронотоп – тарихи романнарга түгел, халык эпосы өчен характерлы үзенчәлек. Нәтиҗәдә тасвирланган вакыйгаларның асылын, дәвамлылыгын бары тик читләтеп кенә ачыкларга мөмкин.

Романда аерым сүзләр дә һәрвакыт урынлы кулланылмаган, ягъни сурәтләнгән чорга яки күренешләргә туры килмиләр. Мәсәлән, автор шаман җыры буларак рус телендә биргән текстта шәмчырак дигән сүз бар:

> У тюрков есть камень смыслов,
> Он зовется Шамчирак [Санжар, 2019, с. 91].

Бу сүзнең беренче компоненты төрки телләргә фарсы شمع (šam›) һәм гарәп телләре аша شمع (šamʿ) кереп, ислам дине аша таралган очракта да, аңа кадәр үк предметы белән бергә үзләштерелгән очракта да, гаҗәеп тотрыклылык саклаган борынгы йола текстларына керүе шикле. Мондый төгәлсезлекләр, әлбәттә, романның тарихилыгына хилафлык китерә.

Нурлан Санжарның «Көтелмәгән кунак – Җүчи» романы тарихи вакыйгаларга нигезләнеп язылган әсәр. Аның нигезен тарихи чыганаклар тәшкил итеп, язучы бу вакыйгаларны яңача аңлатырга, тарихның ачылмый калган сорауларына җавап табарга тырыша. Автор Җүчи образын бары уңай яктан, идеал хөкемдар буларак сурәтләргә омтыла. Шул ук вакытта бу омтылыш Чыңгыз ханның башка балаларын, бигрәк тә икенче улы Чагатайны, тискәре яктан гына күрсәтүгә китерә. Тарихның үз закончалыклары бар, шуңа күрә дә тарихи шәхесләрне дә, вакыйгаларны да берьяклы гына ачу, тарихның ачылмаган сорауларына катгый җавап бирергә омтылу уңышка илтми. Әмма яшь буынга тарихи вакыйгаларны җиткерү, ватанпәрвәрлек хисе тәрбияләү ягыннан, әлбәттә, роман фәкать уңай яктан гына бәяләнә ала.

**Әдәбият**

*Санжар Нурлан*. Нежданный гость – Джучи. Алматы: Meloman Publishing, 2019. 272 с.

*Санжар Нурлан.* Бату-хан. Алматы: Meloman Publishing, 2021. 330 с.

*Танкаева Гульнар.* Баллада о матери Чингисхана. URL: https://forbes.kz/life/afisha/ballada_o_materi_chingishana (мөрәҗәгать көне: 2.09.2023).

*Публикация статьи осуществлена в рамках выполнения научно-исследовательского проекта AP0 9261068 «Идея государственности и концепция исторической личности эпохи Золотой Орды в контексте художественной литературы».*

*Мәкалә «Әдәбият контекстында Алтын Урда чорының дәүләтчелек идеясе һәм тарихи шәхесе концепциясе» AP0 9261068 фәнни-тикшеренү проектын үтәү кысаларында әзерләнде.*

***Закирова Илсөяр Гамил кызы,***
*филология фәннәре докторы, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге баш фәнни хезмәткәре*

***Даутова Сауле Баттал кызы,***
*филология фәннәре докторы, Казакъ милли педагогия университеты профессоры*

УДК 821.512.145

***Ф.Х. Миңнуллина***

# СУГЫШТАН СОҢГЫ ЕЛЛАР (1945–1950) ТАТАР ДРАМАТУРГИЯСЕ: ЗАМАН ГЕРОЕН ЭЗЛӘҮ (Т. Гыйззәт, М. Әмир, Р. Ишморат әсәрләре мисалында)

Великая Отечественная война оказала влияние в татарскую драматургию, на характер культуры в целом. Необходимость защиты родной земли от врагов активизировала звучание патриотических чувств. В центре пьес оказались мотивы призыва к борьбе с захватчиками, веры в победу. В статье рассматриваются татарские пьесы, написанные в 1945–1950-е годы XX века. Основной целью пьес в эти годы было обобщение событий войны, показ источников победы. Автор отмечает создание пьес, описывающих суровые будни войны без романтизма, изображающих труд советских людей.

**Ключевые слова:** татарская драматургия, Великая Отечественная война, трансформация, герой.

The Great Patriotic War had an impact on Tatar drama, on the nature of culture as a whole. The need to protect the native land from enemies intensified the sound of patriotic feelings. At the center of the plays were the motives of the call to fight the invaders, the belief in victory. The article discusses Tatar plays written in the 1945–1950-ies of the XX century. The main purpose of the plays in these years was to summarize the events of the war, to show the sources of victory. There are plays describing the harsh everyday life of the war without romanticism, depicting the work of Soviet people.

**Keywords:** Tatar drama, the Great Patriotic War, transformation, hero

Бөек Ватан сугышы башлану белән татар әдәбиятында халыкны көрәшкә чакыру, җиңүгә ышаныч, илне сакларга ант итү мотивлары үзәккә куела. Татар драматургиясе дә халыкны патриотик рухта тәрбияләүгә, Ватан азатлыгы, халыкның җиңелмәс көче, героик сыйфатлары, саф мәхәббәт, фидакяр хезмәт кебек мәсьәләләрне яктыртуга игътибар бирә. Бу Т. Гыйззәтнең «Изге әманәт», Н. Исәнбәтнең «Мәрьям», М. Әмирнең «Миңлекамал», Ф. Кәримнең «Шакир Шигаев», Р. Ишморатның «Кайту» һ.б. пьесаларында аеруча ачык чагыла. Сугыш башланган чорда язылган пьесаларда, гадәттә, совет кешесенең батырлыгы, тырышлыгы романтик рухта бирелә (Т. Гыйззәт. «Төнге сигнал», М. Әмир. «Партизан Иван», Н. Исәнбәт. «Мәрьям», Р. Ишморат. «Ватан кызлары», Г. Насрый. «Таныш кешеләр», «Патриотлар семьясы») [Шәрипова, 2022, б. 96]. Р. Ишморатның «Кайту» (1942), М. Әмирнең «Миңлекамал» (1944) кебек пьесалары исә героик эчтәлекле булып, халыкның тыл тормышындагы фидакяр хезмәтен, ватандашларының җиңүгә ышанычын, матур киләчәккә зур өмет белән каравын күрсәтә. Бөек Ватан сугышы тәмамланганнан соң,

драматурглар геройларны тасвирлауда бертөрлелеккә юл куймаска омтылсалар да, әдәби әсәрләрнең сәнгатьлелек дәрәҗәсе төшә. Пьесаларда тормышны турыдан-туры яктырту күзәтелә. Социализм үсешендә ачык каршылык юкка чыга дигән сәяси концепция әдәбиятта конфликтсызлык теориясен китереп чыгара. Сугышта җиңүне социализм җиңүе дип раслау, шәхеснең ролен игътибардан читтә калдыру гомуми тенденциягә әверелә [Заһидуллина, 2023]. Сугыш темасы барлык жанрларда дәвам итә: сугыш кырында ятып калганнарны юксыну, сагыну, батырлыкка дан җырлау мотивлары әйдәп бара. Мәсәлән, Т. Гыйззәтнең «Чын мәхәббәт» драмасында Гөләндәм образы, аның уйлары, эш-гамәлләре, өметләре һәм кичерешләре игътибар үзәгенә куелган. Ире сугышка китеп югалгач, Ватанга булган тирән мәхәббәте Гөләндәмгә, очучы булып, дошманнарны тар-мар итүдә катнашырга ярдәм итә. Ләкин әсәрдә сюжет таркаулыгы, кайбер образларның эшләнеп җитмәгәнлеге, характер буларак ачылып бетмәүләре сиземләнә. Мисал итеп, әсәрдә тискәре, үз мәнфәгатьләрен генә кайгыртып йөрүче буларак гәүдәләнеш тапкан Дәүранны китерергә мөмкин.

Югарыда әйтелгәнчә, әсәрләрнең күпчелегендә конфликтсызлык теориясе өстенлек итә. Бу теориядән күпмедер дәрәҗәдә Н. Исәнбәтнең «Рәйхан» (1949), Ю. Әминовның «Язылмаган законнар» (1957), Ш. Хөсәеновның «Чулпан» (1956), Ә. Фәйзинең «Рәүфә» (1958) кебек драмалары читтә кала [Мусин, 2017, б. 36]. Т. Гыйззәтнең «Чын мәхәббәт», «Алсу таң», Р. Ишморатның «Якты юл» (1947), «Идел буенда» (1949), М. Әмирнең «Җыр дәвам итә» (1948) пьесалары исә конфликтсызлыктан, ясалмалылыктан азат түгел. Шулай да, Р. Ишморатның «Якын дус», «Яңа бистәдә», Н. Исәнбәтнең «Гүзәл», Г. Насрыйның «Кушнарат», «Кадерле минутлар» кебек пьесалары (1950–1952) заман героен эзләүдә бер омтылыш булып торалар. Сугыш темасы белән янәшә бу еллар драматургиясендә хезмәт темасына да зур урын бирелә. Язучылар иҗат иткән геройлар дөньяны үзгәртерлек батырлар буларак гәүдәләнә. Фронтовикларның тыныч хезмәткә кайтуы, авылда яки завод-фабрикалардагы эшчәнлекләре сурәтләнә. Мәйданга чыккан нефтьчеләр (А. Әхмәт. «Серләр»), завод эшчеләре тормышы (Р. Ишморат. «Якын дус») драматургиягә дә күчә. Сугыштан кайткан геройның очраклы кимчелекләр, кеше холкы тудырган аерым проблемалар белән көрәшүе үзәккә куела. Бу елларда сугыш темасы белән янәшә шәһәр һәм эшчеләр сыйныфы, фән кешеләре, фәннең производство белән бәйләнеше, эшчеләрнең әхлак, гаилә, көнкүреше кебек мәсьәләләр актуаль тема-проблемалар буларак көн тәртибенә куела. М. Әмирнең фән кешесе турындагы «Профессор Саматов», Т. Гыйззәтнең «Чын мәхәббәт» пьесалары, А. Әхмәтнең (Абдулла Сафиулла улы Әхмәтов) инженер-геологлар хакындагы «Серләр» драмасы шундый темаларга алынуның уңышлы мисалы булып тора [Ханзафаров, 2017, б. 351]. Р. Ишморатның «Якын дус» (1949), «Бүләк» (1947) пьесаларында исә фәннең

производство белән бәйләнеше, завод-фабрика эшчеләренең хезмәте тасвирлана. Мәсәлән, «Бүләк» пьесасының төп герое, стахановчы Заһит, үз станогында автоматлаштыру тәҗрибәләре үткәрә. Моңа кадәр 2–3 норма арттырып үтәп килгән эшче, бер ярым норма бирү белән генә чикләнә. Бу вакыйгалар хезмәттәшләрен, парткомны да, сөйгән кызы Галияне дә уйга калдыра. Егет, Варламов янына килеп, зур эшкә алынуын аңлата. Вакыйгалар үстерелешендә Заһитның максатына ирешүе ачыклана. Ә. Камал фикеренчә, пьеса бик үк ышанып бетеп булмый торган урыннардан да азат түгел. Мәсәлән, «Заһитның тыйнаклыгы шулкадәргә барып җитә, ул үзенең яңа проектын хәтта парткомнан да яшереп эшли. Заһит фатирында бер «кыз»ның барлыгын белү белән, җитмәсә, аны үзе күреп тә түгел, күптәннән телчәнлеге белән танылган хатынның гайбәтенә генә ышанып, Галия Заһитка үпкәли. Мондый кыланчыклык безнең хәзерге эшче кызларыбызның холкына хас якмыни?» – дип яза мәкалә авторы [Камал, 1951, б. 116].

Сугыштан соң иҗат ителгән пьесаларның үзәк геройлары – фронтта булып кайткан ир-егетләр. Ватан азатлыгын саклауда зур батырлыклар күрсәткән Газиз (А. Әхмәт. «Серләр»), Әсгать, Хәйдәр (Ә. Фәйзи. «Отышлы кияү»), Мирсәет (Р. Ишморат «Якты юл»), Хәйри (М. Әмир. «Тормыш җыры»), Мостафа, Володя (Р. Ишморат. «Җыр дәвам итә»), Мирсәет (Р. Ишморат. «Якты юл»), Харис (Г. Насрый. «Кушнарат») һ.б. шундыйлардан. Бу геройлар тыныч тормышта тынгысыз көрәшчеләр, завод-фабрикаларны, авыл хуҗалыгын аякка бастыруда алгы сафта баручылар буларак ачылалар. Р. Ишморатның «Якты юл» (1947) пьесасында элеккеге фронтовик, колхоз кырларыннан югары уңыш алу өчен көрәшүче Мирсәет, партия оештыручысы Зөлфия, Фәрдәнә, Кашшаф кебекләр күрсәтелгән. Әмма әсәрдә геройларның фикерләү рәвешләренә, коры сөйләмнәренә күп урын бирелә. Пьесада җизнәсе Гафур белән каенесе Мирсәет арасында бер гектардан 140 пот уңыш алу-алмау хакында бәхәс бара. Мирсәет җизнәсе урынына колхоз председателе булып килә һәм максатына ирешә. Беренче пәрдәдә беркадәр дәрәҗәдә каршылык күрсәткән Гафур алга таба конфликтка керми. Нәтиҗә буларак, әсәр үсештән туктала, карашлар бәхәсе сүрелә төшә. Т. Гыйззәт сүзләре белән әйткәндә, «Әсәрдә конфликт бетә, көрәш юкка чыга» [Гыйззәт, 2000, б. 106]. Драматург Җәүһәрия шикелле җилбәзәкләрне, Габделмән кебек салам урлап йөрүчеләрне тасвирлап, әсәрдә күпмедер дәрәҗәдә кискен конфликтлар тудырырга омтылыш ясап карый. Әмма эш процессында туган авырлыклар, шуларны җиңәрдәй батырлык күрсәтүче геройлар сурәтләү объекты итеп алынмый.

Әлеге күренеш язучы-прозаик һәм драматург А. Әхмәтнең «Серләр» драмасында да чагылыш таба. Монда да көрәш юк дәрәҗәсендә. Әдип сугыштан соң, татар язучылары арасында беренчеләрдән буларак, нефтьчеләр тормышына һәм хезмәтенә багышланган «Кара алтын» (1947), «Яшәү көче» (1951) исемле очерк китапларын бастыра,

«Серләр» (1948), «Егет сүзе» (1954) исемле драма әсәрләрен яза. Авторны Татарстанда нефть сәнәгате барлыкка килү, хезмәт процессы кызыксындыра. Яңа заман яшьләре, хезмәт батырлары образлары иҗат итеlә. Яшь кыз Рәхимә, Газиз, Иванов – шундыйлардан. Автор геологларның үзләренә генә хас холык-фигылен ача, аларны эш процессында күрсәтә. Пьеса Кәлимәт авылы тирәләрендә нефть ятмалары эзләү белән бәйле вакыйгалардан башлана. Язучы нефтьчеләр тормышын сурәтләү аша төрле холыклы кешеләрнең, төрле милләт вәкилләренең бердәм хезмәтен ача. Кара алтын эзләү эшенең башында торган механик Газиз, сугыш башлану белән фронтка китә. «Механик – сугыш вакытында танкист инде ул» [Әхмәт, 1949, б. 25], – ди ул. Ә Кәлимәт авылы басуында бораулаучылар, алны-ялны белми, җир мае эзли. «И в а н о в. Без фронтка танклар һәм танкистлар биреп кенә калырга тиеш түгел, без танкларны йөртә торган нефть тә бирергә тиешбез» [Әхмәт, 1949, б. 26], – диелә бу хакта әсәрдә. Ирләр белән янәшә бу авыр хезмәтне инженер-геолог, комсомолка, яшь кыз Рәхимә Сәлимова да башкара. Тылда эшче көчләр җитешмәүдән интеккән авыр көннәрдә сугыш җәфаларын иңнәренә салган хатын-кызлар Шәмсекамәр, Гашыйка, Сәхипҗамал нефть чыгару эшенә дә тотыналар:

«Ш ә м с е к а м ә р. Исәннәрмесез!

Н а р е к и й. Исәнмесез!

Ш ә м с е к а м ә р. Без әле генә егетләрне фронтка озаттык. Аларның өчесе дә нефтьтә эшләгән ие бит. Менә без... Гашыйка. Алар урынына.

С ә х и п җ а м а л. Скважинага.

Ш ә м с е к а м ә р. Колхоздан.

Г а ш ы й к а (*төзәтенеп*). Комсомол җибәрде» [Әхмәт, 1949, б. 27]. Алар үз дигәннәренә ирешә – нефть фонтаны табыла. Бу катлаулы хезмәттә аларга сугыш кырыннан яраланып кайткан Газиз дә кушыла. Шул рәвешле, автор Газиз, Иванов, Рәхимә образлары мисалында нефтьчеләр көчен данлый. Әсәрдә яңа заман, яңа яшәешнең нефть белән бәйле контрастлары – уңай (заман технологиясен үзләштерү, техник интеллигенция оешу) һәм тискәре (экологик афәт) күренешләр урын ала. Нефть продуктларының суны, әйләнә-тирә мохитне пычрату мөмкинлеге булу да чагылыш таба. Әсәр үз тәртибе, үз көе белән яшәүче төбәкнең үзгәрүе, аңа яңа заман сулышы килеп керү белән тәмамлана.

Ә. Фәйзи 1947 елда «Отышлы кияү» комедиясен иҗат итеп, киң җәмәгатьчелек игътибарына фронтта булып кайткан Әсгать Моратов, Хәйдәр Арсланов кебек образлар тәкъдим итә. Вакыйгалар үстерелешендә автор батыр сугышчылар ярдәмендә хезмәт урыннарын үз мәнфәгатьләре өчен файдаланырга омтылган бюрократ җитәкчеләрне һәм хезмәткәрләрне тәнкыйть утына тота. Әлеге күренеш язучының башка әсәрләрендә дә урын ала. Мәсәлән, «Сурыкмасов («Төтен»), Дуамалов, Туманский («Дуамалов һәм башкалар») –

шундыйлардан. Хафиз («Отышлы кияү»), Вильдан («Акчарлаклар», 1941–1949) кебекләр дә үз хаҗәтләрен генә кайгыртып көлкегә калалар. Рауза («Отышлы кияү») кебекләр – бизәнеп-ясанып кына яхшы кияүгә чыгу хакында хыялланучылар да – көлү объектына әверелә. «Акчарлаклар» музыкаль комедиясендә, мәсәлән, «Якты ялан» колхозы председателе вакыйгалар үстерелешендә көлке хәлгә кала. Әсәрдәге геройлардан Зәйтүнә, Шәмсия, Зиннәт, Фәтхи һ.б. – кечкенәдән үк авыл эшендә кайнап, хезмәт белән чыныгып үскән кыю һәм алга омтылучы авыл яшьләре. Зәйтүнә белән күрше авыл егете гармунчы Зиннәт арасында мәхәббәт хисләре уяна. Колхоз рәисе Вильданның бу эшкә эче поша, ачуы килә. Ул, Зәйтүнәне колхозда калдыру өчен, үз авылы егете зоотехник Фәтхи белән кавыштыру юлын эзли.

«Ф ә т х и (*күңелсез*). Зиннәтне үпкәләттек бит, Вильдан абзый, шәп түгел бит!

В и л ь д а н. Әйе, әйе. Күңелсезрәк килеп чыкты. Әмма кайгырма, без синең белән колхоз өчен Зәйтүнәне саклап калдык! Хәзер ычкындырма инде үзен!...» [Фәйзи, 1985, б. 354], – диелә бу хакта әсәрдә. Комедиянең финалы традицион: Зәйтүнә сөйгәне Зиннәт белән кавыша.

М. Әмирнең «Тормыш җыры» (1946), «Җыр дәвам итә» (1947), Г. Насрыйның «Кушнарат» пьесаларында да татар кешесенең сугыш кыры һәм тылдагы батырлыгы, туган илгә бирелгәнлек, хезмәт сөючәнлек, тормышка оптимистик караш кебек күркәм сыйфатлары чагылдырыла. А. Салихова фикеренчә, Г. Насрыйның «Кушнарат»ын уңышлы әсәр дип атап булмый. Дөрес, сугыштан соңгы беренче елларда әдәбият белемендә хөкем сөргән конфликтсызлык теориясе Г. Насрый иҗатына да йогынты ясый. Заман рухына хас булганча, биредә 50 нче еллар драматургиясендә үзәктә торган социалистик хезмәт темасы күтәрелә. Пьесада хезмәт кешене тәрбияләү чарасы, бәхет чыганагы итеп карала. Геройларның әхлакый йөзе дә хезмәткә мөнәсәбәттә бәяләнә. Биредә автор, Ә. Фәйзинең «Акчарлаклар» әсәрендәге кебек, колхозларны үстерү, уңыш арттыру өлкәсендәге актив эшчәнлекне күрсәтә. Сугыш кырында батырлыклар кылып кайткан Харис тыныч тормышта «Ялкын» колхозы председателе вазифасын башкара.

«Ш а к и р җ а н. Акыл бит яшьтә түгел, башта. Безнең Харис башлы егет булып чыкты, мин әйтәм. Соң шулай димичә. Казанда укып, агроном исемен алды. Сугыштан кайткач, үзен председатель итеп сайладык. Өч ел эчендәниләр генә эшләмәде ул!.. Лаборатория оештырды. Кырларыбызны сортлы орлык белән күмде. Агроном бит ул, агроном! Үткән ел тагын укырга китте» [Насрый, 1952, б. 17]. Бу уңайдан «Маяк», «Чаткы», «Ялкын» колхозларын кушып, яңа сортлы орлыклар белән зур уңыш алуга, электростанция ачуга ирешкән Харисның сүзләрен китерү урынлы булыр: «Ә халыкка хезмәт итү – коммунизм төзү өчен көрәшнең алдынгы сафында бару дигән сүз. Ләкин

“Ялкын” кебек вак колхозлар белән зур максатка ирешүе авыр. Колхозларның бөтен эше хәзер фән һәм техника көченә корылган. Шундый зур көчне кечкенә басуларга сыйдырып буламы? Юк, булмый! Председательләр курсында укыган чакта мин Кубань егетләре белән сөйләштем, һәм миндә шундый фикер туды: Татарстан басуларын, Кубань далалары кебек, мул икмәк арсеналына әйләндереп булмыймыни?! Мөмкин бит, бик мөмкин. Моның өчен вак колхозларны кушарга, кечкенә басуларны зурайтырга кирәк. Алдынгы техниканы бөтен ходка җигәргә! Колхоз кырларын галимнәр лабораториясенә әйләндерергә! Менә мин өч ел председатель булып эшлим. Колхозыбызның лабораториясе бар. Сортлы орлыклар чәчәбез. Ә нәтиҗәсе?! Егерме-утыз гектар җирдән югары уңыш алып кына колхозларны баетып буламы соң? Булмый бит, Госман абзый, булмый! Ә халык җиребезнең “мул” уңыш бирүен, колхозларыбызның баюын, коммунизм чорының якынаюын тели. Халык югары максатка омтыла. Шушы зур һәм кыю омтылышның алдында бару – безнең изге бурычыбыз» [Насрый, 1952, б. 28]. Заман каһарманының гүзәл образын күрсәтү максаты белән язылган драмада геройлар тиешенчә ачылып бетмәгән. Ул, гомумән алганда, декларатив һәм статик. Шулай да, пьеса заман герое эзләү, фән-техника казанышларын яктырту омтылышы ягыннан игътибарга лаек.

М. Әмирнең «Тормыш җыры» (1946), «Җыр дәвам итә» (1947), Р. Ишморатның «Якты юл» (1947), «Якын дус» кебек сәхнә әсәрләре конфликтсызлык «теориясе» кануннарына яраклаштырыла, финал традицион рухта хәл ителә – аерым геройлар заманга хас кимчелекләрдән азат ителеп, гаепләрен танып, яхшы якка үзгәрәләр. Пьесаларда хезмәт кешесен эш урынында сурәтләгән беръяклы концепция өстенлек итә. Кешенең иҗтимагый һәм шәхси тормышындагы каршылыклар читтә кала.

Бу чор татар драматургиясендә эчке һәм тышкы матурлыкка ия булган көчле рухлы татар хатын-кызы образларын да бирде. Совет әдәбиятының бу өлкәдәге новаторлыгын хатын-кызларны коллектив хезмәт процессы аша тасвирлавында күрергә мөмкин. Илдә барган күмәк хуҗалыкларга берләшү процессы яңа кешеләр үстерде. Татар совет язучылары көрәшләрдә чыныккан, социалистик төзелешнең барлык тармаклары белән кызыксынучы, киң колач белән хәрәкәт итүче хатын-кызларны мәйданга чыгарды. Совет хатын-кызлары Ватанны саклау эшендә бәяләп бетергесез хезмәт күрсәтте. Алар фронт өчен үз-үзләрен аямыйча эшлиләр, сугыштан соңгы барлык кыенлыкларны нык торып кичерәләр. Шушындый җаваплы чорда, башка проблемалар белән беррәттән, әдәбиятта хатын-кыз образын киң күләмдә чагылдырган әсәрләр барлыкка килде. Фатыйма (М. Әмир. «Тормыш җыры»), Зәйтүнә (Ә. Фәйзи. «Акчарлаклар»), Сабира, Наилә (М. Әмир. «Наилә») һ. б. әдәбиятта татар хатын-кызына хас характерны чагылдырган образлар буларак тәкъдим ителәләр. М. Әмир «Тормыш җыры» драмасында сюжетны бер җыр

тирәсендә кора. Фашистлар тылында сугышкан Басыйр яраткан хатыны Фатыймага карата мәхәббәтен, Ватанга тугрылык хисләрен үзе язган җыр белән хәбәр итә. Әсәрнең исеменә үк чыгарылган «җыр» сүзенә символик мәгънә салынган. Ул, бер яктан, Басыйрның сөйгәне Фатыймага багышлап язган җырын – мәхәббәтен белдерсә, киңрәк планда «яшәү» мәгънәсен аңлата [Ганиева, 2017, б. 69].

Кайтмый калсам, туфрак булсам, бәхил бул!
Елак булма, Фатыймам, батыр бул!
Туган илдән көч алырсың,
Миңа тиң дуслар табарсың,
Мин җыр булып сиңа кайтырмын.
[Әмир, 1985, б. 95]

М. Әмирнең «Наилә» (1947) комедиясендә дә Наилә, бригадир Сабира кебек алдынгы колхозчы хатын-кызларны күрәбез. Алар ир-атлар белән янәшә хезмәт итеп, бригадалар арасындагы ярышта җиңеп чыгалар.

1945–1950 еллар драматургиясендә тормышны, яшәешне күбрәк тышкы яктан, совет иленең сугыштан соңгы тыныч тормышта ирешкән уңышларын күтәренке публицистик рухта яктырту белән чикләнелә. Әдәбиятның тормышчанлыгы кимү, каршылыкларны шомартып сурәтләү үзен нык сиздерү, «конфликтсызлык теориясе»нең зур зыян китерүе, төзелешләр, хезмәт җиңүләре белән мавыгып, әдипләрнең еш кына кеше шәхесен икенче планда калдырулары күзәтелә. Әкренләп, яңа әдәби герой – элеккеге фронтовик – мәйданга чыга. Фронтта туган илен саклаган геройның тыныч тормыштагы катып калганлык, эгоизм һ.б. тискәре күренешләрне тәнкыйть итүе бирелә. Сугыштан соңгы чорда илдә барган хәл-вакыйгаларны уңай яктан гына яктырту өстенлек итә. Геройларның гомуми эшкә, дәүләт һәм халык эшенә тулысынча бирелгәнлеге алгы планга чыга.

**Әдәбият**

*Ахмадуллин А.Г.* Татарская драматургия: истоки и проблемы. Казань: Татар. кн. изд-во, 2012. 482 с.

*Әмир М.* Тормыш җыры // *Мирсәй Әмир.* Сайланма әсәрләр: 3 томда. 2 т.: пьесалар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1967. Б. 95.

*Әхмәт А.* Серләр // Казан утлары. 1949. № 5. Б. 5.

*Ганиева А.Ф.* Мирсәй Әмир драмаларында чор проблемаларын яктырту үзенчәлеге // Восток-Запад: литература и художественная культура: Сб. материалов Междунар. науч.-практ. конф.. (Казань, 2017). Казань, 2017. С. 68–71.

*Гыйззәт Т.* «Серләр» // *Гыйззәтов К.* Таҗи Гыйззәт // Казан: Мастер Лайн, 2000. Б. 108.

*Заһидуллина Д.* Чал татар әдәбиятының 100 елы. URL: https://kazanutlary.ru/news/d-bi-t-nkyjt/chal-tatar-dbiyatyny-100-ely-dvamy (мөрәҗәгать көне: 18.09.2023).

*Камал Ә.* Р. Ишморат драмалары. URL: https://kazanutlary.ru/j-archive/journal-materials/1951-3/riza-ishmorat-dramalary?ysclid=lmnggfbknc192632153 (мөрәҗәгать көне: 21.09.2023).

*Мусин Ф.* Әдәби хәрәкәт // Татар әдәбияты тарихы: 8 томда. 5 т.: 1917–1956 еллар. Казан: Татар. кит. нәшр., 2017. 2017. Б. 16–39.

*Насрый Г.* «Кушнарат» // Казан утлары. 1952. № 4. Б. 8

*Фәйзи Ә.* Әсәрләр: 5 томда. 3 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. 454 б.

*Ханзафаров Н.* Татар әдәбияты тарихы: 8 томда. 5 т.: 1917–1956 еллар. Казан: Татар. кит. нәшр., 2017. 2017. 623 б.

*Шарипова А. С.* Татарская драматургия XX – начала XXI в.: инвариант и его исторические трансформации: дис. ... д-ра филол. наук. Казань, 2022. 322 с.

***Миңнуллина Фатыйма Хәлиулла кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әдәбият белеме бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 821.512.145

***А.Ф. Ганиева***

# А. ХӘЛИМНЕҢ «ХУНВЭЙБИН» РОМАНЫНДА МИЛЛӘТ ОБРАЗЫ: ИМАГОЛОГИК АСПЕКТ

Данная работа посвящена анализу романа Айдара Халима «Хунвэйбин» с имагологической точки зрения. Автор статьи дает краткое определение имагологии, которая является одной из ветвей современной компаративистики. Изучение отражения «чужого» образа в литературе сегодня является одной из важнейших задач в литературоведении.

**Ключевые слова:** имагология, образ, главный герой, татарская литература, роман, Айдар Халим.

This work is devoted to the analysis of the novel by Aidar Halim «Hongweibing» from an imagological point of view. The author of the article gives a brief definition of imagology, which is one of the branches of modern comparative studies. The study of the reflection of an «alien» image in literature today is one of the most important tasks in literary criticism.

**Keywords:** imagology, image, main character, Tatar literature, novel, Aidar Halim.

Милләтара бәйләнешләрдә үзара теләктәшлекне саклау өчен, бер халыкның икенчесе турындагы карашларын, бер-берсенә мөнәсәбәтен өйрәнү мөһим. «Халыкларның милли үзаң үсеше, хәзерге җәмгыятьнең күп мәдәниятләрдән торуы, анда төрле милли билгеләнешләр, конфессияләр, идеологияләр яшәве диалог, коммуникация, “башканы” аңлау кебек проблемаларны көн үзәгенә куя» [Аминова, 2010, с. 51].

Бүгенге көндә гаять актуаль булган мондый мәсьәләләр белән гуманитар фән тармагы – имагология шөгыльләнә. Имагология (имаго – латинчада *образ*, *чагылыш*, грек телендә – *сүз, белем* мәгънәсендә) бер халык мәдәниятендә, әдәбиятында башка халыкның образлы сурәтләнешен өйрәнүче, тарих, культурология, социология белән бәйләнешле фән тармагы. Беренче тапкыр имагология термины 1920 елларда социология фәнендә кулланыла башлый. 1950–1960 елларда француз әдәбияты галимнәре (Ж.-М. Карре, М.-Ф. Гийяр) хезмәтләре аркылы гуманитариянең башка өлкәләренә дә үтеп керә. Х. Дизеринк, Д.А. Пажо, М. Фишер, Й. Леерсен – имагология өлкәсендә танылган галимнәр. Рус әдәбияты белгечләреннән Н.А. Ерофеев, Л.З. Копелев, Е.Ю. Артемова һ.б. җитди тикшеренүләр алып баралар. Бүгенге көндә имагологик мәсьәләләрне өйрәнүгә бәйле фәнни семинарлар, конференцияләр үтә. Махсус басмалар (мәсәлән, «Имагология и компаративистика» журналы, Томск) нәшер ителә.

Имагология, халыклар мәдәниятендә барлыкка килгән стереотипларны һәм образларны өйрәнү өлкәсе буларак, үз эченә психология,

социология һәм башка гуманитар фәннәрне ала. Ул – чагыштырмача яңа фән, шуңа аның өйрәнү методлары да әлегә формалашып җитмәгән. Әмма билгеле бер өлкәләрдә тикшеренүләргә басым ясаган имагология тармакларын аерып карарга мөмкин. М. Бойцов, мәсәлән, «Власть һәм образ» хезмәтендә түбәндәге классификацияне тәкъдим итә:

1) әдәбият белеме имагологиясе;

2) потестар имагология;

3) лингвистик имагология [Бойцов, 2010, с. 5].

Лингвистик имагология башка халык яки илнең тел-сөйләм чаралары аша тудырылган образын өйрәнә. Монда бер телдә сөйләшүчеләрнең икенче телгә мөнәсәбәтле стереотипларнына игътибар итү мөһим.

Фәндә шулай ук тарихи, иҗтимагый, психологик имагологияләр дә формалашып килә. Тарихи имагологиянең бер тармагы – потестар имагология. Ул хакимият образларын кабул итү белән бәйле проблемаларны өйрәнә. Әлеге тармакның үзенчәлеге шунда: ул дәүләтләрне, дәүләт төзелешләрен төрле тарихи этапларда бер-берсе белән чагыштырып һәм каршы куеп тикшерә.

Әдәбиятта «үзеңнеке» һәм «читнеке»нә бүлеп карау борынгы чорлардан ук килә. Гомумән, ул – әдәбиятның нигезенә салынган концепция. Язучылар үз әсәрләрендә иҗтимагый, этник, психологик, мәдәни, сәяси-идеологик карашлардан чыгып, төркемнәрнең каршылыгын, үзара бәйләнешләрен чагылдыралар. «Имагологиядә «читләр» образы милли аң стереотибы буларак карала, ягъни конкрет социаль-тарихи тирәлектә барлыкка килгән «чит» турында тотрыклы, эмоциональ яктан бай, гомумиләштерелгән күзаллаулар өйрәнелә. Имагология «чит» образын ачып кына калмый, шулай ук, рецепция һәм бәяләү процессларына бәйле рәвештә, кабул итүче субъект үзен дә характерлый, ягъни үзаңын һәм үзенең милли кыйммәтләр системасын чагылдыра» [Папилова, 2011].

Әдәбият белемендә имагология компаративистиканың бер бүлеге буларак карала, әдәби әсәрләрдә һәм халык авыз иҗатында «чит» (башка мәдәният вәкиле буларак) образларны анализлый. Рус-татар әдәби бәйләнешләренә татар әдәбият белеме фән буларак оеша башлаган чорда ук игътибар ителә. Г. Нигмәти, Г. Сәгъди, Г. Газиз, Г. Рәхим, алга таба М. Гайнуллин, И.Г. Пехтелев, Э. Нигъмәтуллин, Й. Нигъмәтуллина һ.б. хезмәтләрендә ике милләт сүз сәнгатендәге охшашлык һәм аермалыклар төрле яссылыкта тикшерелә. Бүгенге көндә компаративистика өлкәсендә уңышлы эшләүчеләр дип Р.Ф. Мөхәммәтшина, Ә.Ф. Галимуллина, В.Р. Әминева, М.И. Ибраһимов, А.З. Хәбибуллиналарны атарга кирәк. Әдәби багланышлар күбрәк типологик үзенчәлекләргә бәйле өйрәнелә. В.Р. Әминева үзенең «Типы диалогических отношений между национальными литературами (на материале произведений русских писателей второй половины XIX в. и татарских прозаиков первой трети XX в.)» монографик хезмәтендә

төрле чорга караган ике милләтнең классик проза әсәрләрен тикшереп, алар арасындагы диалогик мөнәсәбәт типларын күрсәтә. Автор «үзеңнеке» һәм «чит» дихотомияләренә бәйле рус һәм татар әдәбиятлары арасындагы дүрт төрле диалогик бәйләнешне аерып чыгара. Алар: «үзеңнеке»нә капма-каршы куелган «чит», «үзеңнеке» белән каршылыкка кергән «чит», үзгәртеп корылган «чит» буларак «үзеңнеке» һәм «үзеңнеке» белән охшаш «чит». Әлеге хезмәттә имагологик эзләнүләр шактый: монда да милли эстетик аңның «башка»ны кабул итүе яки кире кагуы өйрәнелә. Әмма имагология, компаративистиканың бер тармагы булса да, максаты чагыштыру гына түгел. Анда төп игътибар башка милләтнең әдәби образы сурәтләнешенә юнәлтелә.

Күпгасырлык татар әдәбиятында татар белән аралашып яшәгән башка халыкларның да милли образлары формалашкан. Әлеге мәкаләдә без Айдар Хәлимнең «Хунвэйбин» роман-эпопеясын имагологик нигездә тикшерүгә омтылыш ясадык. Әсәр зур күләмле: алты кисәкне берләштергән өч томнан гыйбарәт. Сурәтләү масштабы ягыннан да гаять киң: автор үз милләтенең дөньядагы һәм, гомумән, кешелек тарихындагы урынын билгели, башкалар белән чагыштыра, бүгенгесенә бәя бирә.

Романның сюжеты Кытайда – Шәркый Төркестанда туып үскән, хәзерге вакытта Америкада яшәүче, Татарстанга II Бөтендөнья татар Конгрессына вәкил буларак килгән Иркен Сәлах исемле 67 яшьлек ир-атка бәйле алып барыла. Әсәрнең башында ук Иркеннең шәхес буларак камиллегенә басым ясала. Ул тышкы кыяфәте, буе-сыны, пөхтәлеге, белеме һәм эчке-рухи дөньясы белән А. Хәлимнең милли шәхес сәнгати концепциясен гәүдәләндерә. Дөнья масштабында фикерләүче һәм бәяләүче ролендәге әлеге геройны татар ир-атының асыл сыйфатларын туплаган камил зат дияргә мөмкин. Иркен үз халкының тарихын яхшы белә, тел нечкәлекләрен аңлый, шигъриятнең кеше тормышындагы әһәмиятен югары бәяли, шул ук вакытта шәхес бәхетен халыкның матди яшәеше белән бәйләп, сәнәгать һәм икътисад мәсьәләләрен дә күтәрә.

Читтә туып үскән, төрле илләр күргән кеше буларак, төп геройга караш үзгәлеге, киңлеге (исеме дә шуңа ишарә) хас, бу исә авторга татар тормыш-мәгыйшәтен бүтән милләтләр, дәүләтләр белән чагыштыру мөмкинлеге бирә. Иркен, нәсел җепләрен барлау максатында, Чаллыда, Казанда, ата-бабасының туган җире – Мамадыш районы Кизләү авылында, Баулы төбәгендәге Шәмдәл авылларында була. Автор бик күп персонажларны аның белән очраштырып, татар яшәешенә бәйле проблемаларны берәм-берәм тезә. «Шәхес белән җәмгыять, кеше белән тарих, кеше белән кеше, кеше белән тирәлек, милләт белән милләтара мөнәсәбәтләргә кагылышлы проблемаларны тарих һәм көн сулышы белән сугарып яктырту авторның аеруча кыйммәтле ачышларын тәшкил итә» [Галитзуллина, 2015, б. 111]. Татарларның милли үзенчәлекләрен югалта баруы төрле мисалларда күрсәтелеп, моның сәбәпләре тарихи-сәяси, икътисади, психологик яктан аңлатыла.

Күтәрелгән проблемаларга бәйле эпопея берничә сюжет юнәлешендә алып барыла. Аның берсе Иркеннең Казан ханлыгы чорыннан килгән нәсел тарихына кагыла. Икенчесе – югарыда әйтелгәнчә, Татарстан халкының яшәү рәвешен, көнкүрешен төрле яклап ачу, өченчесе – Иркен белән Салют борадәре арасындагы криминаль вакыйга.

Геройның Сөләйман бабалары XIX йөз ахырында, көчләп чукындырудан качып, Кытай чигенә – борынгы уйгур далаларына барып урнаша. Әсәрдә бу вакыйгалар тәфсилле географик яссылыкта аңлатылып, рухи-психологик кичерешләр аша сурәтләнә. Элә елгасы үзәненә йорт салган Сөләйман хәзрәт янына Россиядән күчеп килгән башка гаиләләр дә җыела. Хезмәт сөю, тырышлык, гыйлемгә омтылу, ислами кануннар белән яшәү нәтиҗәсендә авыл тиз аякка баса һәм терлекчелек, игенчелек, сәнәгать өлкәсендә алга китә. Автор татарлар берләшеп яшәгән әлеге төбәкнең тиз үсеш алуын бернинди сәяси кысулар, көчләүләр булмау нәтиҗәсе, дип күрсәтә һәм идеаль җәмгыять моделе буларак тәкъдим итә.

Алтмышынчы еллар уртасында Кытайда «мәдәни инкыйлаб» исеме белән башланган хунвэйбинчылык хәрәкәте Сәлахиләрне дә читләтеп үтми, кытай, уйгур халыклары белән анда яшәүче татарларга да террор газаплары күрергә туры килә. Иркен гаиләсе белән Америкага күчеп китәргә мәҗбүр була. Шулай итеп, язучы төп герой образы һәм аның нәсел тарихы аша татар халкының дөнья тарихындагы урынын – геосәясәтен яктырта.

Роман үзәгендә татар милләте язмышы тора. Язучы үткәннәр аша бүгенгегә килә. Һәм анда «чит» образлар чагыштыру объекты буларак еш файдаланыла. Бу күп очракта аерым герой яки персонажның милләте аша түгел, ә, гомумән, теге яки бу милләт образы ярдәмендә башкарыла. Иркен кешенең милләтен «үзенчәлек» дип атый. «Әгәр расаларны, милләтләрне чагыштыра икән, ул моны нindидер милләтне кимсетү, аларның берсен икенчесеннән югары яки түбән кую өчен эшләми. Әгәр Аллаһы Тәгалә милләтләрне аеры яраткан икән, моның сәбәбе бар. Алар табигатьнең бик салкын һәм бик кайнар, уртача һәм түзәрлек булган параллельләрендә бар ителмешләр икән, димәк, яшәешнең төп мәгънәсе – үзенчәлек. Үзенчәлек – яшәү ысулы. Үзенчәлекнең алдынгысы һәм артта калганы булмый» [Хәлим, 1 т., б. 69].

Имагология, гадәттә, башка милләт турында формалашкан образларның стереотиплары белән эш итә. Һәркемгә мәгълүм, яһүдләр акыллы милләт буларак кабул ителгән. «Хунвэйбин» романында да яһүд образы «яши белүчеләр», «дөнья тотучылар» итеп күрсәтелә. Чаллы шәһәре белән танышуны Иркен зираттан башлый. Монда ул мөселман һәм христиан каберлекләреннән яһүдләрнеке түрдәрәк урнашуы, затлырак булуы белән аерылып торуын күрә. Тормышта гына түгел, хәтта зиратта да иң яхшы урын аларга, ди Лотфрахман. «Алар икенчел, күчермә, копия-талант, тик беренчел талантган яхшырак, акыллырак, өлгеррәк. Алар – оригинал түгел, оригиналны кабатлаучылар. Тик оригиналдан яхшыраклар. Көрәшүче түгел, көрәшкә

котыртучылар. Соңыннан көрәшчеләрне төрмәгә тыгып юк итүчеләр, шул көрәшнең җимешләрен ашаучылар. Алар – авыр штанга тимерен күтәрмәүчеләр, футбол тубын типмәүчеләр, авыр эш эшләмәүчеләр, әмма шуларның хезмәтен «фәнни» оештыручылар һәм хезмәт хакын түләүчеләр. Алар – һәркайда бөек өлгерүчеләр. Композитор түгел – музыкант, пианист һәм скрипач. Яһүди үзе актер булмас, булса, актердан көлүче пародист булыр... Яһүди үзе иснәүче, җырлаучы, йоклаучы булмас, бөек иснәтүче, җырлатучы, йоклатучы, кайгыртучы – менеджер булыр...» ди [Хәлим, 2011, б. 312].

Әрмән образы да әсәрдә тырыш бала – булачак түрә сыйфатында бирелә. Авторны иң борчыган мәсьәләләрнең берсе – тел, милли мәгариф. Иркен авыл мәктәпләрендә укучылар белән очрашуларда була. Туган телне укыту белән кызыксына. Балаларның үз телләрендә белем ала алмаулары зур фаҗига – милләтнең киләчәгенә балта чабу итеп күрсәтелә. Очрашуда әрмән малае Ашот «Туган тел» җырын җырлый. Укытучылары мәктәптә татар балаларының «татарча начар тартуын», ә әрмән укучыларының яхшы сөйләшүен, Ашот Шекоянның исә татарча иншаларны «биш»легә генә язуын әйтә. «Булачак нәчәлникләребез» диелә алар турында.

Халыкларның мәдәни тарихында язу иң әһәмиятле факторларның берсе булып тора. XX гасырның 20–30 нчы елларында татарларның берничә тапкыр имла алмаштыруы милли-мәдәни үсешкә зур тоткарлык ясый. Билгеле булганча, 90 нчы елларда кабат латинга күчү мөмкинлеге туа. Романда «безнекеләр»нең әлеге мәсьәләдә бердәм булмавы күренә. Чаллы Татар иҗтимагый үзәге утырышларына алфавит алмаштыру турында кызу бәхәсләр бара. Чыгыш ясаучылар алга киткән «чит»ләрдән үрнәк алырга чакыра. Яһүдләрнең дә, кытай һәм японнарның да гасырлар буена алфавит үзгәртмәүләре мисалга китерелә.

Әсәрдә ватан, шигырь, шагыйрь, ат образлары зур урын алып тора. Язучының алар турындагы фикерләре кабатлана-үстерелә килеп, «без»не «без» итүче, яшәтүче чыганаклар итеп күрсәтелә. Хунвэйбинлык исә, киресенчә, бетерүче көч – явызлык символы. Аның турында да фикерләр үстерелә килә. Башта «мәдәни революция» ясаучы кытай хунвэйбиннары турында сүз барса, алга таба автор кешегә карата кылынган һәр золымны, кешелексезлекне, вәхшилекне әлеге атама белән атый башлый. Иң ахырда Иркен «үз» туганы Салютны «хунвэйбин» дип атый. Туганнарын барларга кайткан Иркен туганнан туган абыйсының улын – Салютны Чаллыда таба. Тик Иркеннең өметләре акланмый. Салют Сәлахиләр нәселеннән килгән затлылыкны җуйган. Аның бабасы 30 нчы елларда Магнитогорск каласына сөрелә. Салют шунда туып үскән, Чечня сугышында булып кайтып, КАМАЗга эшкә килгән, аннан кыскартылып, бүгенге көндә эшсез, наркоманга чыгып, тормыш төбенә тәгәрәгән, кешелек сыйфатларын югалткан бәндә булып чыга. Ул Иркен агасының башына сугып, кесәсендәге долларларын урлый. Язучы аның шушы хәлгә

төшү сәбәпләре турында уйлана. Моны илдәге вазгыять, милли сәясәт белән бәйли. Салют – үз милләтен күралмаучы, үз теленнән, милләтеннән ваз кичкән зат. Автор кешене үз милләтеннән кимсенү-оялуга китерүне дөньяда иң зур явызлык – хунвэйбинлык итеп күрсәтә.

Тәнкыйтьтә әсәргә татар теленә ят яңгырашлы исем бирелү белән килешмәгән фикерләр дә булды [Сверигин, 2017, б. 169]. «Хунбэйбин»лыкны бер татарга гына хас күренеш булмыйча, дөнья масштабындагы явызлык булуын күрсәтергә теләүдән автор махсус шул исемне сайлаган, күрәсең. «Аның эчке халәте аерым шәхеснең шәхессезлек кризисын, аерым катламнарның, төркемнәрнең күптөрле кире, караңгы, җинаятьчел сыйфатларын үз эченә ала. Мөселман-татарларның динен алыштыру, чукындыру галәмәте шул ук хунвэйбинлык булган лабаса! Хунвэйбинлык – кешелеккә карата булган җинаятьнең дәүләт сәясәте дәрәҗәсенә күтәрелгән бер яңа формасы» [Мөлеков, 2011, б. 9].

Шулай итеп, язучының максаты – милли хисләренә кагылып, укучыны уяту, милләтнең матур якларын да, җитешсезлекләрен дә күрсәтеп кисәтү, алга киткән халыклардан үрнәк алып, йотылудан саклап калу. Дөнья масштабында барган глобализацияне вак детальләр аша төшендереп, аңа каршы торырлык рухи көч бирү.

**Әдәбият**

*Аминова В.Р.* Типы диалогических отношений между национальными литературами (на материале произведений русских писателей второй половины XIX в. и татарских прозаиков первой трети XX в.): автореф. дис. ... д-ра филол. наук. Казань, 2010. 51 с.

*Бойцов М. А.* Что такое потестарная имагология? // Власть и образ. Очерки потестарной имагологии / под ред. М.А. Бойцова и Ф.Б. Успенского. СПб., 2010. С. 5–37.

*Галитзуллина Л.* «Хунвэйбин» романы һәм милли тәрәккыят // Мәйдан. 2015. № 3. Б. 108–129.

*Мөлеков М.* Хунвэйбинчылар заманы яки татар милләтенең язмышы турында сагышлы уйлану // *Айдар Хәлим*. Хунвэйбин: 3 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 2011.

*Папилова Е. В.* Имагология как гуманитарная дисциплина // Rhema. Рема. 2011. № 4. URL: https://cyberleninka.ru/article/n/imagologiya-kak-gumanitarnaya-distsiplina (мөрәҗәгать көне: 16.05.2022).

*Сверигин Р.* Кыйблага кайту // Казан утлары. 2017. № 1. Б. 164–169.

*Хәлим А.* Хунвэйбин: роман-эпопея: 3 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 2011.

***Ганиева Айгөл Фирдинат кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әдәбият белеме бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 398

*Л.Х. Мөхәммәтҗанова*

# ТАТАРЛАРНЫҢ ТУЙ ЙОЛАСЫ КОМПЛЕКСЫНДА ҖЫРЛАР

Обрядовые песни – важная часть быта и праздников-пиршеств народа. В статье автор исследует песенное творчество татар, встречающиеся в составе комплекса свадебного обряда. Песенное творчество подобного ряда в исследовании показано с точки зрения их ритуального содержания, поэтической формы и обрядовой функции, определены роль и место обрядового фольклора в жизни народа. Статья затрагивает вопросы классификации и поэтики татарских народных песен свадебного обряда, тождественности их с жанрами других тюркских народов, представляет жанровый состав песен, обращает внимание на их современное состояние. Рассуждения автора аргументируются примерами из фонда татарских народных песен.

**Ключевые слова:** комплекс свадебного обряда, песенное творчество татар, песни-причитания «кыз елату», «яр-яр», стенания невесты, поэзия обрядового фольклора.

Ritual songs are an important part of everyday life and feasts of the people. In the article, the author explores the song creativity of the Tatars, which are found as part of the wedding ceremony complex. Song creativity of such a series is shown in the study from the point of view of their ritual content, poetic form and ritual function, the role and place of ritual folklore in the life of the people are determined. The article touches upon the issues of classification and poetics of Tatar folk songs of the wedding ceremony, presents their genre composition, draws attention to their current state. The author’s reasoning is supported by examples from the fund of Tatar folk songs.

**Keywords:** wedding ceremony complex, song creativity of Tatars, songs-lamentations «kyz elatu», «yar-yar», groans of the bride, poetry of ritual folklore.

Туй – төрки халыкларда уртак сүз. Асыл мәгънәсе белән күп халык җыйналып, мул табында сыйлануны, күңел ачу мәҗлесен аңлата. «Туй – җыен, сый да уен» дигән әйтем дә бар. Шуның белән бергә туй – көнкүрештә башкарыла торган йола да. Аның борынгы ышанулар катнашкан магик сыйфатлары, кыз бирү-килен төшерүгә бәйле керем-чыгымы, мәһәр-калымы һәм тарихи хокук белән бәйле башка үз кануннары бар. Туй – этнография белән халык иҗатын, йола поэзиясен үз эченә алган катлаулы күренеш, тулы бер комплекс.

Фәндә татар халкының туй йоласын бер-берсенә тыгыз бәйләнгән өч өлешкә бүлеп йөртәләр: 1) яучылау, килешү, билге алышу (ике якның вәгъдәләшүе), ярәшү кебек йола-гадәтләрне үз эченә алган туй алды йолалары; 2) туй мәҗлесенә, кыз һәм егет ягында туй үткәрүгә бәйле гореф-гадәтләр тәртибе; 3) килен төшерү, шәл салдыру, кода

төшерү, кияү кайтармасы (кайтарма аш) һ. б.дан гыйбарәт туй арты йолалары.

Татарлар – сибелеп яшәүче халык. Урынына-ягына, авылына-тирәлегенә карап, туйлар төрле җирдә төрлечә үткән. Казан тирәсендә яшәүче татарларның туйлары белән, әйтик, Башкортстан, Мордовия республикалары, Төмән, Түбән Новгород өлкәсе татарларының туйлары яисә ислам дине, шәригать кануннары катнашкан туйлар белән керәшен татарларының туйлары арасында күп кенә аерымлыклар, үзгәлекләр табарга була. Бу – тарих һәм көнкүреш, җирле шартлар һәм тирә-юньдәге элемтә-йогынтылар белән бәйләнгән табигый хәл. Шул ук вакытта туй йоласында татар халкының барлык этник төркемнәренә дә хас булган уртак, гомуми гадәтләр, бер үк эчтәлектәге сүз сәнгатенең татарлар яшәгән һәр урында эзлекле кабатлануы һәм бу күренешнең дәвамчанлыгы игътибарны җәлеп итә. Тарихның түренәрәк киткән саен йоланың традицион бердәмлек сыйфатлары күбрәк ачыла, шул ук вакытта, тулаем алганда, безнең гасырда да әлеге бердәйлеккә килеп чыгабыз.

Жанр төрләре күзлегеннән караганда, туй поэзиясе шактый катлаулы. Лирик, драматик төсмерле «Кыз елату» җырлары белән бергә, бу поэзия хәзинәсендә туйда яучылар тарафыннан әйтелә торган кинаяле такмазалар да, теләк әйтүгә юнәлгән арбаулар да, мактау җырлары да, чәнечкеле шаян такмаклар да очрый. Аларның һәркайсының үзенә генә хас стилистик формасы бар, башкару алымнары да төрле. Ялгыз җырлауга исәпләнгән лирикадан тыш, диалогка корылган яки күмәк җырлана торган әсәрләр күп очрый. Туйның эчке логикасына буйсынып, аларның я берсе, я икенчесе башкарыла. Туй поэзиясенә кергән әсәрләр чыбылдык астында, аулакта яисә мәҗлес вакытында гына түгел, йола таләбе кушканча, капка төбендә, ак келәт янында, тәрәзә һәм бусага алдында яисә кыз катына үтә торган ишекнең төбендә дә җырланган.

Туй алды йоласы гадәттә яучылау белән башлана. Яучы белән сөйләшенгәннең яисә, соңгырак чор гадәте белән, кыз сорарга барып, килешенеп кайтканның соңында, алдан билгеләнгән көнне, китәчәк кызны иптәшләре-тиңдәшләре озатырга килә. Кызның чәченә тәңкәләр үреләә, башына яулык яптырыла, өстенә ак бөркәнчек каплана. Шул чагында махсус җырлар – «Кыз елату» җырлары башкарыла. Алар кияүгә бирелгән кыз һәм аның дус-ишләре, ә кайбер очракларда йоланы әйбәт белүче берәр карчык тарафыннан җырланган. Җырларның төп эчтәлеге кызның туган йорты, әти-әнисе, туганнары, яшьлеге һәм кыз чагы белән саубуллашуга, ире йортында аны көтә дип уйланылган авырлыклардан хәсрәтләнүгә кайтып кала.

Бу йоланың XVIII гасырга караган тасвирламалары бар [Георги; Милькович]. Дөрес, аларда җыр үрнәкләре бирелмәгән. Тулырак мәгълүматлар һәм җыр текстларының басылып чыгуы XX гасыр башына карый [Акчурина; Рәхим Г.]. Шул ук гасырның икенче яртысында басылган чыганакларда [Бурганова; Мөхәммәтҗанов] әлеге

йола вакытында башкарылган җырларның текстлары китерелү белән бергә йоланың җирле-локаль үзенчәлекләренә дә игътибар ителә башлый. XX гасыр азагында дөнья күргән академик 13 томлыкның «Йола һәм уен җырлары» томында «Туй йоласына караган җырлар» бүлегендә әлеге төр иҗат кыз елату җырлары, сыктаулар, «яр-яр» җырлары, «ишек бавы», туй мәҗлесе җырлары, бирнә сорау җырлары, килен төшерү җырлары, туйда кунакларның бер-берсен макташу һәм хурлашу характерындагы җырлар кебек исемнәр белән аерым төркемләнеп, һәр төркемгә этрафлы аңлатмалар белән басылып чыкты [Татар халык иҗаты, 1980]. Әлеге төр иҗат XXI гасыр башында да актуальлеген югалтмый, фәнни экспедиция нәтиҗәләрен чагылдырган төрле җыентыкларда [Кадыйров] «Кыз елату» җырлары шулай ук киң чагылыш таба. Аеруча «Татар халык иҗаты»ның яңа академик 25 томлыгында йола җырларына, шул исәптән кыз елатуга бәйле иҗатка зур урын бирелгән, томда җыр текстлары һәм аларга кыскача бәяләмә, тулы аңлатмалар табарга мөмкин [Татар халык иҗаты. 25 томда. 2 т.: Йола фольклоры, б. 215–285].

Йола җырларының өйрәнелү тарихын күп катламнардан торган йола фольклорыннан аерып карап булмый. Йола поэзиясенең, тагын да гомумирәк итеп алганда, йола фольклорының аерылгысыз атрибуты буларак, йола җырлары турында беренче мәгълүматлар К. Насыйри хезмәтләрендә урын алган булса, соңгырак чорда мәсьәләнең күп кенә яклары Н. Исәнбәт, И. Надиров, М. Нигъмәтҗанов, Р. Мөхәммәтҗанов, М. Мәһдиев, М. Бакиров, Д. Рамазанова, Ф. Баязитова, Ф. Урманчеев, К. Миңнуллин тикшеренүләрендә яктыртылды. Галимнәрнең игътибар үзәгендә йолаларның күбрәк поэзиягә караган өлеше, сүз белән бәйле фольклор тора.

Кыз елату йоласы төрки халыкларның күбесендә очрый. Казакъ, кыргыз, үзбәк, башкорт фольклорында да бу йоланың махсус җырлары бар. Татарлар яшәгән җирләрдә йола төрлечә аталган:«Кыз чеңләтү», «Чеңләү», «Таң кучат», «Сыктау», «Яслату», «Әтеки әйттерү», «Әҗәл итеп җырлау» һ.б. Әмма исемнәрдәге төрлелек ритуалның җисемен үзгәртми. Кызның ата-ана йортыннан елап аерылуы әлеге йолада үзенә күрә мәҗбүри бер шарт булып тора. Хәтта ярәшкән кешесенә үз теләге белән яратып чыкса да, кыз «еларга» тиеш булган. Бу хәл кыз елатуга ата-бабадан килгән изге йола итеп караудан килә булса кирәк. Шундый мәкаль-нәсыйхәтләр дә бар: борынгылар «Елап барсаң, гомерең көлеп узар, көлеп барсаң, гомерең елап узар», «Үз атаң йортында елап бетермәсәң, биатаң йортында күз яше түгәрсең», «Елап барсаң, елмаеп яшәрсең» дигәннәр.

Кыз елату йоласы мишәрләр яшәгән төбәкләрдә, керәшен һәм себер татарлары арасында аеруча нык таралган була. Борынгырак заманнарда бу йола казан татарларында да булган. Кызның туган өеннән, әти-әнисе яныннан елап китү, елап аерылу гадәте хәзерге көннәрдә дә очрый. Ләкин елап җырлау гадәте бу тирәләрдә акрынлап юкка чыккан. Моның сәбәбен XX башында ук Г. Рәхим казан

татарларына ислам дине тәэсире белән аңлата [Рәхим Г., б. 28]. Чыннан да, туй йоласындагы күп кенә элементлар белән бергә, татарларның туй поэзиясендәге кыз елату җырларын шәригатьчә никах гадәтләре алыштырган. Шул ук вакытта безнең көннәрдә дә кыз елату җырларын һәм бу йоланың тәртибен белүчеләр әле бар.

Кыз елату йоласының безнең көннәргә килеп җиткән мисалын Чиләбе өлкәсе Нязепетровск районына карый торган татар авылларында очратып, язып алырга насыйп булды. Нязепетровск шәһәрендә Рәхмәтуллина Гөлнур Хәмидулла кызыннан (1953 елгы, тумышы белән Арыслан авылыннан), Нязепетровск районы Арыслан авылында Мөхәррәмова Роза Низам кызыннан (1961 елгы) берничә бөрәмлектә язып алынган бу җырларны информантлар үзләре «Чеңләү җырлары» дигән исем белән атый. Фольклорчы И. Ямалтдинов Арыслан авылында Р. Мөхәррәмовадан түбәндәгеләрне язып алган: *«Бу чеңләү. Безнең авылныкы. Әйе, гомер буе авылда чеңләгәннәр, җылатканнар...»* [Ямалтдинов, Чиләбе өлкәсе татарлары..., б. 165–167]. *«Кияүгә киткәндә кызны елаталар. Ата-анасын онытмасын, бәхетле яшәсен, дип. Кыз өстенә чаршау коралар. Чаршауны кызның җиңгәләре, туган тиешле кешеләре тотып тора. Кызны шунда кертеп бастыралар. Шуннан чеңләтәләр. Чеңләүчеләр – шул ябынгычны тотып торучылар инде, бу йоланы белгән апалар, кыз ягы туганнары. Кайвакыт кызның әтисен дә шунда кертәләр»,* – дип сөйли информант Г. Хәмидуллина [Мөхәммәтҗанова, Чиләбе татарларында..., б. 316, 318]. Р. Мөхәррәмовадан язып алынган текст түбәндәгедән гыйбарәт:

*Ак чүпрәккә төргәнсең дә, акыт[1] кына идең, атакаем,*  
*Артык кына итеп сатып бирдең, артык идеме балакаең?*  
*Әтекәемнең өендә утырганым бары бер такта,*  
*Бер такталарың кызганып, сатып бирдең, әти, чит-ятка.*  
*Чылтыр-чылтыр чын чынаяк, чылтыратмый ничек юаем,*  
*Усал кайнәләргә бирдең, ничек кенә итеп түзәем?*

Кыз елату җырларының эчтәлегенә һәм эмоциональ яңгырашына тирән трагизм хас. «Кияүгә чыгуны, туган йортыннан аерылып китүне, – дип яза Ф. Урманчеев, – яшь кыз коточкыч фаҗига дип кабул итә һәм үлем белән бер рәткә куя» [Урманче, б. 71]. Чыннан да, төрки халыклардагы кыз елату җырларының тамыры теге һәм бу дөнья хакындагы бик борынгы мифологик күзаллауларга барып тоташу ихтималы зур. Кыз елату җырларының иң зур күпчелеге кайгы-хәсрәт, күз яше белән сугарылган. *«Әрнеп кенә, сызлап елыймын», «Бикләдегез тимер йозакка», «Ничек ят өйләрдә торырмын»* – бу һ.б. җырларның исемнәрендә үк тирән сагыш, билгесезлектән курку, кире кайтарып алып булмаслыклык югалту хисе, кияүгә китүне зур бер афәт белән тиңләштерү бар. Бу җырларның эчтәлегеннән шулар аңлашыла: кияү йортына кузгаласы кыз тоташ киеренкелектә, аның үз өеннән чит-ят

---

[1] Акыт – акыл, акыллы, зирәк.

урынга һич күчәсе килми, яңа урыныннан ул бернинди яхшылык көтми, булачак иренең йортында үзенә карата һичшиксез булачак дип уйланыла торган кагу-сугуларны күзаллап, әрнеп елый, үзен чарасыз бәхетсез саный, атасы йорты белән мәңгелеккә хушлашкандай ихлас хушлаша. Шул рәвешле, җырда кызның «үз дөньясы» «чит дөнья»га каршы куела:

*Атның аягында дагалар,*
*Дагаларны нигә тагалар?*
*Ят өйләргә төшкәч, шунысы яман,*
*Атна да гына узмый кагалар.*
*Чыбылдыгым гына чуп-чуар,*
*Чебен генә кунса, кем куар?*
*Ят өйләргә төшкәч, эчем пошар,*
*Минем өчен генә кем елар?*
*Үзем тукыган чуар чаршауны*
*Ничек ят өйләрдә корырмын?*
*Әни кәбәм, бирче бер акыл,*
*Ничек ят өйләрдә торырмын?*
*Карамалар үсә каршыда,*
*Көн дә шунда куна карчыга;*
*Еракларга мине биргәнче,*
*Бирегез үзебезнең ялчыга.*
*Юлга чыктым кояш баешка,*
*Юллары ла төште камышка;*
*Ни лә хәлләр итеп түзәрсең,*
*Төшсәң аждаһадай каенишкә?*
*Йомгак белән генә җеп кенәм*
*Өлгерә алмадым җыярга;*
*Өйдә күргән ардак[1]-хөрмәтне*
*Кала инде сагынып еларга.*
*Биек кенә тауның башында*
*Яңгыр микән, әллә кар микән?*
*Әрнеп кенә, сызлап елыймын,–*
*Миннән язулырак[2] бар микән?*

[Татар халык иҗаты, 1980, б. 74]

Кыз елату йоласы нигезендә борынгы ышанулар төсмерләнә. Кызның елап китүе аның язмышы юлында торган сынауларны җиңү, усал рухларны йомшарту өчен кирәк дип саналган. Кыз елату үзенә күрә бер инициация үтәүне дә хәтерләтә. Шуның белән бергә, елап аерылуның реаль социаль җирлек белән бәйле сәбәпләре дә аз булмаган. Әйтик, кыз яратмаган, үзе теләмәгән кешегә кияүгә бирелеп, бөтенләй чит-ят зур гаиләгә килеп, көне-төне эшләргә, кимсетелеп-кагылып яшәргә мәҗбүр ителгән булуны да инкяр итә алмыйбыз. Тиң

[1] Ардак– кадер.
[2] Язулырак – бәхетсезрәк.

түгелгә, яисә көндәш өстенә көчләп бирелү күренешләре дә кызның елап китүен тәэмин иткән булырга мөмкин. Болар бәхетсез килен турындагы бәет һәм мәкальләрдә ачык чагылган. Шуңа күрә елату җырларында кызның яшьлеге үткән ата-ана йорты якты буяуларда сурәтләнеп, кыз килен булып төшәчәк каената йорты караңгы төсләрдә бирелә:

*Әтиемнең мин өендә, урыным иде түрендә;*
*Ят кешеләрнең өендә булырмын ишек төбендә.*
[Татар халык иҗаты, 1980, б. 92]

Елату җырларында кияү булачак кеше турында хәбәр шактый саран, әмма каената, каенана, кагыйдә буларак, усал, рәхимсез итеп сурәтләнә. Алар ягы – «ят як», анда кызны «ят куллар», «кара төннәр» көтә, бу рәхимсез йортта килен ятка һич ярый алмаячак, аның урыны шиксез ишек төбендә булачак һ.б. Шуңа күрә кыз үзен, ирегеннән аерып, кияүгә биргән өчен ата-анасына, абый-җиңгәсенә үпкәачу белдерә, ачынып сыктый, «мал урынына саттыгыз» дип рәнҗи. Сатып бирү мотивы кыз елату җырларында гомумән күп очрый, кызның кайгысын тагын да олырак итеп күрсәтүгә хезмәт итә.

Кызның зары, нигездә, ата-анага юнәлтелгән, ул гаилә тирәлегеннән ерак китми, кыз *«Рәнҗүем күп, әтекәм, сиңа, сөймәгән кешегә бәйләдең», «Сөймәс балакаем китте диеп, калырсыңмы, әнкәй, тынычта?», «Ят җирләрдән яучы килгән чакта балам яшь дип нигә әйтмәдең?», «Акрын гына басып, пыш-пыш сөйләп, җиттегез лә минем башыма»* кебек сүзләр әйтеп елый, үзен ят кулына биргәннәре өчен әрнеп, ата-анасына мөрәҗәгать итә.

Кыз елату җырларында импровизация белән традицион поэтика тыгыз үрелгән. Структур яктан бу үрелештә традиционлык катламы шактый көчле, ә индивидуаль иҗат катламы сизелер-сизелмәс бизәкләр рәвешендә генә гәүдәләнә. Традицион поэтикада уртак образлар – сагыш, үпкә, кайгы, өмет тойгыларын сурәтли торган калыплар үзәк урынны алып тора. Икенче яктан, йоланың үз кануннары белән чикләнгән эчке ситуациясе, һәр кызның кияүгә китү очрагы гаять индивидуаль булу җырларда импровизациянең дә зур урын алуына китерә.

Кыз елату җырларының төп шигъри формасын дүрт юллы строфа тәшкил итә. Арада биш-алты юллы строфалар да очрарга мөмкин, әмма алар гадәттә кабатлау-кушымталар хисабына үстерелгән була. Ритмик-интонацион яктан борынгы дастан строфаларын хәтерләтүче җырлар да бар. Аларда бер-берсенә мәгънәви һәм шигъри бәйләнгән тезмәләр саны үстерелә барып, чылбырлы озын строфа барлыкка килә. Мәсәлән, «Әни, мине ник таптың» дип аталган җыр моңа мисал була ала:

*Әни, мине ник таптың?*
*Әти, мине ник саттың?*
*Әти, мине ник саттың, –*
*Янчык тулы мал өчен?*

*Янчык тулы мал белән*
*Чыршы ызба салырсың,*
*Чыршы ызбаң эченә*
*Чыршы өстәлең куярсың,*
*Чыршы өстәлең өстенә*
*Ак самовар куярсың,*
*Кызың искә төшкәчтен,*
*Чәеңне эчми туярсың.*

[Татар халык иҗаты, 1980, б. 71–72]

Җиде иҗекле мондый шигырь төзелеше кыз елату җырлары арасында «Ризкым кала, әнкәем», «Ах, тиңдәшләр, тиңдәшләр» кебек җырларда очрый. И. Надиров кыз елату җырларының мондый төзелешләләренә карата: «Алар бу йоланың иң борынгы шигъри үрнәкләре булырга мөмкин. Бу форма җырлап түгел, ә көйләп әйтелә торган шигырь буларак күз алдына килә», – дигән фикер белдерә [Татар халык иҗаты, 1980, б. 14].

«Җырларда халык тарафыннан да, шагыйрьләр тарафыннан да уңышлы файдаланылган поэтик алымнарның берсе – лирик эндәшләр», – дип искәртә филология фәннәре докторы, халык җырлары белгече К.М. Миңнуллин [Миңнуллин, б. 259]. Елату җырларының жанр табигатендә дә әлеге хаклы күзәтү чагылыш таба. Кыз елату җырларына риторик сорау, эндәшеп мөрәҗәгать итү кебек стилистик чаралар хас. Бу алым, җырның композициясен оештыру чарасы буларак, кыз елату җырларында бик күп кабатлана. Кыз үзенең моң-зарын, хәсрәтен әйтеп сыктаганда ата-анасына, туганнарына мөрәҗәгать итә, алар белән бәхилләшә, шунда ук үпкәсен дә белдерә, алардан киңәш тә сорый, үтенечләрен әйтә. Җыр поэзиясендәге бу алым елату җырларын җанлы сөйләм интонацияләре җәһәтеннән һәм эмоциональ яктан баета, лиризмны көчәйтә. Чынбарлык белән йола арасындагы күпкырлы мөнәсәбәтләрдән туган елау-сыктау поэзиясендә кияүгә баручы кыз баланың лирик кичерешләре гаять нечкә сурәтләнгән.

Кыз елату җырларының үзенчәлекле бер төркемен «Яр-яр» җырлары тәшкил итүе мәгълүм. Кайчандыр мәдрәсә шәкертләре арасында «Яр-яр» стиленә таянып язылган мәхәббәт шигырьләре дә таралган була. Тарихи-генетик яктан «Яр-яр» әйтү гадәтен белгечләр күп кенә төрки халыкларның туй йоласына хас уртак гадәт дип саный. Бер төркем «Яр-яр» җырлары борынгы «Бүз егет» дастанында да чагылыш тапкан. Үзбәкләрдә һәм төрекмәннәрдә аны «Яр-яр», казакъларда «Жар-жар», нугайларда «Хей-жар», каракалпакларда «Хау-жар» дип йөртәләр. Татарларда сакланып калган «Яр-яр» җырлары, нигездә, гаилә коруга һәм мәхәббәткә багышланган, аларда «яр-яр» сүзләре гаилә коручы яшьләрне бер-берләрен яратып яшәргә, гомергә бергә булырга өнди торган тирән мәгънәле шигъри рефрен буларак кабатланып килә. Туй йоласы комплексындагы кыз елату җырларыннан бераз

аермалы буларак, «Яр-яр»ларда моң-зар мотивы үзәк мотив дип әйтеп булмый, әмма бу төр җырларда да кыз тарафыннан елап-сыктап әйтелгән юлларда үзояңнан ят җиргә күченү хәсрәтеннән туган сагыш тоемлана:

*Дүрт почмаклы өемдә урыным калды, яр-яр,*
*Кара чәчем толымын сүтәм инде, яр-яр;*
*Дүрт колаклы казанда өлешем калды, яр-яр,*
*Сынамаган ят җиргә китәм инде, яр-яр.*
[Татар халык иҗаты, 1980, б. 108]

Туй йоласы комплексындагы «Яр-яр» җырларында яшь парга карата котлау сүзләре, мактаулар, кияүгә бирелә торган кызның күңелен күтәрердәй теләк-киңәшләр әйтелә, җырларда тантаналылык хисе өстенлек ала:

*Берең егет, берең туташ, кушылдыгыз, яр-яр!*
*Берегез ефәк, берегез ука, ишелдегез, яр-яр!*
*Берең кияү, берең килен, берләштегез, яр-яр!*
*Берең былбыл, берең ал гөл, гөрләштегез, яр-яр!*
[Татар халык иҗаты, 1980, б. 111–112]

«Яр-яр»ның үзенә генә хас башкару үзенчәлекләре бар. Себер татарлары арасында кызлар белән яшь киленнәрне чәч толымнарына карап аера торган булганнар. Кызлар толымнарын бердән, ә киленнәр икегә аерып үргәннәр. Беренче мәртәбә кызның толымын икегә аерып үрү йоласы туй алдыннан зур чыбылдык эчендә үтәлгән. Бу изге ритуалны кызның җиңгәләре һәм ахирәт дуслары башкарган. «Яр-яр» җырларын нәкъ менә шул чакта көйләгәннәр. Күмәк җыр әйтешүдә кыз, аның әнисе, җиңгәләре, дуслары, кияү егетләре һәм кайнишләр катнашкан [Татар халык иҗаты, 1980, б. 15]. Кайбер төбәктә, мәсәлән, Төмән өлкәсе Тубыл районында «Яр-яр» җырлары «Үләң таш» дигән исем белән дә мәгълүм [Кадыйров, б. 64–65, 65–66]. «Үләң таш» атамасы «үләндәш» сүзе белән аваздаш, үләң – сюжетлы эпик җыр, дигәнне аңлата. Кайбер төрки халыкларда, шул исәптән татарларда да, туй үләңнәре – мәгълүм жанр төре.

«Ишек бавы» җырлары исеме белән атап йөртелә торган иҗат туй йоласы җырлары комплексында шулай ук игътибарга лаек төркем. Алар татарларда яучылау, елату, «Яр-яр» әйтүләрдән соң үтәлә торган гадәткә бәйле җырлана торган булган. Мондый җырларның эчтәлеге кәләш янына керәсе кияүне ишек төбендә туктатып, аңардан көмеш акча сорауга бәйле. Кәләшнең бәясен күтәреп, шаян рухта сатулашу җыр аша барган.

Моннан тыш «Илаһи матур хан кызы», «Аччы, туташ, ишегеңне», «Илаһи мәгъшукнамә», «Хан кызы, ач ишегеңне» кебек әсәрләр фольклорда «Хан кызы» җырлары исеме белән мәгълүм. Бер очракта мөнәҗәт дип, икенче очракта йола җыры яисә уен җыры дип карала торган бу әсәрләр жанр табигате ягыннан шактый катлаулы. Аны

халык поэзиясенең төрле жанрларына якынайта торган поэтик һәм функциональ билгеләр аз түгел. Кара-каршы әйтешеп җырлануга корылган әлеге төркем яшәеш-таралыш формалары һәм шигъри эчтәлеге ягыннан лирик җырларга якын тора. Әмма бу төр җырлар татарларның туй йоласы комплексында башкарыла, нәкъ менә билгеле бер йола үтәүгә, ягъни кияү каршылау, кияүне кыз янына кертүгә бәйле башкарыла. Шуңа да «Хан кызы» җырлары «Йола фольклоры җырлары» буларак каралырга хаклы. «Хан кызы» татарлар яшәгән барлык төбәкләрдә дә киң таралган булган. Аның халыктан язып алынган, я булмаса төрле кульязма чыганакларда саклана торган дистәләгән вариантлары мәгълүм.

Туй йоласы поэзиясенең тагын бер зур төркеме – туй мәҗлесе җырлары. Кыз ягында да, кияү ягында да туй мәҗлесенә кодалар, туган-тумачалар, дус-ишләр җыела. Татарлар яшәгән теләсә кайсы төбәктә андый мәҗлесләр җыр-бию, уеннар белән үткән. Казан татарлары һәм мишәр татарлары туйларында, гадәт буларак, туганлык-кардәшлекне ныгытуга багышланган җырлар, гомум репертуардагы традицион мәҗлес һәм лирик җырлар төп урынны алып торган булса, керәшен татарларында хәлнең бераз башкачарак булуы мәгълүм. Керәшен туйларында туй барышы белән тыгыз бәйләнгән махсус җырлар әүвәл дә, хәзер дә башкарыла, ә җырлашып утыру туйның күркәм бер гадәте булып санала. Бу төр җырлар халыкта киң таралган, алар үзләре аерым төркем тәшкил итә, шуңа күрә халыкның туй йоласы комплексында мәҗлес барышында башкарыла торган ашау-эчүгә бәйле җырларны «Аш-су табыны җырлары» дип атау һәм аларга аерым хезмәттә махсус тукталу дөрес булыр.

Мәгълүм булганча, килен төшерүдә төп рольне кияү егетләре уйнаган. Алар, йола кануннары буенча, урамда, капка төбендә яисә ак келәт янында килен белән кияүгә багышлап күмәк җырлар башкарган, яшь парларга мәхәббәт һәм тигез гомер теләгәннәр. Моннан тыш, кияү йортына килгән яшь киленгә такмазалап арбаулар, ягъни теләкләр әйтелгән. Арбауларның махсус шигъри формасы мәгълүм. «Арбау әйтү» – гаилә коруга, аның нигезен ныклы итүгә багышланган күркәм бер гадәт. «Арбау»ны килен төшкән көнне махсус башкаручы – өлкән яшьтәге хатын-кыздан әйттергәннәр, каенананың да арбау әйтү очраклары булган:

*Казаның өреле булсын,*
*Китмәскә килерең булсын;*
*Чүмергәнең бал булсын,*
*Ашаганың май булсын,*
*Гаиләң ишле, бай булсын,*
*Абзарың тулы мал булсын;*
*Күңелең кинә тотмасын,*
*Авызың серкә йотмасын,*
*Сыер-танаң мөңтердәп,*
*Кош-кортларың кыткылдап,*

*Күз ачтырсын, киленем,*
*Көн ачтырсын, киленем.*

[Татар халык иҗаты, 1980, б. 159]

Татарларда кияүгә атап әйтелгән «арбау»лар да булган. Аның эчтәлеге асылда шул ук, ул кияүгә яраклаштырып әйтелгән теләкләрдән тора. Арбау әйтү гадәте ерак чорлардан килә. Килен кияү йортына аяк атлап керер алдыннан аны арбау такмазалары белән каршылап, йомшак мендәргә бастыру, авызына бал каптыру гадәте әле бүгенге көндә дә яши:

*«Кызны алып кайткач, берәү өйгә алдан кереп, әйтә:*

*– Парлап кайттык! – ди. Шуннан соң өйдә көтеп торучылар булачак киленне каршы алырга чыга, кайтучыларны өйгә чакыралар. Кыз кергәндә тупсаның эч ягына мендәр куялар. Егет өенә атлап кергән кыз ике аягы белән дә мендәргә баса. Моңа булачак каенана әйтә:*

*– Төкле аягың белән! Исән-имин яшәргә язсын! Йомшак басып йөрер өчен дип салдым мендәрне.*

*Бал белән май каптыра кызга:*

*– Балдай тәмле телле бул! Майдай эре! – ди»* [Мөхәммәтҗанова, Тән азыгы..., б. 198–199].

Килен каршылаганда арбау әйтү гадәте төрки халыкларның күбесенә мәгълүм. Казакъларда, каракалпакларда аны «биташар» (бит ачу) дип йөртәләр. Киленгә нәсыйхәт рәвешендә аларда көйсез такмазалар түгел, озын-озын җырлар әйтелә [Татар халык иҗаты, 1980, б. 18].

Татар халкының туй йоласы комплексына караган җырлар йола һәм аның гамәли функцияләреннән аерылгысыз бер хәлдә яшәмәүләре белән үзенчәлекле. Вакыт узу белән бу төр сәнгатьнең йолага бәйлелеге юкка чыга барса да, әлеге төркем әсәрләренең туй йоласы белән бәйлелеген таныта торган билгеләр югалып беткән дия алмыйбыз. Шул ук вакытта халыкның йола поэзиясе үрнәкләрен бүгенге көндә дә очратырга мөмкин. Традицион туй йоласы җырлары халыкның шигърият байлыгын үзенә туплаган мул һәм үзенчәлекле чыганак булуы белән әһәмиятле. Туй йоласы вакытында башкарылган җырлар халыкның рухи мәдәниятен, иҗтимагый һәм гаилә мөнәсәбәтләрен өйрәнү җәһәтеннән дә мөһим урын алып тора. Көнкүреш йоласының эмоциональ яңгырашын баету, хиссилеген көчәйтүгә хезмәт итә һ.б. функцияләрен әле дә югалтып бетермәгән иҗатның татарлар яши торган төбәкләрдә бүген дә табылып торуы, алай гына да түгел, шактый актив иҗат буларак яшәве – аеруча кызыклы күренеш.

**Әдәбият**

*Акчурина М.* Кыз елату // Шура, 1911. 20 нче сан.

*Бурганова Н.Б.* Свадебные причитания невесты у крещенных татар Подберезинского района. // Известия Казанского филиала АН СССР, вып. 2, 1957.

*Георги И.Г.* Описание всех обитающих в Российском государстве народов. СПБ, 1799. В 4-х частях. Ч. 2: О народах татарского племени и других не решенного еще происхождения Северных Сибирских. 1799. 178 с.

*Кадыйров И.Ш.* Татар халкының туй җырлары: Себер ареалы. Казан: ТӘһСИ, 2021. 188 б.

*Мөхәммәтҗанова Л.Х.* Тән азыгы – икмәк, җан азыгы – хикмәт // Милли-мәдәни мирасыбыз: Мамадыш. Казан: ТӘһСИ, 2017. Б. 189–240.

*Милькович К.* Быт и верования татар Синбирской губернии в 1783 году: (Из зап. уезд. землемера Мильковича). Казань: Типо-лит. ун-та, ценз. 1905. 14 с.

*Миңнуллин К. М.* Һәр чорның үз җыры. Казан: Мәгариф, 2003. 400 б.

*Мөхәммәтҗанов Р.* Башкортстан Ык буе татарларының йола иҗаты (туй поэзиясе). Уфа, 1977. 70 б.

*Мөхәммәтҗанова Л.Х.* Чиләбе татарларында сүз сәнгате // Милли-мәдәни мирасыбыз: Чиләбе өлкәсе татарлары. Казан: ТӘһСИ, 2017. Б. 309–371.

*Рәхим Г.* Халык әдәбиятымызга бер караш: җырлар. Казан: Гасыр, 1919. 80 б.

Татар халык иҗаты. 25 томда. 2 т.: Йола фольклоры. Төз., иск. һәм аңл. әзерл., кереш сүз авт. Л.Х. Дәүләтшина. Казан: Татар. кит. нәшр., 2022. 541 б.

Татар халык иҗаты. Йола һәм уен җырлары / томны төз., кереш мәкалә язучы, искәрмәләр әзерл. И.Н. Надиров. Казан: Татар. кит. нәшр., 1980. 320 б.

*Урманчеев Ф.* Татар халык иҗаты. Казан: Мәгариф, 2002. Б. 71.

*Ямалтдинов И.И.* Чиләбе өлкәсе татарлары фольклоры (Халык иҗаты үрнәкләре) // Милли-мәдәни мирасыбыз: Чиләбе өлкәсе татарлары. Казан: ТӘһСИ, 2017. Б. 145–224.

***Мөхәммәтҗанова Лилия Хатип кызы,***
*филология фәннәре докторы, доцент, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге баш фәнни хезмәткәре*

УДК 398.22

***Г.Р. Хөсәенова***

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИЛЛИ КИТАПХАНӘСЕНДӘ САКЛАНА ТОРГАН ДАСТАННАРГА ГОМУМИ КҮЗӘТҮ

В данной статье проводится общий обзор татарских дастанов, хранящихся в Отделе рукописей и редких книг Национальной библиотеки Республики Татарстан. Цель статьи – выявить хранящиеся в отделе дастаны, обратить внимание на степень сохранности, место обнаружения рукописных памятников, дать им краткую характеристику, определить идейно-тематическую направленность и подвести общие выводы из наблюдений.

С 2008 года в Национальной библиотеке Республики Татарстан издается серия книг «Татарская археография». В этом списке достойное место заняли и татарские дастаны. Автор выделяет среди них важное место произведению «Дастане джайа», отличающемуся своей древностью и названием.

**Ключевые слова:** татары, дастан, эпос, рукопись, памятник, мотив, фольклор, литература.

This article provides a general overview of the Tatar dastans stored in the department of manuscripts and rare books of the National Library of the Republic of Tatarstan. The purpose of the article is to identify the dastans stored in the department, pay attention to the degree of preservation, the location of discovery of handwritten monuments, give them a brief description, determine the ideological and thematic focus and draw general conclusions from observations.

Since 2008 the National Library of the Republic of Tatarstan has published a series of books «Tatar Archeography». Tatar dastans also took a worthy place in this list. The author allocates an important place among them to the work «Dastane Jaya», distinguished by its antiquity and name.

**Keywords:** Tatars, dastan, epic, manuscript, monument, motif, folklore, literature.

Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә татар халкының бәһасез мирасын үз эченә туплаган кулъязма дастаннар саклана. Дастаннарның хронологик чикләре XVII гасыр – XX гасыр башы аралыгын колачлый.

Төрле елларда оештырылган археографик экспедицияләрнең саллы нәтиҗәсе булып торган әлеге язма ядкярләрнең саны бихисап. Биредә татар халкы арасында аеруча яратып укылган Таһир белән Зөһрә , Йосыф-Зөләйха, Ләйлә һәм Мәҗнүн, Сәйфелмөлек сюжетына корылган романик; дини-каһарманлык төркеменә караган «Каһарман Катил»; гыйлем алуның әһәмиятен ассызыклаган «Дастане җайә» дастаннары саклана. Бу кулъязма-хәзинәләр исемлеген «Чыңгыз хан нәселе», «Аксак Тимер», «Идегәй» кебек борынгы дастаннарны үз эченә алган «Дәфтәре Чыңгызнамә» җыентыгы тулыландыра.

Китапханәдә тупланган дастаннарның һәрберсенә аерым тукталып, кыскача анализ ясаудан элек, татар дастаннарына хас үзенчәлекләрне карап үтү бик тә урынлы булыр.

Мәгълүм булганча, Идел буе җирлегендә таралган дастаннар чичән-импровизаторлар тарафыннан башкарыла торган әсәрләрдән бераз аерылып тора. Шул ук вакытта бу төр ядкярләр әдәби дастаннар категориясенә карый торган әсәрләрдән дә үзгә. Бүгенге көндә әлеге үзенчәлекле иҗат үрнәкләрен китаби дастаннар термины белән атап, әдәбият белән фольклор чигендә торган дастаннар буларак өйрәнү гамәлгә кертелгән.

Татар китаби эпос-дастаннары төп ике темага бүлеп карала. Беренче төр дастаннар – архаик, тарихи һәм дини-каһарманлык әсәрләренең һәркайсын этаплап үз эченә алган каһарманлык дастаннары булса, икенче төре мәхәббәт вакыйгалары тасвирланган романик характердагы әсәрләрдән гыйбарәт.

Кульъязма мирасны барлаганда, дастан жанры билгеләренә ия булып та, «кыйсса», «хикәя», «хикәят», «намә» кебек исемнәр белән аталган әсәрләргә еш юлыгырга туры килә. Хәтта бер үк сюжетка корылган әсәрләрне төрле чыганакта төрле жанр исеме белән атау очраклары да бар. Үз чорында язучы-күчерүче тарафыннан аларның бүгенге термин белән аталмаган булуы табигый, шул рәвешле, эпик билгеләргә ия әсәрләр «дастан» төшенчәсенә мәгънәдәш булырлык сүзләр белән билгеләнгәннәр. Бүгенге көндә дастан буларак каралган язма-китаби ядкярләр арасында «китап» сүзе белән аталу очраклары да күзәтелә. Мәсәлән, «Йосыф китабы» («Китабы Йосыф»), «Түләк китабы» һ.б. Аеруча киң таралган сюжетлы дастаннар арасында фәкать төп геройларның исемнәре белән генә йөртелүче әсәрләр дә бар: «Сәйфелмөлек», «Түләк», «Бүз егет» һ.б. [Мухаметзянова, 2014, с. 101–124].

Дастан сүзенең башка термин белән аталу күренеше Милли китапханә фондларында сакланган кульъязмаларга да кагыла. Биредә «дастан» төшенчәсен күбрәк «кыйсса» сүзе алыштыра. Фәкать геройларның исеме белән генә аталган вариантлар да бар. Шуларның берсе – «Таһир илә Зөһрә» дастаны [Таһир илә Зөһрә, сакл. бер. 3434-Т]. Илле биш кәгазьдән гыйбарәт әлеге кульъязма 2010 елгы археографик экспедицияләр вакытында Әтнә районы Өҗем авылында табылган.

Шуны әйтергә кирәк: Кульъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә Таһир белән Зөһрә сюжетына корылган дастаннар иң зур күпчелекне тәшкил итә[1]. Безнең фикеребезчә, ике үсмернең трагик мәхәббәт тарихына нигезләнеп кенә калмыйча, ата белән бала, иҗтимагый

[1] «Таһир-Зөһрә кыйссасы», шифр-2297-Т, Самара өлкәсе Елхов районы Теплый Стан авылында табылган, 7 кәгазь; «Таһир-Зөһрә» кыйссасы шифр-2919-Т, 1998 елда Оренбург өлкәсе Ташлы районы, Бәшир авылында табылган, 48 кәгазь; «Таһир илә Зөһрә һәм бәетләр», шифр-3427-Т, 2010 елда Әтнә районы Ташчишмә авылында табылган, 65 кәгазь.



Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә 2919-Т шифры белән саклана торган «Таһир-Зөһрә» кыйссасының беренче бите

тигезсезлек проблемаларын үз эченә алган бу сюжет, халыкның яшәешенә аваздаш булу сәбәпле, күп гасырлар буе укылган, күчереп язылган.

Бүлектә тематикасы ягыннан Таһир белән Зөһрә сюжетына охшаш тагын бер әсәр – XIX гасыр уртасына караган кулъязма «Кыйссаи Ләйлә вә Мәҗнүн» саклана. Фарсы телендәге әлеге кыйсса 1966 елда Самара өлкәсе Камышлы районы Иске Ярмәк авылы мәчетеннән алынган. Әсәрнең кәгазьдә бер генә бите сакланып калган [Кыйссаи Ләйлә вә Мәҗнүн, сакл. бер. 432ф (74)].

Татар романик дастаннары халыкның көнкүреш проблемаларын яки тарихи вакыйгаларны чагылдырган әсәрләр түгел. Биредә төп игътибар гашыйк геройның хис-кичерешләре, тышкы һәм эчке матурлыгы, җәмгыятьнең гаделсез кануннары белән көрәшенә юнәлдерелә. Шул ук вакытта бу дастаннар татар халкының әдәбият, фольклор әсәрләре белән яхшы таныш булуын, аларның рухи кыйммәтен аңлап, дөрес һәм кирәкле урында куллана белүен күрсәтә [Хөсәенова, 2023, № 1, б. 73].

Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә, романик дастаннардан тыш, борынгы мифологияне, халыкның үткәнен, аның дини традицияләрен чагылдырган «Каһарман Катил кыйссасы» саклана. XVII гасырга караган бу кулъязма Әтнә районы Ташчишмә авылында табылган [Каһарман Катил кыйссасы, сакл. бер. 3409-Т]. Утыз алты кәгазьдән гыйбарәт әлеге борынгы дастанны фәнни әйләнешкә кертеп, хәзерге татар теленә яраклаштыру зарурлыгы бар.

2008 елдан Татарстан Республикасы Милли китапханәсендә «Татар археографиясе» дип исемләнгән китаплар сериясе нәшер ителеп килә. Әлеге китапларда аеруча әһәмиятле дип табылган язма истәлекләр басыла. Бу исемлектә татар дастаннары да лаеклы урын алган. Борынгы дастан текстлары гарәп графикасында язылганлыктан, аларны хәзерге телгә яраклаштыру ихтыяҗы килеп туа. Әлеге кулъязмалар текстолог Рәиф Мәрданов тарафыннан транслитерацияләнеп, бүгенге көн укучысы укый алырлык дәрәҗәгә җиткерелде. Күзәтүне 2019 елда 23 нче китап буларак нәшер ителгән ««Чыңгызнамә»: тарихи дастаннар» китабыннан башлыйк.

«Чыңгызнамә» («Дәфтәри Чыңгызнамә») – тарихи, фольклор һәм әдәби үзенчәлекләрне үзендә туплаган, халык тарафыннан яратып кабул ителгән дастаннар китабы. Әлеге ядкярнең XVII гасыр ахырына барып тоташуы мәгълүм.

Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә «Чыңгызнамә» җыентыгына кергән 11 кулъязма текст бар. «Татар археография»сенең әлеге сериясендә башка оешмалардан тапшырылган язмалар да өстәлеп, 15 кульязма тупланды. Кереш мәкаләдә Р. Мәрданов «Чыңгызнамә» китабының өйрәнелү тарихы, авторлык мәсьәләсе, кайсы чорга каравы, хәзергәчә сакланган күчермәләре һ. б. турында тәфсилләп яза. Китап ахырында




Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә 3409-Т шифры белән саклана торган «Каһарман Катил» әсәренең беренче бите

һәр кулъязма текстка тасвирлама бирелеп, иң соңыннан сүзлек тәкъдим ителә [Чыңгызнамә»: тарихи дастаннар, 2019].

2016 елда Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге хезмәткәрләре тарафыннан Арча районы авылларына оештырылган экспедициядә әлеге көнгә кадәр исеме мәгълүм булмаган дастан табыла. Кулъязма Югары Пошалым авылында яшәүче Нургали Зарипов тапшырган борынгы кулъязмалар җыентыгында урын алган. «Дастане җайә» дип аталган бу ядкяр XVII гасырга карый, барлыгы 58 кәгазьдән гыйбарәт. Дастан 2017 елда бай эчтәлекле мәкалә, текст транслитерациясенең хәзерге татар әдәби телендәге варианты, кулъязмасының факсимилесе һәм тасвирламасы белән «Татар археографиясе» сериясендә 19 нчы китап буларак нәшер ителде [Дастане җайә, 2017].

Җыентыкта ислам дине шәригате нигезләренә багышланган татарча, гарәпчә текстлар урын алган. Кулъязманың битләре шактый тетелгән. Бу – дастанның саклану дәрәҗәсе түбән булуын күрсәтә.

Шунысын әйтү мөһим: моңарчы дастанның тулы тексты һәм «Дастане җайә» атамасы мәгълүм булмаса да, әдәбият тарихында әсәрнең сюжетына охшаш эчтәлекле чәчмә һәм шигъри әсәрләр булуын инкяр итеп булмый. Әйтик, татарлар яшәгән җирлектә без тикшерә торган дастанның кыскартылган варианты «Мәликә китабы» буларак киң танылган. 1846 елдан башлап XX гасыр башына кадәр аның уннан артык басмасы дөнья күргән. Эчтәлеге белән «Дастане җайә»гә охшаш тагын бер әсәрне әйтеп китү урынлы булыр. «Кыз хикәяте» исемле күләмле шигъри кыйсса «Татар археографиясе» сериясенең 10 нчы китабында басылып чыкты [Кыз хикәяте, 2012]. Әлеге әсәр турындагы мәкалә «Татар әдәбияты тарихы» күптомлыгының соңгы басмасында да урын алды. Бу хикәят Алтын Урда чорында (1382 ел) Ибраһим исемле шагыйрь иҗат иткән әсәрнең сюжетын үстереп, баетып нәзыйрә алымында язылган. «Дастане җайә»нең Ибраһим әсәре һәм «Кыз хикәяте» белән уртак яклары шактый күп. Аеруча дастанның башлангыч һәм бетем өлешләре әлеге әсәрләр белән охшаш. Ә «Мәликә китабы»на килгәндә, ул урыннарга артык зур игътибар бирелми. Шулай да «Дастане җайә»нең сорау һәм җаваплардан торган төп өлеше белән «Мәликә китабы»ның басма текстларында охшашлыклар шактый күп [Дастане җайә, 2017, б. 5].

«Дастане җайә» әсәренең исеме гадәти булмаганлыктан, укучыга үзлегеннән генә аның асылына төшенү яки фаразлау шактый кыен. Р. Мәрданов бу атаманың мәгънәсе турында кереш мәкаләсендә болай дип яза:

*«Әсәр исемендәге “җайә” дигән сүз текстта бер мәртәбә дә кабатланмаган. Ләкин дастанның эчтәлегенә күрә аның мәгънәсен фаразларга мөмкин. Фарсы телендәге “җай” сүзе “урын”, гарәп телендәге “җәәә” сүзе “килү, кайту, башкару” кебек мәгънәләргә ия. Шунлыктан, әсәрнең исемендәге “җайә” сүзен “урнашу, җәмгыятьтәге урынга (дәрәҗәгә) ирешү-кайту” күздә тотылган*

*дип аңлатырга мөмкин. Бәлки бу атамадагы "җайә" сүзендә берәр хәрефе (мәсәлән "р") төшеп калгандыр, һәм ул "җария" дип языласы булгандыр дип тә гөманлап була. Әмма "җария" сүзе, гадәттә, хезмәтче кыз, кол кыз дигән мәгънәләрдә йөргәнгә күрә, аның әсәрдәге патша кызына карата кулланылган булуы бик шикле. Шулай ук "җайә" сүзе язылышында ниндидер хәреф төшеп калган булса, күчерүче яки кульязманы укучылар тарафыннан ул өстәлгән һәм төзәтелгән булыр иде. Әсәрнең төп текстына өстәмә һәм төзәтмәләр кертелгән булуы шундый нәтиҗәгә этәрә»* [Дастане җайә, 2017, б. 4].

Безнең фикеребезчә, текстологның беренче фаразы дөреслеккә шактый якын, сюжетта егетнең күп сынаулар кичкәннән соң гына җәмгыятьтә югары дәрәҗәгә ирешүе сурәтләнә.

Мәгълүм булганча, татар китаби дастаннары төрки эпик традицияләр һәм Борынгы Көнчыгыш әдәбияты йогынтысында формалашканнар. Эпик сюжетларны татар халкы борынгы Көнчыгыш фольклорыннан һәм әдәбиятыннан, гомумтөрки эпик фольклорыннан үзләштергән һәм аларга үзеннән үзгәрешләр керткән. Нәтиҗәдә, хронологик яктан тирән тамырларга барып тоташкан, географик яктан татар халкы белән бәйле күп халыкларның бетмәс эпик иҗатын һәм әдәби мирасын үз эченә алган искиткеч катлам барлыкка килгән [Мухаметзянова, 2014, с. 143]. Кульязма хәлендә сакланып калган «Дастане җайә» әсәре дә бу сыйфатлардан хали түгел. Әйтик, дастан Көнчыгыш традицияләрендә кулланыла торган мотив – Аллаһы Тәгаләне мактау, Мөхәммәд пәйгамбәр һәм аның гаиләсе өчен дога кылу белән башланып китә:

*«Ике дөньяның хуҗасы Аллаһы Тәгаләгә шөкерләр булсын. Һәм тәкъва бәндәләргә хәерле ахырлар сорыйбыз. Иң камил зат Мөхәммәдкә һәм барлык нәсәбенә дога һәм сәламнәр булсын»* [Дастане җайә, 2017, б. 78].

Шул урында ук борынгы төрки эпик мотив – баласызлык мотивы күзгә ташлана:

*«Әмма бел һәм хәбәрдар бул, дөньяда күпне күргән-белгәннәр сөйләгәннәр: Рум шәһәрендә бер патша бар иде, исеме Гасаран иде, улы-кызы юк иде. Кәгъбәгә барып, кырык корбан чалып, Олуг һәм Бөек Аллаһка ялварды: "Әй, бер Ходаем! Миңа угыл яки кыз бирсәңче?!" – дип теләде. Тәңре Тәгалә догасын кабул кылды. Өенә килсә, бер кыз пәйда булды, исемен Мәликә дип куйды. Гадәттән тыш акыллы, зирәк һәм гүзәллек иясе, аның кебек белемле кеше юк иде»* [Дастане җайә, 2017, б. 78].

Текстта ислам диненең көчле йогынтысы билгеле бер мотивлар, символлар белән генә чикләнеп калмый, ә әсәрнең буеннан буена сюжетка үрелеп бара. Геройларның дөньяга карашы, кызның егеткә әзерләгән сорауларының дини шәригатькә нигезләнүе, диалогта бик күп пәйгамбәр исемнәре телгә алыну – болар барысы да безнең фикеребезнең дөреслеген дәлилли.

«Дастане җайә» әсәренең эчтәлегенә кыскача күзәтү ясап үтик.

...Кайчандыр гомерендә дә мохтаҗлык күрмәгән, үз байлыгының хисабын белмәс дәрәҗәдә чиксез мөлкәтле бер кеше яшәгән. Бу кешегә көтмәгәндә каза килеп, ул бөлгенлеккә төшкән. Байның Габдулла исемле галим улы булган. *«Дус-дошман арасында бу хәлдә үлгәнче, кая да булса китик»,* – дип, улы ата-анасын алып юлга чыккан.

Бу урында шуңа игътибар итәргә кирәк: матди байлык – тотрыксыз, аның гомерлеккә сакланачагын төгәл әйтеп булмый, ә гыйлем тормышның теләсә кайсы чорында да югалмый, киресенчә, кыенлыкларны җиңеп чыгарга ярдәм итә. Шул рәвешле, дастанның нигезендә гыйлемнең кеше өчен иң әһәмиятле төшенчә булуы идеясе ята. Егетнең гаиләсе мохтаҗлык, ачлык сынауларын узып, геройларның Аллаһы Тәгаләгә тәвәккәл кылулары, аның ярдәменә ышанып, зур эшләргә алынулары, шәригать кануннарын бик тирәнтен белүләре сәбәпле, барлык авырлыклар да артта кала. Бу әсәрдә гыйлемлелеккә, диндарлыкка, сабырлыкка дан җырлана. Дастан егетнең патша кызына өйләнеп, ата-анасы белән янәдән кушылып, элеккедән дә мулрак тормышта яшәп калуы белән тәмамлана.

Милли китапханәдә сакланган тагын бер дастанга кыскача күзәтү ясыйк. 1996 елның апрелендә археографик экспедиция вакытында Самара өлкәсенең Камышлы авылында аеруча әһәмиятле ядкяр – «Түләк» дастанының яңа кулъязмасы табыла. Әлеге кулъязма XIX гасырның беренче яртысында күчерелгән җыентыкның 4–14 битләрен тәшкил итә. Китапчыкның 36б кәгазендә *«ошпу төбне йазгучы мулла Сибгатулла бине мулла Фәхретдин мөдәррис, мөхтәсиб Багданов»* дигән сүзләр бар. Дастан тексты да шушы кеше кулы белән күчереп язылган [Түләк китабы, 2008, б. 13]. Хәзерге көндә бу кулъязма җыентык Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә 1761-Т шифры белән саклана.

«Түләк» дастаны – экияти-мифологик сюжетка корылган әсәр. Дастанда җир егете Түләк белән Чачар хан кызы Сусылуның мәхәббәте тасвирлана. Түләктә сөйгәнен ярату хисе мәхәббәт каһарманнары Сәйфелмөлек, Таһир, Мәҗнүннеке кебек чиксез көчле, шулай да герой өчен туган илне, ата-ананы ярату кебек төшенчәләр дә зур кыйммәткә ия.

Алгарак китеп, шунысын әйтик: Милли китапханәдә поэманың өч дистәдән артык нөсхәсе саклана. Әлеге кулъязмаларны 2008 елда текстолог Р. Мәрдәнов «Кыйссаи Йосыф поэмасының Татарстан Милли китапханәсендә саклана торган кулъязмаларына тасвирламалар» дигән исем астында китап итеп бастырып чыгарды. Галим билгеләп үткәнчә, әлеге текстларның бер өлеше Татарстан, Башкортстан һәм Мари Эл Республикаларында, Пермь, Пенза, Самара, Омск өлкәләренә оештырылган экспедицияләр вакытында табылган [«Кыйссаи Йосыф» поэмасының Татарстан Милли китапханәсендә саклана торган кулъязмаларына тасвирламалар, 2009, б. 6]. Фондта поэманың «Кыйссаи

Йосыфның башка варианты» [Кыйссаи Йосыфның башка варианты, сакл. бер. 2290-Т] һәм «Хикәяте Йосыф галәһиссәлам» [Хикәяте Йосыф галәйһиссәлам, сакл. бер. 614-Т] дип исемләнгән авторсыз вариантлары да очрый. Күргәнебезчә, гарәп язулы бу кульъязмаларның авторы билгесез булу өстенә, исеме дә яңача яңгыраш алган. Бу күренеш әсәрнең халыкта төрле вариантлары яшәп килгәнлеккә һәм саклануга ныклы бер дәлил булып тора [Хөсәенова, 2023, б. 71].

Күзәтүләрдән күренгәнчә, Татарстан Республикасы Милли китапханәсендә күпсанлы борынгы татар эпос-дастаннары саклана. Кульъязма истәлекләр жанр билгеләре буенча «дастан» терминына туры килсәләр дә, «кыйсса» сүзе белән аталып йөртелгәннәр. Биредә архаик, тарихи һәм дини каһарманлык әсәрләрен тәшкил иткән каһарманлык дастаннары һәм мәхәббәт сюжетына корылган романик дастаннар да җитәрлек. Шулай да фондта соңгылары сан ягыннан күпчелекне тәшкил итә. Таһир белән Зөһрә, Сәйфелмөлек, Йосыф китабы сюжетларына корылган дастаннар халык күңеленә аеруча якын булган, буыннан буынга сөйләнелгән, күпсанлы кульъязма вариантлары барлыкка килгән. Шунысын әйтергә кирәк: китапханәдә саклана торган дастаннарның күләме зур түгел, эчтәлекләре ягыннан әкияткә якын торган дастаннар да бар. Бу – татар дастаннарын башка төрки халыклар версияләреннән аерып торган иң зур үзенчәлек. Моннан тыш, текстларда борынгы эпик элементлар белән беррәттән, Көнчыгыш традицияләре дә чагылыш таба. Мондый характердагы билгеләр бүлектә сакланган иҗат үрнәкләренә генә түгел, барлык татар дастаннарына хас.

Әлеге мәкаләдә Кульъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә саклanучы дастаннарга гомуми күзәтү ясалды. Фондта, болардан тыш, дастан жанрына караган тарихи китаби хәзинәләребез бихисап. Алар барысы да диярлек тасвирланган, әмма текстологик анализ ясалмаган. Борынгы текстларны хәзерге татар язуына күчереп, укучыларга тәкъдим итү иң зур максатларның берсе булып тора.

Халыкның динен, менталитетын, идеалларын чагылдырган татар дастаннары Татарстан Республикасы Милли китапханәсе өчен генә түгел, милләт өчен дә бик кадерле. Шуңа күрә Кульъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге хезмәткәрләре бу рухи мирасны җыю, тасвирлау һәм укучыларга җиткерү эше белән актив шөгыльләнә.

**Әдәбият**

Дастане җәйә (Мәликә китабы) / төз. Р. Мәрданов. Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2017. 148 б. («Татар археографиясе» сериясе, 19 нчы китап).

Каһарман Катил кыйссасы // Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең Кульъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге, сакл. бер. 3409-Т.

Кыз хикәяте / төз.-авт. Р. Мәрданов. Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2012. 184 б. («Татар археографиясе» сериясе, 10 нчы китап).

Кыйссаи Йосыфның башка варианты // Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең Кульъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге, сакл. бер. 2290-Т.

«Кыйссаи Йосыф» поэмасының Татарстан Милли китапханәсендә саклана торган кульязмаларына тасвирламалар / төз.-авт. Р. Мәрданов. Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2009. 92 б. («Татар археографиясе» сериясе, 3 нче китап).

Кыйссаи Ләйлә вә Мәҗнүн // Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең Кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге, сакл. бер. 432ф (74).

*Мухаметзянова Л.Х.* Понятие «Книжный эпос» в мировой фольклористике и татарские книжные дастаны // Филологические науки. Вопросы теории и практики. Научно-теоретический и прикладной журнал. 2014. Вып. 5. С. 141–144.

*Мухаметзянова Л.Х.* Татарский эпос: книжные дастаны. Казань. 2014. 380 с.

Таһир илә Зөһрә // Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең Кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге, сакл.бер. 3434-Т.

Таһир илә Зөһрә һәм бәетләр // Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең Кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге, сакл. бер. 3427-Т.

Таһир-Зөһрә кыйссасы // Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең Кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге, сакл. бер. 2297-Т.

Таһир-Зөһрә кыйссасы // Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең Кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге, сакл. бер. 2919-Т.

Түләк китабы: дастан / төз. Р. Мәрданов. Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2008. – 76 б. («Татар археографиясе» сериясе; 2 нче китап).

Хикаяте-Йосыф-галәйһиссәлам // Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең Кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге, сакл. бер. 614-Т.

*Хөсәенова Г.Р* Милли китапханә фондларында мәхәббәт сюжетына корылган дастаннар: таралу тарихы һәм үзенчәлекләре // Китапханә. Фәнни-популяр журнал. 2023. № 1 (55). Б. 70–73.

«Чыңгызнамә»: тарихи дастаннар / төз. Р. Мәрданов. Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2019. 288 б. («Татар археографиясе» сериясе, 23 нче китап).

***Хөсәенова Гөлнирә Рәзиф кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Татарстан Республикасы*
*Милли китапханәсенең Кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге*
*хезмәткәре*

УДК 94(516)

*Г.Т. Хәйруллин*

# НӘБИҖАН ТУРСУН ТАТАРЛАРНЫҢ КӨНЧЫГЫШ ТӨРКЕСТАН РЕСПУБЛИКАСЫН ТӨЗҮ ӨЧЕН КӨРӘШҮЕ ТУРЫНДА (1944–1949)

Статья посвящена борьбе татар за создание свободной Восточно-Туркестанской республики в Синьцзян-Уйгурском автономном районе Китая в 40-е годы прошлого столетия. Раскрыта роль представителей татарского народа в революционных событиях того периода. Описаны боевые действия партизанских отрядов против гоминдановских войск. Указаны татары, принимавшие активное участие в боях, занимавшие ответственные посты в Восточно-Туркестанской республике. Источником для написания статьи послужил материал VII тома исследования Набижана Турсуна «Всеобщая история уйгуров».

**Ключевые слова:** Восточный Туркестан, Синьцзян, республика, Кульджа, гоминдан, восстание, народ.

The article is devoted to the struggle of the Tatars for the creation of a free East Turkestan Republic in the Xinjiang Uygur Autonomous Region of China in the 40s of the last century. The role of representatives of the Tatar people in the revolutionary events of that period is revealed. The combat operations of partisan detachments against the Kuomintang troops are described. The Tatars who took an active part in the battles, who held important positions in the East Turkestan Republic are indicated. The source for writing the article was the material of the VII volume of Nabizhan Tursun's study «The General History of the Uyghurs».

**Keywords:** East Turkestan, Xinyiang, republic. Ghulja. Kuomintang, uprising, people.

Кытай Халык Республикасының төньяк-көнбатыш ягында Синьцзян-Уйгур автономияле районы бар. Монда хәзер дә биш мең тирәсе татар яши. Алар үзләренең татарлыгын югалтмаган, телләрен, татар гореф-гадәтләрен саклап гомер итә; биредәге татар яшьләре тарихи ватаныбыз Татарстанда, Казан шәһәрендә белем алуны хуп күрә, гаилә корып, төпләнеп яшәп калучылар да юк түгел. Менә шул татарларның ата-бабалары узган гасырның катлаулы 30–50 нче елларында үзләре өчен татарга хас туры юл тапканнар.

Танылган галим Нәбиҗан Турсун «Уйгурларның гомуми тарихы» дип аталган күптомлыгын укучыларга тәкъдим итте. 1995 елда Мәскәүдә докторлык диссертациясе яклаганнан соң, тарихи китаплар авторы Н. Турсун Россия, Америка, Кытай, Төркия, Франция, Казакъстан һәм башка илләр университетларында лекцияләр укыган. Күптомлык шул ук проблемаларга багышланган башка әсәрләр арасында иң тулысы, иң тәфсиллесе һәм системалысы дип танылган. Ул киң аудиториягә билгеле булмаган архив материалларына нигезләнүе белән аерылып тора. Әсәрнең җиденче томы Көнчыгыш Төркестан

Республикасы төзелүгә һәм шул чорларда булган вакыйгаларны тасвирлауга багышланган. Автор күпсанлы тарихи чыганакларга, шул исәптән Россия, Кытай архивлары һәм матбугаты материалларына, хәрәкәттә катнашучыларның хатирәләренә таянган. Бу төбәктә яшәгән халыкның гоминданга каршы хәрәкәте милли-азатлык революциясе дип бәяләнгән. Татар халкы вәкилләренең шул чорда тоткан урынын, шул вакыттагы вакыйгаларга катнашын югарыда күрсәтелгән китапка таянып күзаллауның татар тарихы өчен әһәмияте зур булырга мөмкин.

XIX гасыр дәвамында Кытайда, Тәңретау (Тянь-Шань) тау системасы тирәсендә күпсанлы восстаниеләр, беренче нәүбәттә, мөселманнарның милли изүгә каршы протестлары булып торган. Россия архивларында сакланган материалларга караганда, 1923–1925 елларда ук шушы төбәктә (бигрәк тә Кашгар, Аксу, Колҗа шәһәрләрендә) милли азатлык яулап алуны максат иткән оешмалар эшләгән. Колҗа шәһәрендә барлыкка килгән «Көнчыгыш» оешмасы әгъзалары хәтта Коммунистик интернационал агентлары белән дә элемтәгә кергәннәр. 1931 елда мөстәкыйль Уйгур дәүләтен кору өчен кораллы көрәш башланган. Нәкъ шул көрәш нәтиҗәсендә Көнчыгыш Төркестан Ислам Республикасы игълан ителгән дә. Кызганычка каршы, Советлар иле җитәкчелеге бу очракта Япония һәм Бөекбритания мәнфәгатьләре гамәлгә ашырыла, дип исәпләгән. Шуңа күрә Кызыл Армия атлы гаскәре, дәүләт чиген үтеп кереп, восстаниене тар-мар итүдә катнашкан, совет гаскәрләренең бер өлеше Кумулда урнашып калган. Җирле халыкның хәтерендә Советлар Союзы ирекле яңа дәүләт – Көнчыгыш Төркестан Ислам Республикасын һәм аның атаклы баһадирларын юкка чыгаручы буларак сакланган.

Әмма Синьцзян төбәгендә бәйсезлек идеясе һәм азатлыкка омтылыш югалмаган. Тора-бара мондагы шәһәрләрдә яшерен оешмалар күренгәли башлаган. Алар барыннан да элек агитация һәм пропаганда эше белән шөгыльләнгәннәр. 1944 елда чыгарылган листовкада: «Борынгы заманнардан бирле уйгурлар, таранчылар, казакълар, үзбәкләр һәм татарлар шушы җирләрдә яшәгән, – диелә. – Бүген дә аларның нәселләре монда гомер сөрә. Бу территория уйгурларныкы һәм башка төрки халыкларныкы». Көнчыгыш Төркестан революциясенә катнашкан уйгурлар, казакълар, кыргызлар, үзбәкләр һәм татарлар – тугандаш халыклар, төркиләр, кытайларга этник яктан да, мәдәни яктан да охшамыйлар. «Көнчыгыш Төркестан – уйгурларның һәм башка тугандаш төрки халыкларның ватаны», – дип нәтиҗә ясалган [Турсун, б. 35]. Шуны да өстәргә кирәк: татарларның борынгы заманнардан бирле Азия җирләрендә яшәгәнлеге академик М.З. Зәкиев, тарих фәннәре кандидаты М.И. Ерзин һәм башка галимнәрнең хезмәтләрендә дә чагылыш таба.

Текстта колонияләштерү чорындагы сәясәтнең ислам динен кысуга, мөселманнарны халык дошманы рәвешендә сыйфатлауга юнәтелгән булуы ассызыкланган. Шушы төбәктә яшәүче күпчелек

халыкларның мөселман булуларын исәпкә алганда, бу листовканың халыкка тирән тәэсир ясавы бәхәссез.

«Без ни өчен көрәшәбез?» дип аталган агитацион материалда көрәшнең төп максаты күрсәтелгән: «Без үзебезнең Көнчыгыш Төркестанда кытайлар хакимлеген һәм безнең территориядә кытай тиранлыгының бөтен чыганакларын юк итү өчен көрәшәбез. Көнчыгыш Төркестанның чын хуҗалары – уйгурлар, казакълар, кыргызлар, татарлар, үзбәкләр, шулай ук кытай изүеннән җәфа чигүче монголлар һәм кытай милләтенә карамаган башка халыклар. Милли азатлык оешмасы Көнчыгыш Төркестанда бөтен милләтләр арасында чын тигезлеккә ирешү өчен көрәшә». Ул түбәндәге юллар белән тәмамлана: «Һәркем үзе сайларга тиеш: азат һәм бәхетле булып яшәргәме, яки кытай изүе астында интегүне дәвам итәргәме». Шунда ук кешеләрне көрәшкә кушылырга чакыру яңгырый: «Ходай Тәгалә безнең яклы һәм аның рәхиме безнең белән» [Турсун, б. 122–124].

Бу вакыйгаларда үзбәк һәм уйгур яшьләре тарафыннан 1944 елның апрель аенда Колҗа шәһәрендә оештырылган «Азатлык җәмгыяте»нең роле зур булган. Оешмага кергән кешеләрнең күпчелеге Россиядә туып, СССРда укыганнар. Идеологик яктан каршылыклар шактый булса да, оешма әгъзалары гомуми гоминданга каршы көрәш идеясе нигезендә берләшә алганнар. Милли изүдән азат булу һәм мөстәкыйль Көнчыгыш Төркестан Республикасын (КТР) төзү төп максат итеп куелган.

Оешманың рәисе – милләте буенча үзбәк Алихан Тура Шакирходжаев (1885–1976) Токмак шәһәрендә (Кыргызстан) туып-үскән. Советка каршы хәрәкәттә катнашуда гаепләнеп, кулга алынган; тоткынлыктан качып киткән һәм Синьцзянга барып чыккан. Ислам дине кагыйдәләрен һәм Изге Корьәнне яхшы белүе аркасында биредә мулла булган һәм җирле халык арасында зур абруй казанган.

1944 елның июль аенда Колҗа шәһәрендә яшерен рәвештә «Азатлык очкыны» газетасы чыга башлый. «Азатлык оешмасы» җитәкчелегендәге редакциянең эшендә мондагы зыялыларның күренекле вәкилләре, шул исәптән танылган журналист, татар егете Хәбиб Фазылҗан улы Юничи дә (1906–1945) катнаша. Колҗада туып-үскән бу егет Россиядә, Төркиядә, Германиядә укыган. Монда ул уйгур телендә газеталар бастыру белән шөгыльләнгән, халык арасында белемле, зыялы шәхес булып танылган, революцион хәрәкәттә актив катнашкан, соңрак КТР хөкүмәте составына кергән.

Газета материаллары азатлык идеяләре, төрки халыкларның изелүгә каршы көрәше, бердәмлеккә өндәү белән сугарылган. Шуңа күрә бу материаллардагы фикерләр башка басмаларда да яңгыраш ала. Мисал өчен, «Көрәш» журналының 1946 елгы бер санында Мөхәммәт Иминнең «Без революция ясарга хаклыбыз» исемле мәкаләсе басылган. Анда болай диелгән: «Гоминдан партиясе оешу белән үк... Көнчыгыш Төркестан халыкларына басым көчәйде. Безгә каршы сәяси, икътисади, социаль изү белән генә канәгатьләнмичә, безнең милли

структурабызны җимерү, ассимиляцияләү, тарихтан исемебезне алып ташлау хәрәкәте башланды». Көнчыгыш Төркестан халкын, бигрәк тә төрки халыкларны – уйгурларны, казакъларны, кыргызларны, үзбәкләрне, татарларны «Кытай колонизаторлары «исламлаштырылган кытайлар» дип атыйлар», төрки халыклар икәнлеген танымыйлар» [Турсун, б. 30]. Менә шушы факторлар 1944–1949 еллардагы революциянең төп сәбәпләрен тәшкил иткән дә инде.

«Азатлык оешмасы» үзенең сәяси программасын игълан иткән. Берничә мәртәбә тикшерелгән әлеге программаның да авторы Х. Юничи булган. Программада кораллы көрәш башлау, Кытай колониаль идарәсен юкка чыгару, милләтләрнең тигез хокуклыгын тәэмин итү, халыкның тормыш-көнкүрешен рәтләү, хатын-кызларның хокукларын тәэмин итү, мәгариф эшләрен җайга салу, бөтен Көнчыгыш Төркестан территориясен азат итәрлек регуляр Милли Армия төзү һәм башка шундый мәсьәләләр куелган. Әйтергә кирәк, Хәбибнең бертуган энесе Айтуган – шушы программа басылган «Азатлык очкыны» газетасын таратучыларның берсе. Соңрак ул Көнчыгыш Төркестан Республикасы Милли Армиясе подполковнигы хәрби дәрәҗәсен ала, полк командиры була. А. Юничев гомеренең соңгы елларын Алма-Ата шәһәрендә үткәрә, мондагы татар милли-мәдәни хәрәкәтендә актив катнаша.

Бу программа җирле халыкка гаҗәеп көчле йогынты ясаган. Күп урыннарда «Хәрби-революцион группалар, комитетлар» оештырыла башлаган, партизан отрядлары төзелгән. Соңрак әлеге программа «Бәйсезлек декларациясе»нең нигезенә салынган.

Кытайдагы хәлләр турында совет консуллары Мәскәүгә хәбәрләр җибәреп торганнар. Колҗа һәм Чөгүчәк шәһәрләрендә яшерен оешмалар барлыкка килә башлаган вакытта да Советлар Союзы Кытай мәсьәләсен күз уңында тоткан. 1943 елның маенда Мәскәүдә Коммунистлар партиясе Политбюросы «Синьцзянда Шен Шицайга каршы милли-азатлык хәрәкәтенә ярдәм күрсәтү» турында махсус карар кабул иткән.

Совет гаскәрләренең Көнчыгыш Төркестан Ислам дәүләтен тар-мар итүдәге ролен искә алып, хәрби ярдәмне башка бер төбәктә күрсәтү уңайрак булыр, дип табылган. Шуңа күрә Советлар Союзы җитәкчелеге хәрби күтәрелешнең Или һәм Тарбагатай өлкәләрендә башланып китүен хуплаган. Чынлап та, бу төбәктә яшәгән халык күбесенчә совет хакимлеге тәэсиренә бирелгән булган. Биредә яшәгән халыкларның милли составына килгәндә, 1944 елда анда өч миллионнан артык уйгур, 440 меңгә якын казакъ, 222 меңнән артык кытай, 100 меңгә якын дунган, 6 мең чамасы кыргыз, 6 меңләп татар һәм башка милләт вәкилләре яшәгән.

Л.П. Берия үткәргән киңәшмәдә махсус төркем төзү турында карар кабул ителгән. Генерал В.С. Егнаров җитәкчелегендәге махсус төркем Синьцзян партизаннарына булышу мәсьәләсен хәл итәргә һәм аларга Урта Азиядәге совет республикаларының ярдәмен дә

оештырырга тиеш булган. Махсус төркемнең штабы Алма-Атада урнашкан. Тиз арада Алма-Ата, Ташкент, Фрунзе шәһәрләрендә хәрби курслар оештырылган. Монда булачак восстаниене көчәйтерлек кадрлар әзерләү күз алдында тотылган.

Шуның белән бергә, Колҗа азат ителгәнче, СССР баш күтәрүчеләргә ачыктан-ачык ярдәм күрсәтмәгән. Әмма хәрби курслар үз эшләрен дәвам иткән. Мәсәлән, Фатих Мөслимов төркеме дә – Алма-Атадагы курс курсантлары. Алар 1944 елның августында Кытайның Или өлкәсенә үтеп кергәннәр. Төркемнең бурычы мондагы коралլы восстаниегә җитәкчелек итүдән гыйбарәт булган. Фатих Мөслимов төркеменә Хәмит Мөслимов белән Рафик Байчурин да кергән (икесе дә Фатихның якын туганнары: Хәмит – Фатихның бертуган абыйсының улы, Рафик – бертуган апасының улы). Төркем командиры Фатих Мөслимов Или өлкәсенең нәкъ шушы төбәгендә гомер кичергән, монда ул сәүдә эшләрен оста оештыручы булып танылган, тирә-юньдә таныш-белешләре дә байтак булган. Кытай хакимлеге ягыннан басым көчәйгәч, Фатих үзе 1943 елда Советлар Союзына чыгып качкан, гаилә әгъзалары, якыннары төрмәгә утыртылган.

Аның нәкъ менә шушы төбәккә отряд белән килеп урнашуы, әлбәттә, тиккә генә булмый. Отряд әгъзалары уйгур һәм казакъ телләрен яхшы белгәнлектән, җирле халык арасында агитация эшләре җәелдерәләр. Яшерен киңәшмә уздырып, нигездә, корал һәм атлар табу белән бәйле практик мәсьәләләрне хәл итү юлларын табалар. Казакъ егетләре агалы-энеле Әкбар һәм Сәит Есбосиннар атлар мәсьәләсен үз өсләренә алалар. Әкбар – Фатихның күптәнге танышы. 1944 елның башында ук ул, Советлар иле территориясенә үтеп, Фатих белән күрешкән, Фатихның киңәше белән монда кайтып, агитация-пропаганда белән шөгыльләнгән.

Ниһаять, 70 кә якын ир-ат, берләшеп, партизан отряды төзиләр. Әлеге беренче партизан отряды 1944 елның 14 августында оешкан, 17 августта Фатих Мөслимов восстаниенең башлануын игълан иткән. Н. Турсун фикеренчә, восстаниене башлап җибәрүчеләр ун кеше булган: биш уйгур, ике казакъ һәм өч татар (Фатих Мөслимов, Рафик Байчурин, Хәмит Мөслимов). Гоминданчылар хакимияте боларга «алты бандит» исемен тагып (Фатих, Әкбар, Гани, Осман, Нур, Хошур), Нилки районына атлы гаскәр җибәргән. Фатих Мөслимовны һәм Корбан Борханидиновны тотучыларга премия бирү турында игълан ителгән (һәр партизан өчен – берәр мең сарык бәясе). Шул арада гоминданчы солдатлар белән бәрелешләр булган, партизаннар трофей сыйфатында корал таба башлаганнар. Отрядтагы кешеләрнең саны йөзгә җиткән. Партизаннарны танытырлык беренче җиңүләр дә күренгән: Акташ поселогында Хәмит Мөслимов җитәкчелегендәге партизаннар гоминданчыларның бер ротасын тар-мар иткән.

Гоминданчылар армиясе белән бәрелешләр туктап тормаган. Әмма Фатих Мөслимов һәм аның хәрби иптәшләре һәрвакыт җиңү

юлын, кирәк вакытта партизаннарның гомерен саклап, качып китү юлларын таба белгәннәр. Аларның даны арткannan арта барган, Фатих Мөслимовны, Гани Маматбакины, Әкбар Есбосинны Фатих-батыр, Гани-батыр, Әкбар-батыр дип атап йөртә башлаганнар. Отрядка казакълар, уйгурлар, кыргызлар, татарлар кушылган, соңрак руслар да өстәлгән, партизаннарның саны алты йөзгә җиткән. Хәзер инде аларны дөрес итеп оештыру таләп ителгән. Командир боерыгы нигезендә Хошур Мамутов партизаннарны корал һәм башка кирәк-ярак белән тәэмин итү өчен җаваплы итеп тәгаенләнгән; гомуми оештыру мәсьәләләрен хәл итү Хәмит Мөслимовка һәм Рафик Байчуринга йөкләнгән. Фатих-батыр бөтен гаскәрнең башында торган, партизаннар өч отрядка бүленгән: отряд командирлары – Гани-батыр, Рафик Байчурин һәм Әкбар-батыр. Сентябрьнең ахырларында өч отряд өч яктан Мазар поселогына һөҗүм итеп, гоминданчыларның бер батальонын тар-мар иткән.

Партизаннарның уңышлары Советлар Союзы җитәкчелегенең дә игътибарыннан читтә калмаган. Л.П. Берия үзенең рапортында партизан отряды командиры хакында түбәндәгеләрне яза: «Фатих Мостафа улы Мөслимов 1906 елда туган. Милләте буенча татар. Бала чагыннан ук Колҗада яшәгән. 1926 елда СССР гражданлыгын алган» [Турсун, б. 136]

1944 елның 5 октябрендә 1600 кеше катнашында (партизаннар, мондагы аксакаллар һәм башка танылган шәхесләр) зур җыелыш үткәрелгән. Шунда Фатих Мөслимов халыкка Нилки шәһәрен азат итүнең әһәмиятен аңлаткан. Шул ук көнне командирларга өч тарафтан Нилки шәһәренә юнәлергә боерык бирелгән. Нилки шәһәрен яулап алу планы буенча беренче рәткә Гани-батыр отряды куелган; икенче (агалы-энеле Есбосиннар) һәм өченче отрядларның (Рафик Байчурин) һөҗүм итү юнәлешләре билгеләнгән. Шуңа өстәп, хәрби инструкторларның махсус төркеме оештырылган (Хәмит Мөслимов, Рафик Байчурин һ.б.). Нилки шәһәре өч яктан урап алынган һәм шәһәр өчен сугыш башланган. Берничә көн дәвам иткән сугыш 8 октябрьдә партизаннарның җиңүе белән тәмамланган. Гоминданчылар гаскәрендә хезмәт иткән кырыкка якын уйгур егете шунда ук партизаннарга кушылган. Нилки төрмәсендәгеләр күпләп азат ителгән, алар арасында соңрак КТРның күренекле хезмәткәрләре булачак кешеләр дә булган. Нилки сугышында партизаннар байтак кына трофей да (мылтыклар, маузерлар һ.б.) кулга төшергәннәр.

Сугыш тәҗрибәләре җитешмәүгә дә карамастан, баш күтәрүчеләр –партизаннар – батырларча көрәшкән. Аларның иң зур җиңүләренең берсе – Суйдун шәһәрен азат итү. Бу хакта Мәскәүгә җибәргән докладында генерал В.С. Егнаров болай дип язган: «25 декабрьдә дошман бик нык каршылык күрсәтүгә карамастан, штурм белән өч тапкыр һөҗүмгә тотканнан соң, Суйдун яулап алынды. Шуның белән бергә, Хоргос – Колҗа юлы дошманнан чистартылды. 300 солдат һәм офицерлардан торган шәһәр гарнизонының күп өлеше

юк ителде. Хәрби трофейлар, шул исәптән мылтыклар һәм пулемётлар кулга төшерелде» [Турсун, б. 269].

Суйдун сугышыннан соң, 1944 елның соңгы көнендә, тыныч юл белән, үзара сөйләшүләр алып бару нәтиҗәсендә Куре шәһәре республика хакимиятенә күчә. Ул иң зур үсешкә ирешкән шәһәрләрнең берсе булган. Аны камап алганнан соң, партизаннар, көчле репродукторлар урнаштырып, шәһәрдәге солдатларны буйсынырга өнди башлаганнар. Уйгур милләтеннән булган гоминдан солдатларының бер төркеме партизаннар ягына чыккан. Шәһәр хакимлеге белән сөйләшүләр башланган һәм алар килешү белән тәмамланган. Әйтергә кирәк, Суйдун, Хоргос, Куре гоминданчылар өчен таяныч ноктасы булган. Шулай итеп, Колҗа шәһәренең көньяк һәм көнбатышында урнашкан, гоминданчыларның иң яхшы ныгытылган терәк пунктлары Көнчыгыш Төркестан Республикасы составына кергән. Нәтиҗәдә Хоргос, Суйдун, Куре тирәсендә гоминданчылар регуляр армиясенең яхшы коралланган ике полкы диярлек юкка чыгарылган.

Партизаннар алдына яңа зур бурыч – Колҗа шәһәре өчен көрәшү бурычы куела. Л.П. Берия күрсәткәнчә, «Мөслимовка ярдәм итү өчен Синьцзянга Пётр Романович Александров җибәрелде. Ул 1892 елда Алма-Атада туган, рус милләтеннән, элек Дутов армиясендә хезмәт иткән, аннары Синьцзянга качкан. 1944 елның августына кадәр ул Колҗада яшәгән, сәүдә белән шөгыльләнгән... Советлар Союзына качып китәргә мәҗбүр булган» [Турсун, б. 159–160].

Партизан отрядлары Колҗа шәһәренә юнәлгән, әмма бу юлда һәртөрле бәрелешләр булып торган. Мисал өчен, Гани-батыр отряды 1944 елның 6 ноябрендә Топадон полиция участогына һөҗүм итеп, шундагы әсирләрне азат иткән. Ирекка чыгучылар арасында Фатих-батырның әнисе, хатыны, хатынының әнисе һәм биш баласы булган.

Колҗа шәһәренең үзендә «Азатлык оешмасы» восстаниегә әзерләнгән, махсус штаб булдырылган. 1944 елның 7 ноябрендә штабта оешма әгъзалары – уйгурлар Рәхимҗан Сабир-хаҗи, Касимҗан Камбари, Абдукәрим Аббасов, татар егете Малик Биктимеров һәм башка берничә кеше җыелган. Нәкъ менә шул көнне шәһәрдә восстание башланган. Монда Абдукәрим Аббасов һәм Пётр Александров туплаган төркемнәр дә катнашкан. Шуны да өстик: Абдукәрим Аббасовның үз отряды белән Колҗага килүе уйгур, татар, рус яшьләренә көчле тәэсир иткән. Яшьләр шушы отрядка языла башлаганнар. Аларның Колҗа шәһәрендәге яшерен оешмасы белән Аббасов отряды арасында элемтә урнаштырылган.

Штаб боерыгы буенча шәһәргә якынлашкан партизан отрядлары гоминданчыларга һөҗүм иткән. Электән үк алып барылган агитация нигезендә гоминданчылар составында булган уйгур яшьләре партизаннарга кушыла башлаган. Партизаннарның саны шәһәр халкы – «уйгур, шулай ук татар, рус, үзбәк, дунган яшьләре хисабына тулыланган. Отрядлар отделениеләргә, взводларга һәм роталарга бүленгән. Шундый бер татар төркеменең командиры итеп Аруп-

абзый, аның урынбасары итеп Айтуган Юничи, сәяси урынбасар итеп Ёсукай билгеләнгән» [Турсун, б. 169].

12 ноябрьдә Гани-батыр отряды шәһәр диварын шартлата, һәм партизаннар шәһәр эченә бәреп керә. Күп тә үтми, Или өлкәсенең полиция идарәсе кулга алына, мондагы әсирләр барысы да азат ителә. Алар арасында «яшь татар егете Мәргуб Исхаков та була, соңрак ул Көнчыгыш Төркестан Республикасы Милли Армиясе полковнигы, Беренче Суйдун кавалерия полкы политкомиссары, аннары Шихос полкы командиры булган. Моңа өстәп шуны да әйтик: 1923 елда Колҗа шәһәрендә дөньяга килгән Мәргуб Тимергали улы Исхаков коммунистлар хакимлеге чорында Кытай Республикасы армиясендә хезмәт итә, генерал-майор дәрәҗәсенә ирешә. Кытай Халык Республикасында генерал булган башка татар кешесе бәлки юктыр да. Узган гасырның 60нчы еллары башында М. Исхаков гаиләсе белән Советлар Союзына чыгуга ирешә. Гомеренең соңгы елларында ул Алма-Ата шәһәрендә яши, хәзер аның нәсел дәвамчылары хәзер дә шунда гомер кичерә.

Колҗа шәһәренең үзәк районнары азат ителгәч, Көнчыгыш Төркестан Республикасының төзелүе хакында игълан ителә. Президент итеп Алихан Тура Шакиров сайлана, хөкүмәт составы раслана. Мондагы халыкның күпчелеген уйгурлар тәшкил иткән. Шуңа күрә хөкүмәт составында уйгур милләте вәкилләренең күп булуы табигый хәл. Уйгурлардан соң казакъларны, татарларны, үзбәкләрне атарга кирәк. Көнчыгыш Төркестанда яшәүче барлык 12 милләтнең дә вәкилләре үзәк хакимият органнары составына кертелгән.

Америка Кушма Штатларының Өремчедәге консулы үзенең докладында мондагы халыкның 75 % ын уйгурлар, нибары биш процентын гына кытайлар тәшкил итүен, восстаниедә уйгурлар, казакълар, татарлардан тыш элеккеге акгвардиячеләр – руслар да катнашуын, башка милләтләрнең, нигездә, мөселман төркиләр икәнлеген билгеләгән. Революциянең СССР котырту нәтиҗәсе түгел, ә җирле халыкның үз гомере өчен көрәше булуын хәбәр иткән. Гоминданчыларның хәле кискенләшүне, мондагы халыкларның беркайчан да үз ирекләре белән ассимиляциягә, кытайлаштыруга риза булмаячагын ассызыклаган. «Хәрби яктан җиңелү һәм тәртипсезлекләр Советлар Союзының йогынтысын көчәйтәчәк, шуның белән Синьцзянның Кытайдан аерылуына китерергә мөмкин», – дип раслый консул [Турсун, б. 228].

Хөкүмәтнең беренче составында мәгариф министры итеп Хәбиб Фазылҗан улы Юничи тәгаенләнгән. «Азат Көнчыгыш Төркестан» (соңрак «Революцион Көнчыгыш Төркестан») газетасының баш редакторы да ул булган. Шунысы да игътибарга лаек: Хәбибнең үлеменнән соң бу вазифаны һәрвакыт татар яки уйгур халыклары вәкилләре башкарган: Хөсәен Насыйров, Әсхәт Исхаков, Фуат (Уйгур) Сайрани, Зунун Таиров, Жани Юлдашев.

Финанс министрының урынбасарлары итеп татарлардан Ваккас Миршанов һәм Фатих Аллаяри тәгаенләнгән. Ваккас Миршанов

(1885–1968) Казакъстанның Яркәнд шәһәрендә туган, Германиядә белем алган, 1930 елдан Колҗа шәһәрендә яшәгән. Синьцзянда коммунистик хакимият урнашканнан соң да районның финанс органнарында хезмәт иткән. Соңрак СССР га күчеп, Ташкентта төпләнгән. Фатих Аллаяри (1984–1966) Татарстанда туып үскән. 1920 еллар башында Колҗа шәһәренә килеп, монда зур сәүдәгәр булып танылган.

Югарыда аталган генерал Егнаров төркеме Синьцзянда гамәли эш-башкарган. Советлар Союзыннан азсанлы төркемнәр Синьцзянга килә башлаган. Революцион хәрәкәт көчәйгәннән-көчәя барган: аңа руслар, татарлар, уйгурлар, үзбәкләр, дунганнар һәм башка милләт вәкилләре кушылган. Шуны да искә алыйк: кайбер чыганаклар күрсәткәнчә, восстание уңышка ирешкән очракта, биредә Советлар Союзы белән дустанә мөнәсәбәттә булган мөстәкыйль, демократик ислам дәүләте кору күздә тотылган.

1944 елның ахырында Советлар Союзы кавалеристларыннан торган бер төркем Или өлкәсенә кертелгән. Кытай чыганакларына караганда, Исхакбәк Мунунов һәм Иван Полинов җитәкчелегендәге шушы төркем татарлардан, кыргызлардан һәм казакълардан торган, һәм Колҗага килеп, сугышларда катнашкан. 1944 елның декабреннән 1945 елның язына кадәр СССРдан Колҗага барлыгы биш отряд киткән. И.В. Сталин һәм В.М. Молотов исеменә адресланган докладта: «Яңа хөкүмәтнең үтенече нигезендә, ярдәм сыйфатында генерал Егнаров төркеме кирәкле элемтә чаралары һәм шартлату-җимерү белгечләре белән бергә җибәрелде. Синьцзянда туган яки Урта Азия халыкларыннан булган 590 кешедән гыйбарәт биш отряд восстание районына юл алды», – диелгән [Турсун, б. 257]. Шуны да әйтергә кирәк: болар регуляр Кызыл Армия отрядлары түгел, алар Ташкентта, Алма-Атада, Кыргызстанда һәм башка төбәкләрдә хәзерләнгән гаскәриләрдән торган һәм Кытайга яшерен рәвештә җибәрелгән. Димәк, бу очракта Совет Армиясенең Кытай территориясенә керүе хакында сүз алып бару дөреслеккә туры килми.

Чан Кайши хөкүмәте восстаниенең бөтен Синьцзян территориясенә таралу мөмкинлеген яхшы аңлаган. Шуңа күрә Өремчедән чыккан гаскәр белән Көнчыгыш Төркестан Республикасы хөкүмәтенә буйсынган районнарда калган солдатларның кушылуына зур игътибар бирелгән. Республика җитәкчеләре дә моны төшенгән, ләкин аларны корал һәм башка кирәк-яракларның җитешмәве тоткарлап торган. Президент Алихан Тура конкрет тәкъдимнәр әзерләгән, Совет консулы киңәше белән Совет хөкүмәтенә махсус үтенеч тә җибәрелгән.

1944 елның декабрендә В.С. Егнаров төркеме монда хәрби һәм административ эшләр буенча киңәшче вазифаларын үти башлаган. СССРның хәрби киңәшчеләре республика хезмәткәрләре белән уртак тел таба алганнар, аның бәйсезлеген тәэмин итүдә даими ярдәм күрсәтеп торганнар. Советлар Союзы ярдәме белән Хоргоста махсус хәрби мәктәп ачылган, монда КТР хөкүмәте карары нигезендә офицерлар

һәм радистлар әзерләнә башлаган. Шул ук вакытта регуляр армияне төзү мәсьәләләре дә хәл ителгән. Әлбәттә, бу уңайдан СССРдан килгән баш хәрби киңәшче генерал-майор В.С. Егнаровның да ролен ассызыклап күрсәтергә кирәк.

Восстаниенең коралллы көчләре күбесенчә җитәрлек хәрби белеме булмаган көрәшчеләрдән торган. Аларга ярдәм итү максаты белән килгән киңәшчеләр составында руслар да, башка, бигрәк тә төрки халыклар вәкилләре дә булган. Шуларның берсе – Башкортстанда туган Габит Мөҗепов (Музипов, 1907–1981) монда Али Апанди исеме белән танылган. 1920–1930 елларда ул Кыргызстанның Каракол шәһәрендә яшәгән, 1937 елда Көнчыгыш Төркестанга җибәрелгән, бер партизан отрядының разведкасын җитәкләгән, 1944–1949 елларда киңәшче сыйфатында Колҗа шәһәрендә хезмәт куйган. 1946 елда ул «Көнчыгыш Төркестанның бәйсезлеген казанудагы хезмәтләре өчен» республиканың «Бәйсезлек өчен көрәш» исемле беренче дәрәҗәле алтын ордены белән бүләкләнгән. Полковник Мөҗепов гомеренең ахырында Ош шәһәрендә (Кыргызстан) яшәгән.

1945 елның бишенче гыйнварында Республика хөкүмәте «Бәйсезлек декларациясе» кабул итә. Ул «Азатлык оешмасының» югарыда күрсәтелгән сәяси программасына бик якын. Н. Турсун фикеренчә, декларация текстын Әхмәтҗан Касими һәм Хәбиб Юничи әзерләгән. Һәрхәлдә Көнчыгыш Төркестан Республикасы эшчәнлегенең нигезенә нәкъ шушы декларация салынган.

1945 елның гыйнварында Колҗа шәһәре тирәсендәге җирләрне гоминданчылардан тулысынча азат итү өчен сугышлар дәвам иткән. Бу көрәштә шәһәрдә яшәүче кешеләр, шул исәптән хатын-кызлар да, яшүсмерләр дә актив катнашкан. Ниһаять, гоминданчылар чигенергә мәҗбүр булганнар. Беренче февральгә Или елгасы үзәнлеге (Колҗа шәһәре белән бергә) гоминданчылардан тулысынча азат ителгән. Моннан соң инде гоминдан хакимлеге Или өлкәсенә беркайчан да гаскәр җибәрмәгән.

Л.П. Берия үзенең бер докладында: «1945 елның март аена восстаниедә катнашучыларның саны 9300 гә җитте, тиздән бу санның 12 меңгәчә үсүе көтелә,– дип язган. – Аларның хәрби әзерлеге мәсьәләләре белән генерал Егнаров шөгыльләнә. Шушы районда Үзәк Кытай гоминдан хөкүмәтенең 70 меңлек армиясе торганлыгын искә алып, генерал Егнаровка восстаниечеләрне кирәкле корал белән тәэмин итәргә, җитешмәгән хәрби кадрларны әзерләргә боерык бирелде» [Турсун, б. 260]. Чынлап та, Советлар Союзыннан (җитәрлек дәрәҗәдә булмаса да) корал һәм башка кирәк-яраклар килеп торган, хәрби, офицерлар хәзерләү курслары эшләгән. Республиканың СССР белән бәйләнешләре гадәти сәүдә рәвешен алган. СССР дан килгән корал өчен республика атлар һәм сарыклар белән түләгән.

Димәк, 1944 елгы восстаниедә, аның җиңүләргә ирешүендә дә Советлар Союзының булышлыгы искиткеч зур роль уйнаган. Шуны да әйтергә кирәк: шул ук вакытта Кытайдагы Чан Кайши хөкүмәте

СССРдан һәрвакыт корал һәм башка хәрби кирәк-яраклар алып торган, Кытай Коммунистлар партиясе дә Советлар Союзының турыдан-туры ярдәменә таянган.

Ләкин СССР, Кытайда коммунистлар хакимлеге урнашкач, восстание күтәргән көчләргә ярдәм күрсәтүне туктаткан. Бу – Көнчыгыш Төркестан территориясен Кытайның яңа хакимнәре кулына тапшыруны аңлаткан. СССР җитәкчеләренең әлеге гамәле халык мәнфәгатьләрен саклау максаты белән түгел, бары сәясәт мәсьәләләре белән генә аңлатыла. 1949 елда яңа хакимнәр бу восстаниенең «Өч округ революциясе», «Кытайдагы демократик революциянең бер өлеше» генә булуын таныган. Шулай итеп, биш ел дәвам иткән кораллы көрәш нибары Или, Тарбагатай һәм Алтай өлкәләренең күтәрелешенә генә кайтып калган.

Йомгаклап шуны әйтергә кирәк: татар халкы вәкилләре революцион хәрәкәттә актив катнашкан. Гадәттә бертуган агалы-энеле, аталы-уллы татарлар да революцион көрәшкә кушылганнар. Мисалга, Исхаковлар, Мөслимовлар, Юничевлар һ.б. кебек фамилияләрне искә төшерү дә җитә.

Китапта бөтен дөньяга сибелеп яшәгән татар халкының тарихы белән кызыксынучыларга бай һәм шактый нигезле материал тәкъдим итә. Шуңа күрә бүген Н. Турсунның хезмәте Төркиядә һәм Казакъстанда инде нәшер ителгән һәм инглизчәдән рус, уйгур телләренә тәрҗемәләнеп ята.

**Әдәбият**

*Ерзин М.* Из глубин Евразии. Алматы: ТОО «Издательство Экономика». 2015. 560 с.

*Закиев М.З.* Происхождение тюрков и татар. М.: ИНСАН. 2003. 496 с.

Мы из Китая. Сборник воспоминаний. Алматы: КИЦ «АВС». 1999. 206 с.

*Турсун Н.* Уйғур умумий тарихи (7-том). Шәрқий Түркстан Җумһурийити умумий тарихи. 1-қисим (инқилап, уруш вә сәясәт). Алматы: «МИР» нәшрият өйи. 2022. 556 б.

***Хәйруллин Гриф Тимерзаһит улы,***
*педагогика фәннәре докторы,*
*«Туран» университеты профессоры*
*(Казакъстан, Алматы)*

УДК 929.52

***Исмаил Балы оглу Умудлу***

# ИДЕЛ-УРАЛ БУЕ ТАТАР МОРЗАЛАРЫ ТЕРЕГУЛОВЛАР НӘСЕЛЕ ҺӘМ АЗӘРБАЙҖАН

В статье рассматривается одна ветвь генеалогии знаменитого Волго-Уральского татарского дворянского рода Терегуловых, которая с первой половины XIX века была тесно связана с Азербайджаном, его общественной жизнью, театральной и музыкальной средой. В качестве основного документа здесь взята старинная поколенческая картина рода Терегуловых, хранившаяся в бакинской семье Султановых, подписанная главой семьи Терегуловых – отставным военным строителем Мурзой Сафаром, который жил в XIX веке в Тифлисе. Обзорное описание дополнено генеалогическими сведениями и представлено более подробно.

**Ключевые слова:** Терегуловы, Еникеевы, татары, Гаджибеков, Магомаев.

The article discusses one branch of the genealogy of the famous Volga-Ural Tatar noble family Teregulovs, who has been closely associated with Azerbaijan since the first half of the 19th century,with its social life, theatrical and musical environment. In this,an old generational painting of the Teregulov family, kept in the Bakufamily of the Sultanovs, signed by the head of the family Teregulovs retired military builder Murza Safar, who lived in the 19th century in Tiflis, is taken as the basic document. The overview description is supplemented with genealogical information and is presented in a more detail.

**Keywords:** Teregulovs, Enikeevs, Tatars, Hacibeyov, Magomaev.

### Мәсьәләнең куелышы

Гаилә тарихларын күзәткәндә, кайвакыт гаять бай интеллектуаль күренеш ачыла. Чыгышлары белән Идел-Урал буе татарларыннан булып, кан-кардәшлеккә һәм мөселманлыкка тугры Терегуловлар гаиләсе мисалында моңа без тагын бер кат инанабыз. XIX гасырның икенче яртысы – XX гасырның беренче яртысында азәрбайҗан милләтенең хәзерге этно-мәдәни йөзен формалаштыруга үзләреннән саллы өлеш керткәннәр алар. Мәгълүм булганча, бу морзалар нәселенең бер тармагы Кавказ һәм Азәрбайҗан белән тыгыз бәйләнгән, аның вәкилләре илебезнең мәдәни тормышында якты эз калдырганнар һәм биредә күренекле төрки-азәрбайҗан нәселләре белән туганлашканнар. Бу хәл үзе үк Терегуловлар шәҗәрәсе белән кызыксынуны бермә-бер арттыра. Әмма авторның 2004 елда ачык ресурсларда басылып чыккан газета мәкаләсеннән [Умудлу] һәм [ASE. Cild IX] төрле публикацияләрдәге өзек-өзек генеалогик мәгълүматлардан [ASE. Cild IX; Üzeyir Hacıbəyov Ensiklopediyası] тыш, моңарчы Терегуловлар шәҗәрәсенең азәрбайҗан тармагы турында бер генә тирәнтен тикшерену дә булмады. Гәрчә Терегуловлар нәселенең башка тармаклары, төрки дөньяда иң кызыклы нәселләрнең берсе буларак, татар

генеалогы Сәед морза Еникеев [Еникеев] тарафыннан өйрәнелгән булса да. Интеллектуаль, фәнни-техник күрсәткечләре буенча бу нәселне Россиянең башка иң күренекле фамилияләре белән бер рәткә куярга мөмкин.

Бакуда яшәүче Солтановлар гаиләсендә сакланган кәгазьләр арасында Терегуловлар шәҗәрәсе дә табыла, анда әлеге нәселнең XVI гасырдан алып XIX гасырга кадәр яшәгән вәкилләренең исемнәре, эзлеклелек саклап, аска таба кими бару тәртибендә теркәлгән. Бу мәкалә Идел-Урал буе татар морзалары Терегуловлар нәселе шәҗәрәсенең Кавказ һәм Азәрбайҗан белән бәйле тармагын тагын да тулырак өйрәнүгә үз өлешебезне кертү максаты белән язылды.

**Бәян**

Мәрхүм Алангу ханым Надир бәк кызы Солтанованың (кыз фамилиясе Гаибова, Кавказ мөфтие Гусейн әфәнде Гаибовның (1830–1917) оныгы) гаилә архивында сакланган бу документлар белән мине дустым Назим Солтанов таныштырды. 150 ел элек язылган, саргаеп беткән кәгазьләрне игътибар белән өйрәнгәннән соң, Азәрбайҗанга күпсанлы лаеклы шәхесләр биргән Терегуловлар нәселенең шәҗәрәсе турында шактый яңа мәгълүматлар билгеле булды. Әлеге иске кәгазьләр арасында очраклы рәвештә Терегуловлар шәҗәрәсенә юлыгу (аңа морза Сәфәр Богдал углы Терегулов татар телендә болай дип язып кул куйган: *«Murza Səfər Boğdal oğlu Terequlof qollum qoydum».* Идел-Урал буенда яшәгән шушы югары сословие вәкилләре – морзалар (кенәзләр) чыккан күренекле татар нәселенә карата кызыксыну тудырды һәм аларның Кавказ-Азәрбайҗан тармагына ачыклык кертү теләге уятты.

Документлар өйдә сакланган: Алангу ханымның – беренче төрки пианистка Хәдиҗә ханым Гаибованың (кыз фамилиясе Мөфтизадә (1893–1938), сәяси репрессия корбаны) әнисенең әбисе Зөләйха ханым була. Ул да бу вакытта бөтен гаиләләре белән Тифлистә яшәгән Терегуловлар нәселеннән чыккан. Еш кына без чыганакларда бу нәселнең башка вәкилләре, Үзбәк Хаҗибәков һәм Мөслим Магомаевның туганнары турында өзек-өзек хатирә-истәлекләргә юлыга идек. Әлбәттә, бу факт үзе үк документка карата миндә зур кызыксыну уятты. Иң мөһиме – алар арасында мин морзалар – Терегуловларның үзләре тарафыннан имзаланган шәҗәрәсенә (таблица рәвешендә) тап булдым.

2007 елда нәшер ителгән «Үзәер Хаҗибәков» энциклопедиясендә Терегуловлар нәселе турында кыска гына әйтеп кителә: *«Нәсел башында торган Сәфәр ага Терегулов – Идел буе татарларыннан. Егерме ел Кавказда инженерлар полкында хезмәт итеп, армиядән кайтканнан соң, С. Терегулов 1845 елда гаиләсе – хатыны, ике улы Хәсән һәм Ибраһим, кызы Фатыйма белән бергә Тифлискә күчеп китә. Хаҗибәковның каенатасы – аның кайнишләре Хәнәфи белән Алиның әтисе – Хәсән Сәфәр ага углы Терегулов (1835–1911)*

*мәгърифәтче, җәмәгать эшлеклесе булган. 1889 елда ул абыйсы Ибраһим белән берлектә Тифлистә рус-татар мәктәбе ачкан. Хәсән ага да Тифлистәге сөнни-татар (Идел буе) мәчетенә җитәкчелек итә. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: ул вакытта Кавказдагы рус армиясендә Идел буе татарларыннан булган шактый күпсанлы солдат һәм офицерлар хезмәт иткән. Аларга татар телендә гыйбадәт кыла торган мәчет кирәк булган. Моннан тыш, Тифлистә яшәгән сөнниләрнең башкалары да шушы мәчеткә йөргәннәр. Хәсән ага белән Ибраһим ага болардан тыш хәйрия эшчәнлеге белән дә шөгыльләнгәннәр»* [Üzeyir Hacıbəyov Ensiklopediyası, s.200].

Әмма минем кулыма төшкән генеалогик документта күп нәрсәләргә ачыклык кертәчәк мәгълүматлар тупланган иде. Югыйсә ул нәсел башы Сәфәр морза Терегуловтан башланып, тифлисле **Сәфәр морза Терегуловка** кадәр язмаларны үз эченә алган шәҗәрә генә кебек. Бу документта Сәфәр морзаның, төрки традиция буенча, «җиде буынга кадәр» бабалары саналган: Сәфәр морза Терегуловның улы Ибраһим, Ибраһимнан Нугай бәк туган. Нугай бәктән – улы Бигай, Бигайдан – улы Мансур, Мансурдан – Багдал, Багдалдан – Тифлистә хезмәт иткән Сәфәр. Шунысын да ассызыклап китик: Сәфәр морзадан Багдалга кадәр һәр буынны бердәнбер ир бала дәвам иткән. Бары тик соңгысы – Сәфәр аганың гына (хәрби хезмәткәр) ике улы (Хәсән һәм Ибраһим) булган. Аерым билгеләп үтәргә телим: татар аксөякләренең югары катлавы булган «морзалар» бездә югары сословие кешесен белдергән «мирза» сүзе (*«төрки-татар дипломатиясе»* буенча (Мирза Казимбәк)) белән бер үк мәгънәгә ия, һәм бу титул гарәп телендәге «мир» яки «әмир»дән килеп чыккан. Мирза Казимбәк язганча, рус хезмәтенә күчкән татар морзалары титуллары белән кенәзләргә тиңләштерелгән [Kazım Bəy, s. 218]. Күрүебезчә, Кавказда Сәфәр морза үзе дә, аның ике улы Хәсән белән Ибраһим да җирле мөселман дворяннары кебек *ага* (бәккә тиң) титулын йөрткәннәр.

Әлеге шәҗәрәдә Сәфәр морзаның атасының исеме – Богдал / Багдал да игътибарны җәлеп итә. Күрәсең, татарларны көчләп чукындыру чорында төрки-татарлар арасында популяр булган *Тәрбирде* (Тәңребирде, Тариверди,) дигән исем *Богдал*га, ягъни «Алла бирде»гә әйләнгән булса кирәк.

Нәсел башында торган Сәфәр морза Терегуловның фамилиясе азәрбайҗанча *Тәңрекулиев*, әмма кайбер көньяк сөйләшләрдә шулай ук *Тәр-гулу* варианты да очрый, тагын берсе бар: *Тәңребирде (Танрыверди) / Тарверди*.

Сәфәр Терегулов Мәскәүдә туган, аның гаиләсе шәһәр үзәгендә, Татар бистәсендә яшәгән. Татарларны көчләп христианлаштыруга карамастан, алар ислам диненә тугры калганнар [Хамидуллин]. Кавказда алар хәрби-төзелеш отряды составында булганнар. Төньяк Кавказда да да, Көньяк Кавказда да да алар, башлыча, күперләр төзегәннәр, кайчакта искеләрен яңартканнар. Сәфәр морзаның балалары

Владикавказда туган. Хәрби хезмәттән соң ул даими яшәү урыны итеп нәкъ менә Тифлисне сайлаган, чөнки ул вакытта инде биредә Идел буе татарлары җәмгыяте оешкан. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: 1832–1840 елларда Казан татары Таҗеддин Мостафин бөтен Кавказ мөфтие булып торган. Бу өммәт өчен гыйбадәт кылуны татар телендә үткәрә торган мәчет кирәк булганлыктан, кайбер мәгълүматларга караганда, шәһәрнең электә җимерелгән сөнниләр мәчетен нәкъ менә Сәфәр морза торгызган [Хамидуллин].

Патша дәвере Кавказ арты мөселман диния нәзарәтенең (сөнни юнәлеш өйрәтмәсе) архив фондларында Тифлис мәчетендәге мәхәллә кешеләренең рухи тормышын чагылдырган күп кенә материаллар саклана. Әлеге мөселманнарның күбесе Идел буе татарларыннан чыккан. Нәзарәт әгъзалары составындагы дин әһелләре арасында да Идел буе татарлары булган. Кайбер мәгълүматларга караганда, Сәфәр морза Терегулов бу мәчетнең имам-хатыйбы вазифаларын башкарган һәм шәһәр халкы арасында зур хөрмәт казанган. Ул шушы мәчет каршындагы мәдрәсәдә укыткан, аның күп кенә шәкертләре соңыннан хәрби уку йортларына укырга кергән. Шәкертләр исемлегеннән күренгәнчә, бу мәдрәсәдә шәһәрдән генә түгел, ә бөтен Кавказдан җыелган егетләр укыган. Моннан тыш, шул заман тәртипләре буенча, бу мәчеткә җәмәгать намазына Тифлиснең башка мөселман-сөнниләре дә йөри торган булган. Вакытлар узу белән, Тифлискә, һ.б. шәһәрләргә Идел-Урал буеннан килеп төпләнгән татарлар Көньяк Кавказ мөселманнары тирәсенә тупланганнар. Бер генә факт: чыгышы белән Оренбург морзаларына барып тоташкан Тәүхеддин Нурпай углы Мамлеев (1850– ?), 1875 елда Елисаветполь (Гәнҗә) губернасы Казакъ өязе Сәлахлы авылында рус-татар мәктәбе ача һәм дүрт ел шунда укыта [Umudlu, s. 155]. Төбәктә шактый абруйлы кеше санала. Сәлахлы авылы шәкертләреннән кайберәүләр, ә алар тулы бер бер плеяда хасил итә, соңрак Кавказ мөселманнары арасында мәгърифәт таратуда сизелерлек роль уйнаганнар. 1980 еллар ахырына кадәр Идел буе татарлары общинасы (гәрчә аз санлы булса да) күпмилләтле Тифлистә яшәвен дәвам итә; әлеге сөнниләр мәчете җирле татарларның этник-социаль тәңгәллеген саклауда гаять мөһим роль уйный.

Татар авторлары Терегуловларның халкыбыз арасында (һәм күпмедер дәрәҗәдә бөтен Россиядә) бик атаклы нәсел булуы хакында бердәм фикерне хуплыйлар [Хамидуллин]. Татар генеалогы Сәид морза Еникеев фикерләренә таянсак, татар морзалары Терегуловларның вәкилләре Еникей морза Кульдяшевның нәсел дәвамчылары булып торалар (аның улы Терегул аша) [Еникеев, s. 302–303]. Ягъни Терегуловлар Еникеевләрнең бер тармагын тәшкил итә, һәм Тифлистә яшәгән Сәфәр морза Терегуловның шәҗәрәсенә караганда, нәсел башлыгына кадәр тагын 3 буын өстәлә: Еники морза – Терегул – Тәрбирде (Тенәш) – Сәфәр морза. Шулай итеп, без Терегуловлар нәселенең 10 нчы буынын да күрәбез.

Нәсел Алтын Урда ханы Биханнан башланып китә. Еникеев мәгълүматларына караганда, нәсел башы Еники морза (Янәки бәк) Кульдяшев (Янәки бәк – Кульдяш бәкнең улы, Кульдяш бәк, үз чиратында, – Биханның оныгы) чама белән XVI гасыр башында Мәскәү дәүләтенә вассаллык бәйлелегендә торган Темников кенәзлегендә хезмәт иткән. Алдагы гасырларда аның өлкән улы Терегулның нәсел дәвамчылары Тамбов, Саратов һәм Оренбург губерналарында яшәгән.

XIX гасыр Тифлисенә әйләнеп кайтыйк. Аталарының эшен уллары дәвам итә. Тифлиснең мактаулы гражданины (мөселман агалары өчен шундый категория булган) Хәсән ага Сәфәр ага углы Терегулов (Владикавказда туган) сөнниләр мәчетенең имам-хатыйбы да булган. 1880 елда абыйлы-энеле Хәсән ага белән Ибраһим ага Тифлистә рус-татар мәктәбе ачалар, анда малайлар һәм кызлар бергә укый, ә бу – Кавказ мөселманнары даирәсендә гадәти булмаган күренеш. Хәсән ага Фәхретдин Акмаевның кызы – Раббия ханым Акмаевага өйләнгән булган; ул да Мәскәүнең татар бистәсеннән [Хамидуллин]. Аларның күп балалы гаиләсендә өч малай һәм биш кыз үскән: Мәмәд-Хәнәфи, Рамазан, Али, Бәдигыльҗамал, Хөсниҗамал, Мәликә, Әминә, Мәрьям.

Аларның кыскача биографияләренә тукталып китик.

**Мәмәд-Хәнәфи (Хәнәфи) Хәсән углы Терегулов** (7.11.1877, Тифлис – 18.12.1942, Баку) җырчы, театр эшлеклесе, Хезмәт герое (1927) булган. Кавказ арты укытучылар семинариясен тәмамлаганнан соң (1899), Иреван губернасының Аштарак авылында, шулай ук Бакуда мөгаллимлек иткән. 1917 елда ул Идел буе татарларының Бакудагы «Берлек» эшчеләр оешмасын җитәкләгән. 1918 елда Азәрбайҗан башкаласында большевик әрмәннәр отрядлары тарафыннан оештырылган канлы март суешыннан соң, башка сәяси эшлеклеләр белән бергә Хәнәфи дә Әстерхан шәһәренә күчеп киткән. Анда ул атаман Дутовның Уралдагы һөҗүмен бастыруда катнашкан. Бакуга 1920 елдан соң гына әйләнеп кайткан.

Аннары, 1942 елга кадәр, төрле җаваплы урыннарда эшләгән. Башта ул Азәрбайҗан БКП ҮКда бүлек мөдире итеп билгеләнгән, аннары – Аз.ССР Халык Комиссарлары Советында Сәнгать идарәсе башлыгы вазифаларын үтәгән. Беркадәр вакыт Матбугат буенча Баш идарә начальнигы, ниһаять, Азәрбайҗан ССРның фото-кино идарәсе оештыручысы һәм җитәкчесе булган. Ә үзенең җырчылык талантын ул Үзәер Хаҗибәков һәм Мөслим Магомаевның опера куелышларында төп башкаручыларның берсе буларак гамәлгә ашырган. Моннан тыш Хәнәфи Терегулов – опера хорын оештыручыларның берсе [ASE. Cild IX, s. 205; Üzeyir Hacıbəyov Ensiklopediyası, s. 200].

Хәнәфи Терегулов Любовь Берковна Ханинага өйләнгән. Улы Давид Терегулов (1912–1982) һәм кызы Тамара Терегулова (1917–1988) Мәскәүдә яшәгәннәр. Давид Терегулов инженер-нефтьче белгечлеге алып, озак еллар СССР Дәүләт планы бүлеге җитәкчесе булып эшләгән, күпмедер вакыт АКШта дипломатик хезмәт үтәгән. Аның шулай

ук музыка белеме дә булган. Давид Терегуловның улы – Евгений (1950–2011), кызлары – Татьяна һәм Тамара.

**Тамара Хәнәфи кызы Терегулова** Азәрбайҗан дәүләт консерваториясен фортепиано классы буенча тәмамлаган. 1945 елда, укуын гел «бишле» билгеләренә генә тәмамлап, шунда ук Казан дәүләт консерваториясе ректоры, композитор Нәҗип Җиһанов чакыруы буенча Татарстанга киткән. 1966 елга кадәр Казан консерваториясенең фортепиано факультетында укыткан, ә 1966–1974 елларда Ерак Көнчыгыш сәнгать институтында шул ук вазифаны башкарган. Казанда дөнья куйган. Аның Наталья исемле кызы булган.

Хәнәфинең абыйсы **Рамазан Терегулов** турында без бик аз беләбез. Шунысы бәхәссез: аның кызы – Азәрбайҗанның атказанган артисткасы **Алия Рамазан кызы Терегулова** (1913–1968), Бакуда югары музыкаль белем алып, Музыкаль комедия театрында эшләгән. Филармония, Яшь тамашачы театры сәхнәләрендә чыгыш ясаган. 1955 елда Мәскәүгә киткән, Вахтангов исемендәге театрда хезмәт куйган. Гомеренең соңгы елларын Мәскәүдә уздырган һәм шунда вафат булган.

«Үзәер Хаҗибәков» энциклопедиясендә **Али Хәсән углы Терегулов** (1883–1950) турында түбәндәге мәгълүматлар бар: педагог, җәмәгать эшлеклесе, Үзәер Хаҗибәковның иң якын дусларыннан берсе. Кавказ арты укытучылар семинариясендә (Гори шәһәре) башланган танышлык көчле дуслыкка әверелгән, ә аннары туганлык бәйләнешләре белән дә ныгытылган. Семинарияне тәмамлаганнан соң Али Хәсән углы Терегулов укытучылык эше белән шөгыльләнгән, ә соңрак Бакуга күченеп киткән, «Бертуган Хаҗибәковлар» труппасына кергән. «Ләйлә һәм Мәҗнүн» операсының премьерасында аңа мактаулы беренче скрипка роле бирелгән [Üzeyir Hacıbəyov Ensiklopediyası, s. 200].

**Бәдигыльҗамал** (бу гаҗәеп матур хатын-кыз исеменең азәрбайҗанча версиясе – Багдагөл) 1910 елда булачак композитор Абдулмөслим (Мөслим) Магомаевка (1885–1937) кияүгә чыккан. Аларның ике баласы туган, Җамаледдин (1910–1977) – инженер һәм дәүләт эшлеклесе; Мөхәммәд (Магомед) – театр рәссамы, мультипликатор, СССРның Халык артисты Мөслим Магомаевның әтисе, 1945 елның апрелендә Берлинда һәлак булган. Бәдигыльҗамал ханым 1967 елда вафат.

**Хөснижамал Хәсән кызы Терегулова** (1901–1999) – сәнгать белгече, Азәрбайҗан опера һәм балет театры директоры һәм башкалада Үзәер Хаҗибәйли музей-йортының беренче директоры булган мәрхүм Рамазан Хәмзәт углы Хәлиловның әнисе [Üzeyir Hacıbəyov Ensiklopediyası, s. 108].

**Мәликә Хәсән кызы Терегулова** (1893–1966) 1910 елда булачак композитор Үзәер Хаҗибәйлигә (1885–1948) кияүгә чыга. Мәликә Терегулова Тифлистә Кенәз хатыны Ольга Федоровна исемендәге Беренче хатын-кызлар гимназиясенең 4 нче сыйныфын

тәмамлый. 1909 елдан башлап Бакудагы 10 нчы, 7 нче, 8 нче һәм 4 нче рус-татар мәктәпләрендә татар һәм азәрбайҗан телләрен укыта.

1920 елдан соң, Көнчыгыш консерватория гамәлгә куелгач, әлеге югары уку йортына укырга керә һәм музыка теориясен үзләштерә. Ире үлгәч, Бакуда – «Аршин мал алан» музыкаль комедиясе һәм Мәскәүдә «Күруглы» операсы клавирларын бастыру өстендә күп эшли [Üzeyir Hacıbəyov Ensiklopediyası, s. 80; Səfərov].

Аларның балалары булмый. Үзәер аганың этисез калган оныгы Солтан Исмәгыйль углы Хаҗибәковны (1919–1974) 10 яшеннән тәрбияләп үстерәләр. Ул киләчәктә композитор, дирижёр, СССРның Халык артисты була [Üzeyir Hacıbəyov Ensiklopediyası, s. 80].

**Әминә Хәсән кызы Терегулова** 1908 елда «Ниҗат» хәйрия җәмгыятенең Баку хатын-кызлар бүлекчәсен гамәлгә куючыларның берсе була. Ул Кавказ арты укытучылар семинариясен тәмамлаган (1905), 1920 елдан соң Азәрбайҗанда культура революциясен оештыручыларның берсе булган, репрессияләнгән Пәнаһ Алекпер углы Гасыймовка (1881–1937) кияүгә чыккан [Üzeyir Hacıbəyov Ensiklopediyası, s. 130]. Аларның улы Һидаять, кызлары Адилә һәм Нигяр дөньяга килгән.

**Мәрьям Хәсән кызы Терегулова** (1897–1954) Тифлис хатын-кызлар гимназиясен тәмамлаганнан соң (1911) Бакуга килгән һәм гомеренең ахырына кадәр биредә төрле мәктәпләрдә укыткан. Губад Абдулла углы Гасыймов (1896–1993) белән гаилә корып җибәргәннәр. Губад Гасыймов тарих буенча фәлсәфә докторы, музыка буенча музыка тарихчысы, «Үзәер Хаҗибәков» (1949) һәм «Үзәер Хаҗибәков. Библиография» (1985) монографияләре авторы буларак танылган. Бөек Үзәер бәкнең әдәби һәм фәнни мирасын җыю, төзү һәм бастыру буенча күп эшләгән [Üzeyir Hacıbəyov Ensiklopediyası, s. 129].

Ибраһим Сәфәр углы Терегуловның ике кызы булган: Рәхилә һәм Зөләйха ханымнар.

**Рәхилә Ибраһим кызы Терегулова** педагогик белем алган. Бакуга килгәннән соң шушы өлкәдә эшләгән һәм язмышын 1906 елдан башлап «Ниҗат» хәйрия җәмгыяте эшендә актив катнашкан Мәхти бәк Хаҗибабабәков (1871–1925) белән бәйләгән. Әлеге оешма демократик карашлы төрки зыялыларны берләштереп торган.

Рәхилә ханым да бу эшкә кушылып киткән, Бакуда «Ниҗат» ширкәте каршындагы 3 нче хатын-кызлар рус-татар мәктәбенә җитәкчелек иткән. 1914 елдан ул инде «Баку мөселман хатын-кызлар хәйрия җәмгыяте» эшендә рәис урынбасары сыйфатында актив катнаша башлаган. Мәхти бәк Шамахы дворяннарыннан чыгып, үз ватанының патриоты булган.1918 елның 28 маендагы Азәрбайҗанның Бәйсезлеге Декларациясен ул имзалаган.

**Зөләйха Ибраһим кызы** Кавказ артының мәрхүм мөфтие Мәмәд әфәнде Мөфтизадәнең (1821–1872) улы Осман бәккә (1853–1909) кияүгә чыккан. Ул сарай киңәшчесе, ызанлау мәсьәләләре буенча чиновник дәрәҗәсенә ирешкән. Бу никахтан Мәмәд бәк белән Хәдиҗә

ханым туган. Мәмәд бәк 1918 елда Төркиягә күчеп киткән, шуннан соң, билгесез сәбәпләр аркасында, аның белән бәйләнеш өзелгән. Алда әйтелгәнчә, Хәдиҗә ханым Мөфтизадә соңрак мөфти булган Гусейн әфәнде Гаибовның улы – элемтә юллары инженеры Надир бәкнең (1874–1941) хатыны булган [Umudlu, s. 626].

**Фатма Сәфәр кызы Терегулова** Владикавказда туган, шунда ук кызлар гимназиясен тәмамлаган һәм авыл мәктәбендә укыткан. Беренче бөтендөнья сугышы чорында ул Тифлистә Мөселман хатын-кызлар җәмгыяте тарафыннан оештырылган ятимнәр йортын җитәкләгән. 1922 елдан Баку хатын-кызлар семинариясендә тәрбияче хезмәтен башкарган. Соңыннан 1936 елга кадәр Бакуда Хатын-кызлар клубы каршындагы балалар бакчасында мөдирлек иткән.

Шул рәвешле, Терегуловлар нәселенең азәрбайҗан тармагын мөмкин кадәр тулы ачыкланды дип санарга мөмкин.

**Әдәбият**

ASE. Cild IX. Bakı: 1986.

*Kazım Bəy, Mirzə*. Müridizm və Şamil. Bab və babilər. Uyğurlar / tərcümə – İsmayıl Umudlu. Bakı: Hədəf Nəşrləri, 2015. 432 s.

*Səfərov, Rafiq*. Pedaqoq, maarifçi, musiqişünas. Dahi bəstəkarın həyat yoldaşı Məleykə xanım Hacıbəyovanın bioqrafiyasından bəzi qeydlər // «Azərbaycan» qəzeti. 2020. 7 mart. S. 4.

*Umudlu, İsmayıl.* Salahlı eli. Etnoqrafik araşdırma/ İsmayıl Umudlu. Bakı: Apostroff, 2011. 912 s.

Üzeyir Hacıbəyov Ensiklopediyası. Bakı: ŞƏRQ-QƏRB, 2007. 262 s.

*Еникеев, Саид Ханафиевич.* Очерк истории татарского. Уфа: Гилем, 2007.

*Умудлу, И.Б.* Татарский род Терегуловых. И о том, как они породнились с Азербайджаном // Зеркало (Баку). 176 (1921), приложения «История». № 1. 2004. 11 сент.

*Хамидуллин, Лирон.* След татарских мурз на Кавказе // Идель. URL: idel-tat.ru (мөрәҗәгать көне: 10.08.2020).

***Исмаил Балы оглу Умудлу,***
*Азәрбайҗан Милли Фәннәр академиясе Археология, Этнография һәм Антропология институтының тарихи этнография бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 94(470.57)

***А.Ә. Зиннәтуллина***

# МӘРЬЯМ АКЧУРИНА-СОЛТАНОВА
# ҺӘМ «УФА МӨСЕЛМАН ХАНЫМНАР ҖӘМГЫЯТЕ»

В статье дается оценка благотворительной деятельности Марьям Акчуриной, дочери известного симбирского купца, фабриканта и мецената Тимербулата Курамшевича Акчурина и жена старшего сына пятого муфтия Оренбургского магометанского духовного собрания Мухамедьяра Султанова Арслангали. Особое внимание уделяется истории мусульманских благотворительных обществ г. Уфы, в деятельности которых супруги принимали активное участие, в частности, Уфимского мусульманского дамского общества, в котором М. Акчурина была учредительницей и председательницей. Источниками исследования послужили материалы дореволюционной периодической печати, устав и отчеты обществ за разные года и воспоминания современников.
**Ключевые слова:** Акчурины, благотворительная деятельность, мусульманское дамское общества, приют, Уфа, школы для девочек.

The article gives an assessment of the charitable activities of Maryam Akchurina. She is the daughter of the famous Simbirsk merchant, manufacturer and philanthropist Timerbulat Kuramshevich Akchurin and the wife of the eldest son of the fifth mufti of the Orenburg Mohammedan Spiritual Assembly Mukhamedyar Sultanov Arslangali. Special attention is paid to the history of Muslim charitable societies in Ufa, in which the spouses took an active part, in particular, the Ufa Muslim Ladies' Society, in which M.Akchurina was the founder and chairman. The sources of the research were the materials of the pre-revolutionary periodical press, the charter and reports of societies for different years and the memoirs of contemporaries.
**Keywords:** Akchurins, charity, muslim women society, shelter, Ufa, schools for girls.

Татар халкы тарихын Апанаевлар, Хөсәеновлар, Рәмиевлар, Сәйдәшевләр кебек бөтен төрки-мөселман дөньясына танылган мәшһүр нәселләрдән башка күз алдына да китереп булмый. Әлеге исемлектә Сембер губернасы сәнәгатьчеләре, сәүдәгәр һәм эшмәкәрләре, җәмәгать эшлеклеләре, милләтнең мәдәни, дини һәм иҗтимагый тормышында тирән эз калдырган Акчуриннар династиясе аерым урын алып тора. Нәселнең һәрбер вәкиле татар милләтенең алга китүенә үзенең өлешен кертергә тырышкан. Алар хәйриячелек белән аеруча күп шөгыльләнгәннәр. Заманында Акчуриннар иганәсенә мәчетләр төзелгән, мәктәп-мәдрәсәләр салынган, китапханә-кыйраәтханәләр булдырылган, сугыш елларында авыру һәм яралы солдатлар өчен шифаханәләр оештырылган, мохтаҗлар өчен бушлай ашханәләр ачылган. Әлбәттә, нәселнең хатын-кызлары да мондый игелекле эшләрдән читтә калмаганнар.

Бу мәкаләдә сүз әлеге күптармаклы нәселнең бер әгъзасы – Сембер губернасы Гурьевка һәм Самайкино авылларындагы постау фабрикалары хуҗасы, Сембер шәһәре Думасы гласные, атаклы сәүдәгәр Тимербулат Курамша улы Акчуринның кызы Мәрьям Акчурина турында барачак. Бу ханым – Оренбург мөселман Диния нәзарәте мөфтие Мөхәммәдьяр Солтановның олы улы Арслангали Солтановның хатыны, шул сәбәпле киң җәмәгатьчелектә ул күбрәк Мәрьям Солтанова исеме белән билгеле.

Мәрьям Тимербулат кызы Акчурина 1859 елның 15 октябрендә дөньяга килә. Ул тумыштан ук акыллы, зирәк һәм сәләтле кыз була, кечкенәдән рус һәм төрек телләрен яхшы белә, матур һәм фәнни әдәбият белән кызыксына, мөгаллимә булырга хыяллана. Казанда хатын-кызлар гимназиясен тәмамлаганнан соң, Арслангали Солтановка кияүгә чыга һәм гомеренең күп өлешен белем-мәгърифәт тарату өлкәсендә хезмәт куюга багышлый.

Тарихка күз салсак, мәктәп-мәдрәсәләр төп ике шарт үтәлгәндә генә яши алганнар. Беренчедән, балаларга гыйлем бирә алырлык югары аң-белемле имам-мөдәррисләр булганда, икенчедән, укымышлы, динле байлар, иганәчеләр яки хәлле халык тарафыннан матди яктан тәэмин ителгәндә.

Татарлар арасында хәйриячелек хәрәкәте XVIII гасырда башланып китә һәм XIX гасыр ахыры – XX гасыр башларында үзенең иң югары ноктасына күтәрелә. Икътисади яктан ныклап аякка баскан татар сәүдәгәрләре һәм эшкуарлары үз керемнәрен мәгариф өлкәсен заман таләпләре дәрәҗәсенә күтәрү максатына юнәлтә башлыйлар.

Кечкенәдән дини йолалар нигезендә тәрбияләнгән, гаиләдә кешелеклелек, мәрхәмәтлелек, игелек кылуның матур үрнәкләрен күреп үскән Мәрьям ханым да мохтаҗларга, фәкыйрьләргә һәм ятимнәргә булышу эшенә керешеп китә. Алар ире белән 1898 елның 20 мартында ачылган «Уфа шәһәрендәге фәкыйрь мөселманнарга ярдәм җәмгыяте»нең («Попечительство о бедных мусульманах г. Уфы») хакыйкый әгъзалары булып, аңа матди ярдәм күрсәтеп торалар, Уфа ятимханәсенә һәрдаим булышалар. Ятимханәнең дин дәресләре мөгаллимәсе Заһирә Байчурина сүзләре буенча, 1908 елда гына Мәрьям ханым ятимханәдә укучы 48 мөселман кызына дин дәресләре өчен барлык кирәкле әсбапларны алып бирә [Байчурина]. Балалар укытырга хыялланган хәйрияче ханым үз ярдәменең күпчелек өлешен мөселман хатын-кызларына тәрбия һәм белем бирү өлкәсенә юнәлдерергә тырышкан. Мәсәлән, бертуган Яһудиннар тарафыннан ачылган кызлар мәктәбе идарәсен үз өстенә алып, оештыру эшләре белән шөгыльләнгән, мөгаллимәләр билгеләгән. Шулай итеп, йөздән артык кыз белем алу мөмкинлегенә ия булган [Кызлар].

Мәрьям Акчуринаның хәйриячелек өлкәсендә күрсәткән иң мәшһүр һәм игътибарга лаеклы эшләренең берсе – мөселман хатын-кызларының Россиядә беренче хәйрия җәмгыятен оештыруда актив катнашуы һәм аның рәисәсе булуыдыр, мөгаен.

XIX гасырның икенче яртысында Россия күләмендәге социаль-икътисади үзгәрешләр татар хатын-кызларына да зур йогынты ясый. Алар җәмгыятьнең төрле өлкәләрендә үзләрен сынап карарга омтыла башлыйлар. Моңарчы ирләре күләгәсендә яшәргә күнеккән, нигездә, гаилә мәшәкатьләре белән генә мәшгуль туташ һәм ханымнар акрынлап иҗтимагый тормышка тартыла.

Татар хатын-кызларының иҗтимагый тормышка кереп китүләренең янә бер юлы – хәйрия җәмгыятьләре оештыру. Россия җирлегендә мөселман хатын-кызларының хәйрия җәмгыятьләре XX гасырның беренче унъеллыгында оеша башлаган. Тәүге җәмгыятьләр хатын-кызларга аң-белем тарату юлында ярдәм итүне үзләренең төп максатлары итеп куйганнар. Беренче бөтендөнья сугышы мөселман хатын-кызларының иҗтимагый тормышта тагын да активлашуларына этәргеч биргән. Күп кенә төбәкләрдә хатын-кызлар тырышлыгы белән яраланган сугышчыларга һәм аларның гаиләләренә ярдәм күрсәтү оешмалары төзелгән. Хәйрия җәмгыятьләрен тирәннән өйрәнгән галим Җ.С. Миңнуллин исәпләвенчә, сугыш башланганчы Россиядә нибары 6 мөселман хатын-кызлары оешмасы булса, 1917 елның февраленә аларның саны 19 га, ә шул елның октябренә инде 61 гә җиткән [Миннуллин, 2007, с.110–126].

Мәгълүм булганча, мөселман хатын-кызларының Россиядә беренче хәйрия җәмгыяте Уфада оештырыла һәм 1907 елның 12 декабрендә «Уфа мөселман ханымнары җәмгыяте» исеме белән Уфа губернасының җәмгыятьләр һәм берлекләр реестрына теркәлә [Устав, с. 1]. Җәмгыятьне оештыру нияте 1907 елның язында, шәһәрдәге кызлар мәктәпләренең берсендә чыгарылыш имтиханнары барганда туа. Бу җәмгыятьне төзү эшендә Мәрьям Солтанова, Маһипәрваз Шаһгалиева, Суфиябикә Җантурина, Суфия Солтанова актив катнашалар, оешманың уставын төзү һәм аны кирәкле дәүләт органнарына җиткерү юлында ханымнарга ирләрнең дә, төгәлрәк әйткәндә, Сәлимгәрәй Җантурин, Арслангали Солтанов, Искәндәр Солтанов, Сабир хәзрәт Хәсәниләрнең дә зур ярдәме тия [Мөслимәләр].

Устав буенча җәмгыять кыз балалар өчен төрле типтагы мәктәпләр ачуны, укучы һәм укытучыларга матди ярдәм күрсәтүне, китапханәләр һәм уку заллары булдыруны, хатын-кызларга аң-белем тарату юлында төрле әдәби кичәләр, лекцияләр, укулар үткәрүне, хатын-кызлар өчен шифаханәләр, дәвалау-тикшерену үзәкләре (медпунктлар), ятимханәләр ачуны максат итеп куя.

Җәмгыятьне ачу тантанасы 1908 елның 25 гыйнварында була. Мәҗлестә алдынгы карашлы дин әһелләре, мөгаллимәләр, җәмәгать эшлеклеләре тарафыннан нотыклар сөйләнә, котлау сүзләре әйтелә, әгъзалык акчалары җыела. Соңыннан идарәгә рәисә сайлана. Бу җаваплы эш Мәрьям ханым Солтановага тапшырыла. 27 гыйнварда Мәрьям Солтанова йортында идарә әгъзалары сайлау җыелышы уза. Шулай итеп, «Уфа ханымнар җәмгыяте»нең эшчәнлеге башланып китә.

Бераз алга китеп шунысын да әйтеп үтәргә кирәк: Мәрьям ханым җәмгыятьнең эшчәнлеге туктатылганчы, ягъни илнең сәяси һәм икътисади тормышында кискен борылыш ясаган Октябрь революциясенә кадәр, шушы вазифаны башкара. Матбугат битләрендә «җәмгыять рәисәсе урынына» дигән язу астында Фатима Алкина, Зөләйха Терегулова, Фатима Басимова фамилияләрен дә очратырга мөмкин [Хисап, Уфа мөселман...]. Ләкин аларны, Мәрьям ханым төрле сәбәпләр аркасында үз эшләрен үти алмаган вакытларда, вазифаны вакытлыча башкаручылар буларак кабул итәргә кирәк. Мәсәлән, Мәрьям ханым хаҗ сәфәрендә вакытта.

Җәмгыятьнең төп максаты кыз балаларга аң-белем тарату булганлыктан, аның әгъзалары бу мәсьәләгә зур игътибар биргәннәр. 1911 елда җәмгыять карамагында 542 укучысы булган – алты, 1912 елда 430 укучы белән – биш, ә 1914 елда 517 укучы белән җиде башлангыч мәктәп эшләгән. Барлык мәктәпләрдә дә гомуми фәннәр белән беррәттән кул эшләре дәресләре дә укытылган. Бу дәресләрдә кызлар бәйләү, чигү, тегү кебек көндәлек тормышта кирәкле һөнәрләргә өйрәнгәннәр. Тиздән җәмгыять кыз балалар өчен ятимханә дә ачып җибәргән. Еллык хисапларга караганда, ятимханәдә 1911 елда – 15, 1912 елда – 16, ә 1914 елда 14 кыз тәрбияләнгән. Биредә кызларны кием-салым тегү эшенә генә өйрәтеп калмаганнар, күннән аяк киемнәре тегү күнекмәләре дә биргәннәр [Зиннатуллина, с. 216]. Әлеге чаралар җәмгыятьтән шактый зур чыгымнар таләп иткән. Әгъзалык кертемнәре, төрле чаралардан килгән акчалар, хосусый иганәләр хәйрия җәмгыятьләренең төп яшәү чыганагы булып торган.

«Уфа мөселман ханымнары җәмгыяте» уставы буенча, җәмгыять файдасына түләнә торган мәҗбүри кертемнәренең күләменә карап, әгъзалар шәрәфле, хакыйкый, ярышчы һәм хезмәткәрләргә бүленгәннәр. 300 сумнан да ким булмаган күләмдә акчалата иганә биргән яки җәмгыять файдасына әһәмиятле хезмәт күрсәткән кешеләр шәрәфле әгъза булып саналганнар. Хакыйкый әгъзалар ел саен өч сум яки бер тапкыр җәмгыять фондына 100 сумнан да ким булмаган, ә ярышчылар исә ел саен бер сумнан да ким булмаган күләмдә иганә кылырга тиеш булганнар. Үз эшчәнлекләре белән җәмгыятькә яки җәмгыятьнең хакыйкый әгъзаларына ярдәм иткән затлар хезмәткәр дип танылган [Устав, с. 8]. Җәмгыятьтә әгъза булып торган танылган татар эшкуарларының, дәүләт хезмәткәрләренең һәм дин әһелләренең хатыннары һәм кызлары, мәҗбүри түләнә торган әгъзалык акчаларыннан тыш, оешма файдасына әйберләтә дә иганә кылганнар. Иң зур иганә кылучы, әлбәттә, Мәрьям ханым Солтанова булган. Җәмгыятьнең еллык хисабыннан күренгәнчә, 1911 елда ханымнар җәмгыятендә бары бер шәрәфле әгъза була, ул да булса – Мәрьям Солтанова [Отчет, 1912, с. 2]. Әле җәмгыятьнең беренче җыелышында ук ул 100 сум акча иганә кыла. Ә инде 1911 елда җәмгыять файдасына Уфаның Спасский урамында урнашкан үз йортын, аяк белән эшли торган бер тегү машинасы, 120 аршын тукыма, бер пот бодай оны, 10 фунт ак

ипи, 2 фунт шикәр, 0,5 фунт чәй, бер пот ит һәм өч урынлы кулъюгыч биргән [Отчет, 1912, с. 10 ]. Мондый хосусый ярдәмнәр җәмгыять чыгымнарын киметергә һәм кергән керемнән нәтиҗәле файдаланырга мөмкинлек тудырган.

1908 елда Уфа шәһәре идарәсе Никольский мәйданында җәмгыять карамагына җир кишәрлеге бүлеп биргән. Бу урынга җәмгыять ике катлы таш мәктәп һәм аның янына бер катлы агач флигель салдырырга уйлаган. Агач бинада кызлар мәктәбе булса, таш бина укытучылар хәзерләү йорты булыр дип фаразланган. Шул ук елны биналарның планнары төзелеп, агач флигель торгызылган. Мәктәп Мәрьям Солтанова карамагында булып, укытырга ике мөгаллимә билгеләнгән һәм 15 сентябрьдән мәктәптә укулар да башланган. Беренче елны җәмгыятьнең кереме аз булганлыктан, таш бинаны салдыру икенче елга кадәр кичектерелеп торган [Уфада]. Әмма табылган материалларга караганда, әлеге мәктәп җәмгыять эшчәнлегенең соңгы елларына кадәр салынып бетә алмаган, күрәсең. Чөнки газета битләрендә бу мәктәпкә кагылышлы бәхәсләр берничә ел дәвамында яктыртылып килә.

Тема буенча мәгълүмат туплаганда без әлеге кызлар мәктәбен төзеп бетерү өчен ярдәм сорап язылган үтенеч кәгазенә тап булдык. Үтенеч Уфа мөселман ханымнары җәмгыяте бланкында язылган. Текстка карандаш белән бик күп төзәтүләр һәм өстәмәләр кертелгән. Мөгаен бу – үтенечнең каралама варианты булгандыр. Аның кем кулы белән язылганлыгы да билгеле түгел. Фикер сөреше һәм текстның эчтәлеге буенча әлеге хатны татар һәм рус телләрен яхшы белгән, димәк, тиешле белеме булган хатын-кыз язган дип әйтеп була. «Уфа мөселман ханымнар җәмгыяте» рәисәсенең фабрикант һәм эре сәүдәгәр кызы булуын һәм мондый эш белән күбрәк җәмгыять җитәкчеләре шөгыльләнүен исәпкә алсак, әлеге үтенеч Мәрьям ханым тарафыннан язылган, дип нәтиҗә ясый алабыз. Документның елы да билгеле түгел, ләкин эчтәлегенә карап, без аны чама белән 1912 ел дип билгеләдек. Тексттан күренгәнчә, 1911 елда мәдрәсәнең фундаменты салынган, әмма акча булмау сәбәпле эш тагын туктатылган. «Мәдрәсәне тәмам итү өчен 15 мең рублә кадәр кирәк буладыр», – диелә текстта [КСКБ].

1915 һәм 1916 елгы газета битләрендә әлеге мәктәп мәсьәләсе яңадан кузгатыла: «Салынып бетмәгән кызлар мәктәбе» дигән мәкаләдә: «Бу бәхетсез бинаның салына башлавына берничә еллар үтеп китсә дә, ул һаман шул «бетмәгән» көйгә әрәм булып ята. Аны тәмам итәр өчен 10 мең сумнар акча кирәк». Бинаны рус поплары сатып алырга сорыйлар, аның янында бер төзелеп бетмәгән чиркәү дә булып, мәктәп бинасын шуның милкенә алырга уйлыйлар, имеш, дигән хәбәрләр дә тарала [Салынып, 1916]. Димәк, бинаның күпмедер өлеше торгызылган булган. Әлбәттә, әгъзалык акчаларына гына ике катлы таш бина салып чыгу мөмкин түгел. Шуның өстенә җәмгыять әгъзаларының саны елдан-ел кими, димәк, керем дә азая. Мондый

зур чыгымнар өчен, мөгаен, эре эшмәкәрләрнең һәм сәүдәгәрләрнең төгәл шушы эш өчен иганә кылулары кирәк булгандыр. Газета битләрендәге бәхәсләр дә нәкъ акча мәсьәләсенә кайтып кала. Уфа шәһәренең бер төркем байлары мәктәпне үз хисапларына салып бетерергә телиләр, ләкин акча җәмгыять кассасы аша үтмәскә, турыдан-туры байларның үз кулларында тупланырга тиеш була. Җәмгыять идарәсе моның белән килешми, чөнки устав буенча җәмгыятькә юлланган барлык иганә керем кенәгәсендә теркәлеп барып, аның буенча тиешле оешмаларга хисап бирү таләп ителә. Җәмгыять өстеннән шикаятьләр була калса, әлеге таләпләр үтәлмәгән очракта, аны ябып кую ихтималы да була. Билгеле инде, җәмгыять идарәсе мондый адымга бармый.

Җәмгыять оешып күп тә үтми, 1910 елның октябрендә Мәрьям Солтанованың ире Арслангали вафат була[1]. Бу вакыйга да җәмгыять эшчәнлегенә күпмедер дәрәҗәдә тискәре йогынты ясагандыр. 1914 елда Беренче бөтендөнья сугышы башлану да җәмгыять өчен өстәмә чыгымнар китереп чыгара. Ничек кенә булмасын, ханымнар җәмгыятенең таш мәктәп салу хыялы тормышка ашмый кала.

Җәмгыять оешып эшли башлаган көннәрдән үк газета битләрендә аның эшчәнлеге, идарә әгъзаларының тырышлыгы мактап язылган мәкаләләр күп очрый. Әлеге җәмгыять башка шәһәр хатын-кызларына гына түгел, гомумән мөселман җәмгыятьләре алдында да үрнәк итеп күрсәтелә .

Ханымнар җәмгыятенең тагын бер игътибарга лаеклы эше – ул кыйраәтханә (китапханә) ачу. Уфада кыйраәтханә ачарга беренче мәртәбә «Уфа мөселманнар җәмгыяте» омтылып карый. Ләкин уставтагы җитешсезлекләр аркасында әлеге омтылыш тормышка ашмый. Кыйраәтханә оештыру йөкләмәсен ханымнар җәмгыяте үзләренең уставларына кертеп җибәрә һәм, шуның нигезендә, 1910 елның 3 мартында мөфти хәзрәтнең Воскресенская урамындагы йорты флигелендә китапханә оештыра. Әмма, төрле сәбәпләр аркасында, китапханәнең тантаналы ачылышы 1914 елның 23 февралендә генә була. Бу вакытта инде кыйраәтханә җәмгыятьнең үз милкендә булган Спасский урамындагы 10 нчы йортка күчерелә. Әлеге йорт, инде югарыда әйтелгәнчә, 1911 елның 16 февралендә Мәрьям Солтанова тарафыннан җәмгыятькә иганә итеп тапшырылган була [Гомдә].

Кыйраәтханә ялсыз эшли. 1914 ел башына анда 500 данә китап исәпләнә. Хатын-кызлар кыйраәтханәгә, якшәмбедән тыш, көн саен көндезге икедән дүрткә кадәр, ә ирләр көн дә кичке җидедән унга кадәр, ә якшәмбе көне буена килә алганнар.

Тантаналы ачылыштан соң кыйраәтханә озак эшләми. Беренче бөтендөнья сугышы башлану белән әлеге бинада сугышта яраланган

[1] Солтанов Арслангали Мөхәммәдъяр улы 1910 елның 18 нче октябрендә вафат була. (Мәрхүм Арслангали Солтанов // Вакыт, 1910. 4 ноябрь).

солдатлар өчен кием тегү һәм башка кирәк-яраклар хәзерләү эше башлана. Тиздән ханымнар ун кешелек лазарет та (кечерәк кенә хәрби больница) ачып җибәрәләр [Уфа хәбәрләре].

Мәрьям Солтанованың тагын бер тарихка уелып калган гамәле – ул татар хатын-кызларының мәчеттә намаз укуы өчен көрәше. Бертуганы Хөсәен Акчурин белән хаҗ кылып кайтканнан соң, Мәрьям ханым бертөркем хатын-кызлар белән Уфаның беренче мәчетенә намаз укырга бара. Аларның бу адымы кадимчеләр арасында бәхәсләр китереп чыгара. Күренекле дин һәм җәмәгать эшлеклесе Галимҗан Баруди Мәрьям ханымны яклап, хатын-кызларның бергәләп мәчеткә йөрүләренә һәм намаз укуларына дини киртәләр юклыгын билгеләп үтә [Мараш, с.165]. Күрүебезчә, Мәрьям ханым мөселман хатын-кызларының үз хокукларын һәм ирекләрен саклауны һәм яклауны да үзенең бурычы итеп куйган.

Мәрьям Акчурина-Солтанованың мөселман хатын-кызларын аң-белемле, мәгърифәтле итүгә, аларның иҗтимагый тормыштагы ролен күтәрүгә керткән өлеше санап бетергесез. Ул бөтен көчен мәгърифәт юлына юнәлтеп, «Уфа мөселман ханымнары җәмгыяте»ндә хезмәт куйган. Әлеге җәмгыятькә нигез салучыларның берсе, аның шәрәфле әгъзасы, рәисәсе һәм җәмгыять файдасына иң зур иганә кылучы һәм, гомумән, җәмгыятьнең мәгънәви һәм матди нигезен тәшкил итүче булып торган. «Уфа мөселман ханымнары җәмгыяте» – мөселман хатын-кызлары хәйрия оешмаларының Россиядәге беренче карлыгачы. Әлеге җәмгыять үрнәгендә алга таба илебезнең башка шәһәрләрендә дә хатын-кызларның хәйрия җәмгыятьләре оештырыла башлаган.

Мәрьям ханымның хәйриячелек һәм җәмәгать эшләрендә актив катнашуы, халкыбыз үсешенә күрсәткән олы хезмәте бүген дә күпләргә үрнәк булып торырлык. Без милләтебезнең Мәрьям Акчурина-Солтановалар кебек татарны тәрәккыйлек юлына этәргән асыл затларыннан үрнәк алып, алар белән горурланып яшәргә, аларның бай мирасын киләчәк буыннарга җиткерергә бурычлы.

**Әдәбият**

*Гомдә.* Уфада кыйраәтханә // Тормыш. 1914. 26 февраль.

Заһирә Байчурина. [Мөхәррир әфәнде...] // Вакыт. 1908. 7 февраль.

*Зиннатуллина А.А.* Благотворительная деятельность Уфимского мусульманского дамского общества // Гасырлар авазы = Эхо веков. 2009. № 1. С. 214–220.

КСКБ (Н.И. Лобачевский исем. фәнни китапханәнең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге). 1635-Т.

Кызлар укыту // Вакыт. 1908. 18 ноябрь.

*Мараш И.* Религиозное обновление в тюркском мире (1850–1917): пер. с турецкого. Казань: Иман, 2005. 199 с.

*Миннуллин З.С.* Этапы развития и количественная характеристика мусульманских благотворительных организаций России (XIX – начало XX в.) // Благотворительность в России. СПб., 2007. С. 108–126.

Мөслимәләр җәмгыяте // Вакыт. 1908. 5 гыйнвар.
Отчет Уфимского мусульманского дамского общества за 1911 год. Уфа, 1912. 10 с.
Салынып бетмәгән кызлар мәктәбе // Вакыт. 1916. 17 гыйнвар.
Устав Уфимского мусульманского дамского общества. Уфа, 1913. 37 с.
Уфада кызлар мәдрәсәсе // Мәгълүмат. 1908. № 18. Б. 412–413.
Уфа мөселман ханымнары җәмгыяте тарафыннан ясалган лоторея-аллегри хисабы // Тормыш. 1914. 12 ноябрь.
Уфа хәбәрләре. [Ханымнар җәмгыятенең китапханәсендә...] // Тормыш. 1914. 24 август.
Хисап // Тормыш. 1914. 29 октябрь.

***Зиннәтуллина Алсу Әнвәр кызы,***
*ТР ФА Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтының*
*Тарих һәм милли мәгариф теориясе үзәге*
*фәнни хезмәткәре*

УДК 371.214.41=512.145

**М.М. Шәкүрова**

# XIX ГАСЫР АХЫРЫ – XX ГАСЫР БАШЫ ГАЛИМНӘРЕНЕҢ ХЕЗМӘТЛӘРЕНДӘ РУС ҺӘМ ТАТАР ТЕЛЛӘРЕНӘ ӨЙРӘТҮНЕҢ ФӘННИ НИГЕЗЛӘРЕ

Хронологически разработка научных основ методики преподавания русского и татарского языков относится ко второй половине XIX и первой четверти XX века (В.В. Радлов, К.Д. Ушинский, К. Насыри, Г. Ибрагимов и др.). В этот период основное внимание сосредоточено на изучении языка, на целях и задачах, методах и формах обучения языку как родному и неродному. Автор статьи считает деятельность Каюма Насыри исходной вехой лингвистической, а впоследствии и методической науки. Его идеи оказали решающее влияние на формирование лингвометодической науки.

**Ключевые слова:** научное наследие, преподавание татарского языка, обучение грамоте на русском языке, В. Радлов, К. Ушинский, К. Насыйри, Г. Ибраһимов.

Chronologically, the development of the scientific foundations of the methods of teaching the Russian and Tatar languages dates back to the second half of the 19th and the first half of the 20th centuries (V.V. Radlov, K.D. Ushinsky, K. Nasyri, G. Ibrahimov, etc.). During this period, the main attention is focused on learning the language, on the goals and objectives, methods and forms of teaching the language as native and non-native. The initial milestone of linguistic and later methodological science, without any doubt, should be considered the activity of Kayum Nasyri. His ideas had a decisive influence on the formation of linguo-methodological science.

**Keywords:** scientific heritage, teaching the Tatar language, literacy in Russian, V.V. Radlov, K.D. Ushinsky, Kayum Nasyri, G. Ibrahimov.

Татар мәгарифе тарихында үзләренең бөтен гомерләрен, белемнәрен рус һәм татар халкының телен, тарихын өйрәнүгә, татар мәгарифен үстерүгә, татар балаларына рус телен укытуга багышлаган бер төркем галимнәр, укытучы-методистлар бар: В. Радлов, К. Ушинский, К. Насыйри, М. Корбангалиев, Р. Газизов һ.б. Җәмгыятьтәге үзгәрешләр татар телен укыту методикасының 200 елдан артык зур тарихын читләтеп үтмәде. Соңгы елларда XVIII гасыр ахыры – XX гасыр башларында телгә өйрәтү методикасына үзләреннән өлеш керткән методистларны барлау, аларның хезмәтләрен өйрәнү кирәклеге ачыкланды: И. Хәлфин, И. Гиганов, А. Троянский, М. Казимбәк, Г. Ваһапов, М. Бикчурин, Н. Ильминский, М. Мәхмүдов, М. Иванов, С. Кукляшев, В.В. Радлов, К. Насыйри һ.б. Шулар арасында татар халкы тарихы, татар мәгарифе үсешенә зур өлеш керткән мөгаллим-филолог Василий Васильевич Радлов та (1837–1918) бар. Ул – төрки телләр белеменә нигез салучыларның берсе [Кононов, 1972, с. 7–15].

Мирасы гаять зур һәм күпкырлы: диалектография һәм диалектология, лексикография һәм лексикология, төрки телләрнең чагыштырма фонетикасы һәм грамматикасы, төрки текстология, рун, уйгур һәм гарәп алфавиты белән язылган төрки язма истәлекләр, төрки фольклор, төрки этнография һәм археология, мәктәп дәреслекләре, уку китаплары. В. Радловның «Төрки халыкларның халык әдәбияты үрнәкләре» («Образцы народной литературы тюркских племен», 10 томда, СПб., 1866–1907), «Төрки телләр буенча сүзлек тәҗрибәсе» («Опыт словаря тюркских наречий», 4 томда, СПб., 1893–1911), «Төрки телләрнең чагыштырма грамматикасы. I. Фонетика» (Лейпциг, 1882–1883) кебек дөньякүләм танылган хезмәтләре бүген дә әһәмиятен югалтмаган. Ул XIX гасырның икенче яртысында татар лингвистик терминологиясе үсешенә үзеннән зур өлеш керткән [Закирова, 2011, с. 124–129].

XIX гасырның 1860 елларында бер төркем рус педагоглары (П. Редкин, К. Ушинский, А. Воронов, Д. Семенов, В. Стоюнин һ.б.) Санкт-Петербургта Педагогик җәмгыять төзиләр: искечә укыту алымнарын, тәрбия чараларын, дәреслекләрне тәнкыйтьлиләр, Россиядә грамоталылык дәрәҗәсе түбән булуны ассызыклыйлар, бигрәк тә авыл җирләре өчен белемле укытучылар әзерләү, алар өчен китапханәләр ачу турында фикерләшәләр. «Педагогик елъязмалар» дигән журнал да чыгаралар [Антология, 1990, 7]. Кызганычка каршы, 1879 елда патша хөкүмәте бу Педагогик җәмгыятьне яба.

Укырга, язарга өйрәтүче методистлар арасында галим һәм педагог, дәреслекләр һәм методик хезмәтләр авторы К. Ушинский да бар («О первоначальном преподавании русского языка»; «Руководство к преподаванию по «Родному слову»; «Родное слово» 1, 2, 3 годы; «Человек как предмет воспитания»). Әлеге хезмәтләрендә ул рус телен укытуда өч максатны билгеләгән: 1) сөйләм телен үстерү (әңгәмә ысулын кулланып, махсус күнегүләр үткәрү, күрсәтмә әсбаплар кулланып, сочинение яздыру, укучыларны иҗади эшчәнлеккә күнектерү һ.б.), 2) туган телнең байлыгын аңлы рәвештә үзләштерү, 3) грамматиканы өйрәнү. Мәсәлән, грамматикага өйрәткәндә, 15 нче дәрестә И. Крыловның «Ике ир» («Два мужика») мәсәленә нигезләнеп, сүзлек эшен башкару, сорау-җавап формасы, синтаксик, этимологик һәм орфографик анализлар ясау, төрле язма эшләр үткәрү кебек эш төрләре тәкъдим итә. К. Ушинский грамматиканы укучыларга өйрәтеп кенә калмаска чакыра, ныклы күнекмәләр булдыру турында да әйтә: *«Грамматическая правильность речи из устной и письменной есть не только знание, но и привычка, или, лучше сказать, очень сложная и обширная система мелочных навыков выражать свои мысли правильно в речи и на письме»* [Ушинский, 1949, с. 234]. Шул рәвешле, ул игътибарны телдән сөйләм һәм язма сөйләмне бергә үреп алып бару, инша яздыру, укыганны кыска һәм аңлаешлы итеп башкаларга җиткерә белүгә дә юнәлтә. К. Ушинскийның фикерләренә нигезләнеп, XX гасыр башларында чыккан татар теле дәреслекләрендә бу төр эшчәнлекләргә беренчеләрдән булып Г. Ибраһимов игътибар итә.

Ул үзенең «Татар телен ничек укытырга. Телебезнең методикасы турында бер тәҗрибә» (1916) дигән хезмәтендә балаларны ана телендә дөрес укырга һәм язарга өйрәтү, уку дәресләрен оештыру, грамматик кагыйдәләрне җиңел үзләштерү ысулларын күрсәтә, инша яздыру тәртибен аңлата [Ибраһимов, 1916, б. 78].

2021 елда Ф. Йосыпов дөньякүләм атаклы В. Радловның 10 томлык фундаменталь хезмәтләре арасыннан 4 нче томын («Образцы народной литературы тюркских племен, живущих в Южной Сибири и Дзунгарской степи. Наречия барабинцев, тарских, тобольских, тюменских татар») русчага тәрҗемә итеп, беренче тапкыр бастырып чыгарды. 912 биттән торган әлеге хезмәт себер татарларының рухи байлыгын туплаган кыйммәтле материалны үз эченә алган [Радлов, 2012, с. 400].

В. Радлов Казан гимназиясендә рус теле һәм әдәбияты укытучысы булып эшләгән. 1876 елда, татар мәктәпләрендә рус теле укытучыларын әзерләү максатыннан, Казан татар укытучылар мәктәбен ачалар. Бу эшне башлап йөрүче һәм оештыручыларның берсе булган В. Радлов мәгърифәтче К. Насыйри, Ш. Әхмәровларны укытырга чакыра [Йосыпов, 2023, б. 148].

1872–1874 елларда В. Радловның өч дәреслеге басылып чыккан: «Белек» (1872), «Грамматика русского языка, составленная для татар Восточной России» (1873), «Первая книга для чтения» (1874). В. Радловның «Белек» дәреслеге кече яшьтәге балалар өчен татар телендә язылган беренче басма уку китабы булып тора. Биредә укучыларның сөйләм телен үстерү, укырга, язарга өйрәтү күз уңында тотылган. Дәреслек алты бүлеккә бүлеп бирелгән: «Гыйбрәтләр бәяны турында», «Җәнлекләр бәяны», «Үлән минераллар бәяны», «Вакыт беләнҖир, Кояш, Айның бәяны», «Җәгърафия бәяны», «Урыс тарихыннан берничә хикәят». Бу бүлекләрдә 162 хикәя һәм фәнни-тарихи очерклар тәкъдим ителгән. В. Радловның талантлы шәкерте булган Н. Катанов та университетта төрки телләр грамматикасын, төрек-татар әдәбияты тарихын укыткан, шул телдә язылган текстларны укырга өйрәткән [Кононов, 1972, с. 8].

В. Радловны Россия Фәннәр академиясенең хакыйкый әгъзасы итеп сайлагач, 1885 елда аның урынына Казан укыту округының татар, башкорт, кыргыз мәктәпләре инспекторы итеп Шаһбазгәрәй Исмәгыйль улы Әхмәров билгеләнә. 1898 елда аның тырышлыгы белән татар мөгаллимнәренең белемен күтәрү курслары оештырыла.

XIX гасырның икенче яртысында рус-татар мәктәпләре күпләп ачыла башлый. «Кое-что о казанском мусульманстве» (1893) дигән китапның авторы («некий мусульманин») татарларга рус телен, культурасын, гореф-гадәтләрен, әдәбиятын өйрәнергә, рус халкы белән аралашырга, рус-татар мәктәпләренә балаларны курыкмыйча бирергә чакыра: *«Министерство же Народного Просвещения, по инициативе которого открывались русско-татарские школы, видя несочувствие населения, перестало открывать их вновь, предоставив татарам*

*самим заботиться о средствах к умственному просвещению и приобретению знания русского языка»* [Кое-что..., 1893, с. 14]. Тарихчылар бу «мусульманин»ның Казан татары, беренче Казан гимназиясен һәм Казан университетын тәмамлаган Шаһбазгәрәй Исмәгыйль улы Әхмәров икәнлеген исбатладылар. Ул татар мәктәпләрендә рус телен укыту методикасын эшләүгә дә күп көч куя.

Шулай итеп, XIX гасырда күпләп басылып чыккан сөйләүлекләр, үзөйрәткечләр, грамматика китаплары, сүзлекләр татар телен укыту методикасы өлкәсендә яңа фикерләр уята, укытуның эчтәлеген ачыкларга, эш алымнарын эзләргә, дөньяви уку-укыту системасына таба борылырга этәргеч ясый.

XIX гасыр – мәктәпләр, нигездә, рус телендә сөйләшүчеләр өчен дәреслекләр, үзөйрәткечләр, сөйләүлекләр язу, сүзлекләр төзү һәм тәҗрибә туплау чоры буларак тарихта билгеле (А. Троянский, М. Казимбәк, С. Кукляшев, М. Иванов, М. Бекчурин, Г. Ваһапов, Н. Ильминский, И. Кондратов, Г. Мәхмүдов, Г. Фәисханов, К. Насыйри һ.б.). Әлеге чорда татар теле Тобольск, Оренбург, Саратов, Әстерхан, Ставрополь, Симферополь гимназияләрендә укытыла. Яңа белем бирү системасы бер-берсе белән нык бәйләнгән дүрт баскычтан тора: югары – университет (һәр округта), урта – гимназия (һәр губернада), урталыкта – өязләрдәге училищелар (һәр өяздә берәр), түбән – мәхәллә (шәһәрләрдә һәм авылларда). Университет училищелар, гимназияләр, мәктәпләр ачуга, программалар, дәреслекләр эшләүгә, укытучылар әзерләү өлкәсендә зур тырышлык куя. 1804 елда Устав («Устав учебных заведений, подведомых университетам») басылып чыкканнан соң, яңа типтагы гимназияләр дә ачыла.

Габделкаюм Габденнасыйр улы Насыйров шулай ук К. Ушинскийның педагогика һәм уку-укыту методикасына караган фикерләрен дәвам иттереп, татар телен фән буларак мәктәпләрдә өйрәнү зарурлыгына басым ясый [Ханбиков, 1975, 17]. Ул 1825 елның 14 (2) февралендә элекке Казан губернасы Зөя өязе Югары Шырдан авылында укымышлы гаиләдә туган. К. Насыйри – тәрҗемәче, тарихчы, эпиграфист, тел галиме, лексикограф, педагог. Аның гыйльмимәгърифәтчелек эшчәнлеге XIX гасыр урталарыннан башлана. Ул төрле уку китаплары һәм дәреслекләр яза: «Нәхү: Русча өйрәнүче татар егетләре вә татарча өйрәнүче рус егетләре өчен тәсниф кыйлынды» (1860), «Әнмүзәҗ» (1895). Мәгърифәтче укытучы буларак, татар һәм рус телләренең грамматикаларын яхшы белә, аларны чагыштырма методка нигезләнеп аңлата: «*...Ләкин гайре телне өйрәнәсе булсаң, ул вакытта үз телеңнең кавагыйдатен белмәк зарурдыр*» («Фәвакиһел җөләса»). Әлеге дөньякүләм танылган хезмәт бүген дә әһәмиятен югалтмый. К. Насыйри – XIX гасырның икенче яртысында татар лингвистикасы үсешенә үзеннән зур өлеш керткән галим. XX гасыр башында татарларга рус телен өйрәтү барышында файдаланылган табигый, тәрҗемәи (чагыштырма), катнаш һ.б. ысулларга тирән анализ ясаган, аларга үзенең тасвирый бәяләмәсен биргән галимә

Л.З. Шакирова чагыштырма ысулның нәкъ менә К. Насыйрилар заманында ук кулланылышка керүен һәм тәкъдим ителүен искәртә [Шакирова, 2003, с. 5–6].

XIX гасырның икенче яртысында рус-татар мәктәпләренең күпләп ачыла башлавында да бөек педагогның роле бик зур. Бу чорда К. Насыйриның татар һәм рус телләрен укытуга керткән өлешен билгеләп үтәргә кирәк [Шакурова, 2010, с. 208]. «Казан шәһәрендә мөселман балалары русча укый торган мәдрәсәнең ибтидасы» дигән хезмәтендә (1871) педагог К. Насыйри үзе күргән кыенлыклар, ачлы-туклы яшәүгә дә карамастан, укучыларны берәмләп эзләп табып, ихлас татар телен өйрәтүе, татар һәм рус мәдрәсәләрендә телгә өйрәтү вакыты, баланы русчага укытуда министрлык, инспектор хәзрәтләре, әти-әниләрнең фикерләре турында бәян итә: «*Бөтен кыш буенча утыз биш малайдан ким булмады, һәм укырга-язарга вә һәм гыйльме хисапка яхшы төшенүчеләр булды*» («Казан шәһәрендә мөселман балалары русча укый торган мәдрәсәнең ибтидасы»). Духовная семинариядә татар телен укыту белән бергә рус телен дә тирәнтен өйрәнә, соңыннан булачак галим Казан университетына ирекле тыңлаучы булып керә.

1889 елда татарларны русча укырга-язарга өйрәтү өчен, К. Насыйри «Кавагыйде кыйраәт русия» («Русская азбука») дигән китап яза. 24 битле бу әлифба, 50 дәрескә бүлеп, рус һәм татар хәрефләрен, сүзләрен чагыштырып, җентекләп эшләнгән. Телгә өйрәтүдә татарча-русча һәм русча-татарча сүзлекләре дә (1878, 1892) мөһим роль уйный: «*Сүзләрне берәм-берәм ятлап, һәрбер ишеткән сүзне исеңдә тотып, берәм-берәм зиһен тубалына тутырырга кирәк. Моның мисалы менә шундый: берәү, бер чиләк алып, урманга җиләк җыярга бара. Иң элек, урман авызына кергәч, чиләгенә бер җиләк өзеп сала. Шулай кичкә чаклы йөреп, чиләген тутыра*» («Русча-татарча лөгать»тән) [Насыйри, 1974, б. 36].

К. Насыйри әхлак, тәрбия, уку-укыту мәсьәләләрен бергә үреп бирә: «Гыйлемлек вә наданлык», «Ата-ана хакы», «Хәйләкәрлек», «Әдәп» һ.б. Педагог баланы яшьтән үк акны карадан, яхшыны яманнан аера белергә өйрәтсәк, үсеп җиткәч аңа күпкә җиңел булачагын, тормышта ориентлашып, үз урынын, үз юлын дөрес табачагын ассызыклый, «*... балалар яшь агач кебектер, яшь агач һәрникадәр кәкре булса да, төзәтмәк ансаттыр*»(«Әхлак рисаләсе» (1890)) [Насыйри, 1974, б. 38].

1892 елда аның «Кавагыйде китабәт» («Язу кагыйдәләре») дигән кулланмасы басылып чыга. К. Насыйриның «Әнмүзәҗ»ен (1895) шул чорның беренче гыйльми тулы грамматикасы дип атыйлар [Татар грамматикасы, 1998, б. 57]: *«Утыз-утыз биш елдан бирле ике тел фәннәреннән, ягъни үз телебездән вә дәхи рус теленнән балаларга сабак укытканда, хосусан рус телен укытканда үз телебезнең кагыйдәсен бәян кылгучы бер китапка мохтаҗ буладыр идем»*. Шул уңайдан татар телен гыйльми өйрәнүгә, татар телен укыту методика-

сын үстерүгә зур өлеш керткән Казан тюркология мәктәбенең роле дә, һичшиксез, зур (В. Радлов, Н. Катанов, И. Бодуэн де Куртенэ, В. Богородицкий һ.б.).

Россиядә XIX гасыр ахырларына кадәр балаларны үстерү, аларны укыту, югары тәрбия бирү, ир балалар белән бергә кызларны да мәктәпкә тарту, мәктәпләр төзү, аларны ашату-эчертү рус һәм татар педагог-галимнәренең уртак проблемаларына әйләнә (С. Рачинский «Заметки о сельских школах» (1883)), Н. Ильминский «Казанская центральная крещено-татарская школа: Материалы для истории христианского просвещения крещеных татар» (1887), В. Сиповский «Чего недостает современной школе», «Чему и как учить» (1895) һ.б.). Алар арасында *«аягыма кияргә юк дип укырга йөрмәүче балага кәвеш алып биргән»,* ач-ялангач шартларда, фатир эзли-эзли, шунда дәресләр үткәргән олы җанлы, белемле К. Насыйри да бар [Насыйри, 1974, б. 39].

К. Насыйриның педагогик һәм методик характердагы мәкаләләрен һәм китапларын өйрәнеп чыккач, шуны әйтәсе килә: ул шәкертләрнең психологиясен яхшы белгән оста педагог, уку-укыту һәм тәрбиягә караган мәсьәләләр белән бик теләп, яратып шөгыльләнгән, методика фәнен яхшы белгән тәҗрибәле укытучы булган. Аның лингвистика, методика өлкәсенә караган хезмәтләренең тарихи әһәмияте туган телебезгә, татарча укытуга игътибар бермә-бер арткан безнең заманда тагын да ачыграк күренә. Шул рәвешле, XIX гасырда К. Насыйри хезмәтләре, грамматика китаплары, сүзлекләре татар телен укыту методикасы өлкәсендә яңа фикерләр уятты, укытуның эчтәлеген ачыкларга, эш алымнарын эзләргә юнәлеш бирде.

XIX гасыр ахыры XX гасыр башлары – телгә өйрәтү методикасының нигезе эшләнгән чор. Бу чорда рус-татар мәктәпләре күпләп ачыла, укытуның эчтәлеге ачыклана, иң уңышлы ысуллар һәм алымнар тәкъдим ителә, грамматика китаплары, дәреслекләр бастырыла. Бигрәк тә рус һәм татар телләрен өйрәтүдә педагог-галимнәр В. Радлов, Н. Катанов, К. Ушинский, К. Насыйри, Г. Ибраһимовларның роле зур. Аларны телгә өйрәтү методикасының нигезен эшләгән, күләмле методик хезмәтләр язган оста педагог-галимнәр дип атарга тулы нигез бар.

**Әдәбият**

Антология педагогической мысли России второй половины XIX – начала XX в. / сост. П.А. Лебедев. М.: Педагогика, 1990. 603 с.

*Закирова Л.И.* Василий Васильевич Радлов. Казанский период деятельности. Казань: Ихлас, 2013. 291 с.

*Ибраһимов Г.* Татар телен ничек укытырга?: телебезнең методикасы хакында бер тәҗрибә. Казан: Сабах, 1916. 90 б.

*Йосыпов Ф.Й.* В.В. Радловның Казан чоры фәнни, педагогик эшчәнлеге // Фәнни Татарстан. 2023. № 1. Б. 143–155.

Кое-что о казанском мусульманстве. Казань: Типография и литография В.М. Ключникова, 1893. С. 93

*Кононов А.Н.* В.В. Радлов и отечественная тюркология // Тюркологический сборник. М.: Наука, 1972. С. 7–15.

*Насыйри К.* Сайланма әсәрләр. Ике томда. Беренче том. Казан: Татар. кит. нәшр., 1974. 320 б.

*Радлов В.В.* Образцы народной литературы тюркских племен, живущих в Южной Сибири и Джунгарской степи. Часть IV. Наречия барабинцев, тарских, тобольских и тюменских татар / сост. д-р филол. наук Ф.Ю. Юсупов). Казань: Татар. кн. изд-во, 2012. 517 с.

Татар грамматикасы: Өч томда. 1 т. Мәскәү: «Инсан», Казан: «Фикер», 1998. 448 б.

*Ханбиков Я.И.* История развития педагогической мысли татарского народа. Казань: КГПИ, 1975. 162 с.

*Шакирова Л.З.* Обучение русскому языку в татарской школе: теория и практика / Л.З.Шакирова. Казань: Магариф, 2002. 191 с.

*Шакурова М.М.* Становление и развитие методики преподавания татарского языка в иноязычной аудитории // Научный Татарстан, 2010. № 3. С. 207–214.

***Шәкүрова Мөслимә Мәгъсүм кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, доцент, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының милли мәгариф бүлеге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

УДК 398.22

*З.С. Аманбаева*

# БАШКОРТ ХАЛКЫНЫҢ «УРАЛ БАТЫР» ЭПОСЫНДА ДУАЛИЗМ КҮРЕНЕШЕ

В статье рассматриваются проблемы нравственного противостояния в лице образов родных братьев. На основе анализа мотива противостояния земного, небесного и подземного миров рассматриваются категории добра и зла, жизни и смерти. Это дает возможность составить целостную картину мифологической модели мира в сознании древнего народа.

**Ключевые слова:** добро, зло, дуалистическое мировоззрение, Урал-батыр, Шульген.

The article examines problems of moral confrontation in the form of images of brothers. Based on the analysis of the motive of confrontation between the earthly, heavenly and underground worlds, the categories of good and evil, life and death are considered. This makes it possible to create a holistic picture of the mythological model of the world in the minds of the ancient people.

**Keywords:** good, evil, dualistic worldview, Ural Batyr, Shulgen.

Дөнья яратылуга, изгелек белән бергә явызлык та барлыкка килә. Яхшылыкның мөһимлеге аның явызлык белән параллель рәвештә баруында, аларның көрәшендә күренәдер, мөгаен. Изгелек белән явызлык көрәшен сурәтләүгә халык иҗатында зур гына урын бирелгән. Бу, әлбәттә, күбесенчә әкият, эпосларда сизелә. Әлегә сүз башкорт халкының кабатланмас милли хәзинәсе – «Урал батыр» эпосы хакында булыр.

«Урал батыр» эпосында күтәрелгән темаларның берсе – явызлыкка каршы көрәш. Әсәрдә явызлык ничек кенә көчле булмасын, ул барыбер яхшылыктан җиңелә, дигән фикер үткәрелә. Яхшылык белән явызлык көрәше борынгы җәмгыятьтәге дуалистик карашның эпикага үтеп керүен һәм төп темага әйләнүен күрсәтә.

Башкорт ыруларын башлап җибәрүче Йәнбирде карт белән Йәнбикә карчыктан кешелекне яклаучы, ил мәнфәгате белән янып яшәүче Урал батыр һәм кеше дошманына әверелгән Шүлгән дә туа. М. Сәгыйтов әйтүенчә, ике бертуганда яхшылык һәм явызлык образларын сурәтләү – ул халыкның борынгы дуалистик карашын чагылдыручы күренеш, ягъни ике көч – яхшылык белән яманлык гомер бакый бер-берсе белән көрәшә, дигән фикер. Урал белән Шүлгән – шул карашны гәүдәләндерүче бер-берсенә капма-каршы образлар [Сәғитов, б. 60].

Белүебезчә, дөнья фольклорында да ике туган арасындагы көрәш мотивын билгеләп үтәргә мөмкин. Мәсәлән, грек мифологиясендә Прометей белән Эпиметей, «Авеста»да Ахура-Мазда белән

Ангро-Манью көрәше дә шул изгелек белән явызлык көрәшенә барып тоташа.

Эпосның буеннан буена изгелек белән явызлык көрәше төп конфликт төенен тәшкил итә. Ә. Дәүләтколов үзенең хезмәтендә шушы ике башлангычта зароастризм диненә хас дуализм күренешенең чагылышын әйтеп үтә [Давлеткулов, с. 163].

Ә.М. Сөләйманов белән Р.Ф. Рәҗәпов «Башҡорт халҡының мифологик эпосына хас ҡайһы бер үҙенсәлектәр» дигән хезмәтләрендә эпоста К. Мәргән, М. Сәгыйтов, С. Галиндар игътибарын җәлеп иткән бер күренешне борынгы сунарчы ата-бабаларыбыз уздырган ритуалның чагылышы дип әйтеп үтәләр. Монда Йәнбикә белән Йәнбирденең сунарга чыгар алдыннан кабырчыктагы канны авыз итүләре турында сүз бара. Шул ритуал буенча, кан иясе булган ерткыч көче канны эчүчегә күчә, имеш [Сөләйманов, Рәҗәпов, б. 338].

Шулай ук шушы ритуалның балигъ булмаган үсмерләр өчен тыелуы да игътибарга лаек, ди алар. Шүлгән олылар тыюына колак салмавы белән үзен ата-ана сүзен санга сукмаучы итеп кенә түгел, йола белән исәпләшмәүче рәвешендә дә күрсәтә. Менә шул башта ачылган кире ягы аның киләчәктә дә Урал батыр кылган изгелекләрнең киресен эшләвенә төшендерү әһәмиятенә ия. Ә Урал батыр ата-анасы тыюына колак салуы, ягъни йоланы бозмау ягында булуы белән киләчәктә изге юлдан китәсен алдан билгеләп куйгандай була. Шулай итеп, ерткыч канына бәйле йоланы бозу-бозмау асылда Шүлгән белән Уралның капма-каршы холык-фигыль иясе булып үсүен дә, моңа бәйле икесенең ике төрле маҗараларга очрауларын да, димәк, шуның белән эпоста ике сюжет сызыгы булуын да, аларның алга таба бер-берсенә охшамаган ике юнәлештә баруын да билгели.

Балаларның ата-аналарын, бигрәк тә аталарын тыңлау зарурлыгы хакында сөйләүче бу мораль әхлакый, патриархаль нормалар белән аңлатыладыр. Ике бертуганның дошманлашуы сөземтәсендә конфликт кискенләшә. Аларның бәрелешендә ыру җәмгыятенең бер-берсе белән дошманлашуы ике өлешкә бүленүен күрергә була. Берсе – Шүлгән – барысына хаким булып, башкаларны кол итәргә тырыша. Икенчесе – Урал – бөтенесенең тигезлеге, гаделлек, ыру җәмгыятенең йолаларын һәм нормаларын саклап калу өчен көрәшә. Урал явыз үлемне табып юк итәргә чакыргач та, ерткычлар белән бергә Шүлгән аңа каршы чыга. Бар тирә-якка яхшылык кына эшләгән Урал, явыз агасының Һомай-аккошны ашыйк дигән теләгенә каршы чыгып, Һомайны коткарып кала.

Урал – халык күрергә теләгән идеаль батыр образы. Уралның бөтен гамәлләре, батырлыклары кешелеккә үлемсезлек китерү мотивы белән бәйле. Ул гадел, ярдәмчел булырга тели, ыру, кеше мәнфәгатен үзеннән өстен куя, кыерсытылуга, изелүгә дучар булганнарны яклап көрәшә. Эпоста ул физик яктан бик көчле демиург итеп сурәтләнә. Шул ук вакытта Урал батырда башкорт халкына хас сыйфатлар, ягъни басынкылык, гадилекнең булуы ассызыклана. Уралның гаделлек

сыйфаты аеруча аның дошманнарга мөнәсәбәтендә чагыла. Ягъни ул аларны аяусыз юк итәргә тырышмый, ә уйларга, төзәлергә форсат бирә, тик тәкъдиме кире кагылса гына, аларны каты җәзалап үтерә. Шүлгәнне дә туры юлга бастырып карый, тик ул явызлыктан арына алмый. Эпоста Урал батыр агасына һәрвакыт яхшылыкның яманлыкны җиңүен аңлатырга тырыша. Агасы белән алыштан соң Уралның Шүлгәнгә эндәшүендә аңа тулы сыйфатлама биргән юлларга игътибар итеп үтик.

*Йәштән яуыз үстең һин,*
*Урлап ҡан да эстең һин.*
*Атам һүҙен тотманың,*
*Яуызлыҡҡа ыҡланың,*
*Яҡшылыҡты ташланың.*
*Ҡанда йөҙҙөң яуың мән,*
*Ил капланың һыуың мән,*
*Ил үртәнең утың мән,*
*Дейеүҙәрҙе дуҫ иттең,*
*Кешеләрҙе хур иттең;*
*Яуызлығың ат иттең,*
*Йөрәгеңде таш иттең,*
*Атам йөҙөн ят иттең,*
*Әсәм һөтөн ыу иттең...*
*Һин һүҙеңдә торманың,*
*Яуызға ҡаршы барманың,*
*Бөтә илде һыу иттең,*
*Кеше ҡанын ҡоярға*
*Дейеүҙәрҙе өскөттөң,*
*Ер өҫтөндә эркеттең,*
*Тигеҙ яткан ер йөҙөн,*
*Иңкар-шоңкар иттең һин...*
[Урал батыр, б. 161–162]

Бу сүзләрдән соң Шүлгән, әлбәттә, Уралга болай дип сүз бирә:

*Ҡара йөҙөм йыуайым,*
*Аҡ йөҙ мән алдыңда*
*Килеп, ерҙе үбәйем,*
*Кешеләргә иш булып,*
*Бергә торлаҡ ҡорайым.*
[Урал батыр, б. 162]

Шулай да Шүлгән явызлыктан баш тарта алмый.

Урал батыр кылынган изгелекләре өчен бер вакытта да халыкны үзе алдында бурычлы дип санамый. Иреккә чыгып, газаптан котылган халык аның кылган изгелеге өчен: *«Инде, егет ни эшләйек, ниндәй бүләк бирәйек; Тәңре тиһәк, кешеһең, ни тип әйтеп ҙурлайыҡ»,* – дип әйтүләренә болай дип җавап бирә:

*Һис бер ҙурлык кәрәкмәй,*
*Ил батыры шул булыр –*
*Кеше һөйәр ил булыр.*
*Һеҙҙең шатлык – минеке,*
*Минең шатлык – һеҙҙеке.*
[Урал батыр, б. 97]

Урал батыр гомеренең ахырына кадәр яхшылыкны пропагандалый. Моны аның түбәндәге сүзләре дәлилли:

*Яҡшылыҡ булһын атығыҙ,*
*Кеше булһын затығыҙ;*
*Яманға ҡул ҡуймағыҙ,*
*Яҡшынан баш тартмағыҙ,*
*Тигән һүҙен әйткән дә*
*Урал батыр үлгән, ти.*
[Урал батыр, б. 178]

Урал батырның үлемсезлек биргән тере су эзләве – «Урал батыр» эпосы сюжетының төп лейтмотивы. Бу мотив дөнья фольклорында да еш очрый. Урал батырның тере су эзләп үткән юлы – аның мәңгелек даны юлы. Бөтен кешелек язмышын кайгыртуында Урал батырның үлемсезлеге чагыла. Урал батыр – мәдәни герой, халыкның ата-бабасы. Ул кылган изге гамәлләр бөтен кешелек өчен социаль әһәмияткә ия. «Урал батыр» эпосында мәдәни герой төшенчәсе булу һичшиксез аны үлемсезлек проблемасы белән бәйле башка мифлардан аерып тора. Монда тере су мотивы тирән символик мәгънәгә ия. Герой җирне тере су белән сугарып, табигатьтә мәңгелек тәртип урнаштыра.

Урал батыр кешелекнең, табигатьнең үлемсезлеге өчен көрәшә. Әмма ул кешенең мәңгелек тормышы турында үз фикерен үзгәртергә мәҗбүр була. Моңа, беренчедән, хайваннар дөньясының каршы торуы, икенчедән, тере су эчеп, газапланып яшәгән картны очрату булышлык итә. Карт үзенең күргән газапларын сөйләп, Уралга үлемсезлектән баш тартырга киңәш бирә. Шуннан соң гына батыр табигатьне, тирә-як мохитне үлемсез итәргә карар кыла.

Урал батыр бөтен коллектив мәнфәгатен кайгыртырга тырыша. Бу бигрәк тә геройның тере судан баш тартуы, шәхси үлемсезлеккә өлгәшергә теләмәвендә чагыла. Монда аның батырлык, гаделлек, олыларны олылау, кечеләрне кече итү кебек әхлакый сыйфатлары чагыла. Тере су белән ничек эш итүе – ул Урал батырның әхлагын билгеле: ул үз-үзенә хыянәт итми һәм үзенең үлемен лаеклы кабул итә.

С.С. Парсамов әйтүенчә, «Үлемсезлек таныла, әмма бер шәхеснең физик үлемсезлеге түгел, ә аның даны, яхшы гамәлләренә карата буын-варисларының рәхмәтлелеге. Туры мәгънәдә, поэма раславынча, шәхес түгел, ә бөтен халык үлемсез...» [Парсамов, с. 90].

Шулай итеп, әсәр башыннан Урал – яхшылык, ә Шүлгән явызлык яклы булып чыгыш ясый. Димәк, «Урал батыр» эпосында Шүлгән

белән Урал – борынгы башкорт халкының дуалистик карашын гәүдәләндерүче капма-каршы образлар. Яхшылык һәм явызлык, яшәү һәм үлем, үлемсезлек көрәше «Урал батыр» эпосы эчтәлегенең нигезен тәшкил итә. Кешенең үлемсезлеге аның изгелегендә – эпосның төп идеясе менә шул. Бу идея картның *«Күккә лә осор – яҡшылыҡ, һыуға ла батмаҫ – яҡшылыҡ, утта ла янмаҫ – яҡшылыҡ, телдән дә төшмәҫ – яҡшылыҡ»* [Урал батыр, б. 95], дигән сүзләренә нигезләнгән.

**Әдәбият**

*Давлеткулов А.Х.* Проблемы художественно-эстетического осмысления истории этноса в башкирском эпосе. Уфа, 1998. 214 с.

*Сәғитов М.М.* Боронғо башкорт ҡобайырҙары. Монография. Өфө: Башҡортостан китап нәшриәте, 1987. 224 б.

*Сөләймәнов А.Х., Рәжәпов Р.Ф.* Башҡорт халкының мифологик эпосына хас ҡайһы бер үҙенсәлектәр. Өфө, 1998. 448 б.

*Парсамов С.С.* К вопросу об отражении мифологических воззрений в башкирском народном эпосе «Урал батыр» // Башкирский фольклор. Вып. IV. 85 лет записи башкирского народного эпоса «Урал-батыр»: сб. статей. Уфа: Гилем, 2000. 301 с.

Урал батыр. Башкорт халык кобайыры. Өфө: «Аэрокосмос һәм ноосфера», 2004. 213 б.

***Аманбаева Зилия Сатыбалды кызы,***
*М. Акмулла исемендәге Башкот дәүләт педагогика*
*университетының мәгълүмат-аналитика бүлеге*
*әйдәп баручы белгече*

УДК 745

*Л.М. Шкляева*

# Ю.В. ПАВЛОВНЫҢ ХӘЗЕРГЕ ЧОР ИҖАТЫНДА ТРАДИЦИОН ЛАКЛЫ МИНИАТЮРА СӘНГАТЕНЕҢ ҮСЕШЕ

В данной статье раскрываются особенности творчества современного художника Татарстана Ю.В. Павлова, мастера лаковой миниатюры, освоившего стилевые особенности искусства мстерской школы. Опираясь на традиции отечественной школы, он за много лет разработал авторскую интерпретацию основных принципов исполнения основных видов искусства.

**Ключевые слова:** Ю.В. Павлов, художник, Татарстан, лаковая миниатюра, исторические сюжеты, авторская интерпретация.

This article reveals the features of the work of the modern artist of Tatarstan, Y.V. Pavlov a master of lacquer miniature, who mastered the stylistic features of the art of the Master school, based on which he developed an author's interpretation of the traditional principles of performance of works over many years.

**Keywords:** Y.V. Pavlov, artist, Tatarstan, lacquer miniature, historical plots, author's interpretation.

Үз уй-фикерләрен гамәлгә ашыру өчен лаклы миниатюраны төп иҗат төре итеп сайлаган күп кенә рәссамнарны [Лавров, с. 76] Палех, Холуй һәм Мстера сәнгатенең стиль үзенчәлекләре үзенә җәлеп итте һәм ул бүген дә шулай дәвам итә [Сидорович, с. 192]. 30 елдан артык әлеге техниканы кулланып иҗат иткән Юрий Владимирович Павлов та шулар арасында. Ул 1962 елда Казанда туган, гаиләләре белән Әлмәткә күченү сәбәпле, анда сәнгать мәктәбендә укыган (1972–1976), Лениногорск педагогия училищесының сәнгать-графика бүлегендә һөнәри белем алган (1977–1981). Соңрак Н.Н. Харламов исемендәге Холуйск училищесын тәмамлаган һәм лаклы миниатюра өлкәсендә нәселдән килгән оста Олег Александрович Кульпин бу вакытта шушы уку йортында эшләгән (1946–2022). О.А. Кульпин исә Татарстан сәнгатендә беренчеләрдән булып татар милли тарихы һәм мәдәнияте темалары яктыртылган дивар панноларында Палех мәктәбенең сәнгати тәэсирлелек чараларын кулланучылардан [Султанова, с. 4–7].

Ихтимал, нәкъ менә шул вакытта Ю.В. Павлов әлеге иҗат төре белән кызыксына башлагандыр. Ул Мстера стилен нигез итеп сайлый һәм мөстәкыйль рәвештә аның сәнгати-эстетик кануннарын үзләштерә (форма буларак кара лак кулланмау, миниатюрада пейзажның үзенчәлекле роль уйнавы һ.б.) [Журбенко, 2015]. 2004 елда рәссам Казанга кайта һәм хәзерге вакытта да биредә яшәвен һәм эшләвен дәвам итә, төбәк, республика һәм халыкара күргәзмәләрдә һәрдаим актив катнашып килә.

Татарстанның, Россиянең бай тарихы һәм мәдәнияте Ю.В. Павлов өчен идеяләр чыганагы булып хезмәт итә. Мәсәлән, ул Г. Тукайга багышланган һәм «Бөек татар шагыйре» дип аталган эшләре коллекциясен (2017), «Бөек кенәз Александр Невский» коллекциясен (2017–2021), «Пётр I» пластинасын (2022) һ.б. яза. Аның эшләре арасында Татарстанның җирле халыклары тарихыннан алынган әһәмиятле вакыйгалар тасвирланган лаклы миниатюраларны да очратырга мөмкин: «1551 елның 24 мае. Архитектор, дьяк Иван Выродков җитәкчелегендә Зөя каласына нигез салыну» (2011) һәм «922 елның маенда илтабар Алмуш Җафар хан тарафыннан Идел Болгарында ислам дине кабул ителү» (2012) шкатулкалары, «Казан өчен көрәш» пластинасы (2013) һ.б.

Тарихи темалар белән беррәттән, Ю.В. Павлов татар фольклоры сюжетларына да мөрәҗәгать итә. «Кабан күле легендалары» шкатулкасындагы (2014) рәсемнәрне шулар рәтенә кертергә була. Кабан күленең төбендә яткан хан хәзинәләре турындагы кыйссалар рәссамны иҗатка рухландыру нәтиҗәсендә «Сабантуй» (2015) һәм «Шүрәле» (2017) картиналары да иҗат ителә.

Ю.В. Павлов, лаклы миниатюра сәнгатендәге художестволы тәэсирлелек чараларына таянып, сюжетларны үзенчә ача. Әйтик, оста күп кенә эшләренең төсләр гаммасын зәңгәр һәм күк төсләр белән баета. Шундый әсәрләр арасында «Су буйлап, Казансу елгасы буйлап» (2013), «Сөембикә ханбикә һәм аның улы Үтәмешгәрәйнең ярдан кузгалып йөзеп китүе» (2015), «Су анасы» (2017) бар. Моннан тыш, башка әсәрләрен иҗат иткәндә, ул «Авыл киче» (2012), «Таңбатыр» (2010) шкатулкаларында чагылыш тапкан полихромияне куллана. Әлеге алымның кулланылуы татар декоратив-гамәли сәнгатенә төсләрнең күптөрлелегe хас булу һәм контраст колористика белән аклана. Шулай ук рәссам пейзаж язудагы төсләр нюансировкасында кулланыла торган юка буяу катлавыннан (плавь) файдалана, бу исә үсемлекләргә, суга, корылмаларга үзенчәлекле төсмер бирә: аларның өслеге асылташ кебек җемелдәп тора. Нур бөркелгән, якты, тере буяулар аша рәссам яшәешнең шатлык белән тулы булуын чагылдырырга тели.

Ю.В. Павловның «ерактагыны гәүдәләндергән» панорамалы пейзажы күз күреме җитәрлек бөтен дөньяны колачларга омтыла. Рәссам, табигать күренешләре өстендә эшләгәндә, осталарның лаклы миниатюралар сүзлегендә «каравашка» дип йөртелгән болытларны сурәтләүдә стиль үзенчәлекләрен саклый [Грицай, с. 183]. Аның пейзажлары традицион рәвештә агачларның күптөрле формаларын үз эченә ала: соңгыларының кәүсәләре, ботаклары һәм яфраклары җентекләп эшләнгән. Моның белән беррәттән, автор ябалдашны гомум караңгы масса итеп сурәтли, аның өслегендә ачыграк төстәге күпсанлы түгәрәкләп сыланган буяулар яки миниатюр өч таҗлы розеткалар урнаша. Шул рәвешле, рәссам сюжетның күләмлелегенә һәм беркадәр фантазиягә нигезләнгән шартлылыкка омтыла, бу очракта максатка

ирешүдә оста тарафыннан пропорциональ формаларда сурәтләнгән кораб образлары ярдәмгә килә. Алар әкияти хайваннарның нәфис танаулары белән бизәлгән. Ул 4–5 рәттән торган дулкынсыман параллельләр рәвешендә сурәтләнгән суның күп катлылыгын үзенә генә хас осталык белән бирә ала. Зәңгәр төс спектрындагы буяулар талгын гына яктыдан караңгыга таба көчәп ялтырый.

Ю.В. Павлов табигать, шәһәр, авыл күренешләрен гаять оста итеп яза, һава һәм яктылык белән тулы хыялый киңлек тудыра. Әлеге фонда кеше образы бөтен барлыкның гүзәллеген гәүдәләндерә кебек. Рәссам кешеләрне лаклы миниатюраның эстетик принципларына туры китереп сурәтли: аларның бөрмәле-бөрмәле, ачык төстәге киемнәре гәүдәләрен түгәрәкләтеп җибәрә һәм аерым бер нәзакәтлелек бирә. Ю.В. Павлов эшләрендә персонажларның реалистик трактовкасы аларның беркадәр шартлы гәүдәләнеше белән органик рәвештә яраша. Рәссам татарларның да, русларның да образларын бердәм композициягә кертә, шул рәвешле аларның тормышларындагы үзара бәйләнешне ассызыклый.

Авторның дөньядагы хәлләрнең бер үк вакытта баруын сурәтләү алымын аерым күрсәтеп үтәргә кирәк. Бу аның түбәндәге эшләрендә чагылыш таба: «Су буйлап, Казансу елгасы буйлап» (2013), «Сабантуй» (2015), «Матурым, шуарга барабыз» (2013), «Казанда Казан Мәрьям Ана соборын яңадан торгызу» (2021–2022). Әлеге картиналарның сюжетларында Ю.В. Павлов я XIX гасыр вакыйгаларын XXI гасыр архитектурасы күренешләре белән берләштерә, я әсәрне төрле, шул исәптән хәзерге тарихи чор персонажлары белән тулыландыра. Ул буыннар арасындагы күзгә күренми, әмма барыбер сизелә торган бәйләнешне ассызыклый. Барлык миниатюраларда да урын алган төп архитектур формалар шунда ук күзгә ташлана [Романенко, Бесшапошникова, с. 42]. Шулай ук автор корылмаларның декоратив бизәлешен эшләүгә дә зур игътибар бирә.

Озак еллар дәвамында рәссам Ю.В. Павлов үз язу манерасын булдырды. Ул күп фигуралы композицияләрнең бөтенлеге, детальләрнең эшләнгәнлеге һәм сызыкларның йомшаклыгы, шулай ук ачык төсләргә нигезләнгән колористик чишелеше белән аерылып тора. Рәссам аерым эшләрен, милли эстетик кануннарга таянып, татар декоратив системасы өчен хас үсемлек-чәчәк орнаментлары төшерелгән бизәкле рамка эченә утырта. Катлаулы ритм уенында, фигураларның күренер-күренмәс сызыкларында, төсле массалар һәм буяулар аһәңдәшлегендә халык җырлары тоемлана. Композициянең аерым элементлары арасында сюжет, сәнгати-образлы һәм хисси бәйләнеш барлыкка килә, бу автор стиленең үзенчәлеге белән аңлатыла. Оста дөньяда барган хәлләрне фәлсәфи күзлектән үткәреп кабат тамашачыга җиткергәндә, туры юлны виртуозларча әйләнеп уза.

Шулай итеп, Ю.В. Павловның лаклы миниатюрасы борынгы рус сәнгатенең иҗади эшкәртелгән традицияләренә нигезләнә. Шул ук вакытта аның аерым әчке динамика белән сугарылган үз манерасы

бар. Ул татарларның һәм Татарстанда яшәүче башка җирле халыкларның дөньяга карашын чагылдыра, тарихтан, мифологиядән һәм фольклордан алынып, күпмилләтле республика өчен традицион саналган сюжетларга мөрәҗәгать итә. Аның каләме бу сюжетларга яңа яңгыраш бирә. Ю.В. Павлов миниатюралары югары дәрәҗәдәге осталык белән башкарылган, аларның төп идеяләре дә үзенчәлекле. Алар туган як мәдәниятенә һәм тарихына ихлас мәхәббәт белән сугарылган. Бу аның лаклы миниатюра традицияләрен һәм хәзерге заман Татарстан сәнгатен үстерүгә һәм баетуга шәхсән өлеш кертүе турында нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә.

**Әдәбият**

*Грицай Л.А.* Искусство лаковой миниатюры в России: история и современность // Сборник статей XXII Междунар. науч.-практ. конф. «Современная наука: актуальные вопросы, достижения и инновации»: в 2 частях. Часть 1. Пенза: Наука и просвещение, 2021. С. 182–186.

*Журбенко Л.В.* Особенности лаковой миниатюры Мстеры // Научный поиск. 2015. № 2, 4. С. 51.

*Лавров Д.Е.* Исторические этапы развития СССР в произведениях русской лаковой миниатюры XX в. // Ноосферы исследования. 2022. № 4. С. 72–80.

*Романенко С.В., Бесшапошникова Ю.А.* Образы городов России в произведениях лаковой миниатюрной живописи // Крымские диалоги: культура, искусство, образование. № 3 (11), 2017. С. 40–46.

*Сидорович Ю.М.* Лаковая миниатюрная живопись как средство приобщения к национальным традициям и художественной культуре России // Взаимодействие культуры и общества: проблемы и перспективы. Казань: Омега сайнс. 2017. С. 190–194.

*Султанова Р.Р.* Олег Кульпин. Кистью и сердцем. Казань: Рухият, 2021. 200 с.: ил.

***Шкляева Людмила Михайловна,***
*сәнгать фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Сәнгать белеме үзәге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 792.8

***Л.Р. Петрова***

# ТАТАР МИЛЛИ БАЛЕТ СПЕКТАКЛЕ: СӘХНӘ ЧИШЕЛЕШЕН ЭЗЛӘҮ МӘСЬӘЛӘСЕНӘ КАРАТА

Постановка национальных балетных спектаклей в советский период на основе легенд, мифов, приданий и др., привела к увеличению диапазона сюжетов для инсценировок, обогащению жанров и стилей. Синтез танцевального фольклора, классического танца и современного пластического языка расширил возможности балетного театра и привел к возникновению новаторской лексики. В настоящее время хореографы продолжают поиски, способствующие развитию национального балетного спектакля и хореографического искусства. В статье рассматриваются особенности постановок «Шурале» (1945, Казань; 1950, Ленинград) и «Сказание о «Йусуфе» (2001, Казань). В указанных спектаклях наиболее ярко в различных формах были представлены характерные принципы национального татарского балета.

**Ключевые слова:** национальный балетный спектакль, фольклор, либретто, «Шурале», «Сказание о Йусуфе».

The wealth of the peoples of the USSR (legends, myths, legends, etc.), using which ballet performances were staged, contributed to the search for new forms of stage embodiment on the Soviet stage in the 20th century. The staging of national ballet performances has led to an increase in the range of plots for dramatizations, the enrichment of genres and styles. The synthesis of dance folklore, classical dance and modern plastic language has expanded the possibilities of ballet theater and led to the emergence of innovative vocabulary. Currently, choreographers continue to search for ways to promote the development of the national ballet performance and choreographic art. This article discusses the features of the productions of «Shurale» (1945, Kazan; 1950, Leningrad) and «The Legend of Yusuf» (2001, Kazan). In these performances, the characteristic principles of the national Tatar ballet were presented most vividly in various forms.

**Keywords:** national ballet performance, folklore, libretto, «Shurale», «The Legend of Yusuf».

1920–1950 елларда союздаш һәм автономияле милли республикаларда балет труппалары актив рәвештә барлыкка килә. Коллективлар Зур театр һәм Киров исемендәге театр репертуарларын үзләштереп үсеш ала. Репертуар формалаштырганда яшь труппалар фольклор материалына нигезләнгән спектакльләр, либреттосы риваять, әкият, мифларга таянып язылган спектакльләр өстендә актив эшли башлый. Балет театры өчен бу ниндидер яңалык булмый, әлбәттә. Гасырлар дәвамында яхшылык һәм яманлык, яктылык һәм караңгылык көрәше, халык авыз иҗатындагы фантастик, мистик башлангыч классик мирасның күпчелек спектакльләре сюжетының нигезен тәшкил итә.

Борынгы «Сильфида» (1832) спектакле өчен А. Нурри шотланд легендалары белән сугарылган либретто яза. Генрих Гейне тарафыннан язып алынган виллислар турындагы борынгы легенда «Жизель» балеты (1841) либреттосы авторы Теофиль Готьены иҗатка рухландырган. «Баядерка» либреттосының (1877) нигезендә борынгы һинд шагыйре һәм драматургы Калидасаның борынгы һинд эпосы мотивлары буенча язылган әсәре ята. «Аккош күле» либреттосы (1877; авторлары – Бегичев һәм Гельцер) аккошларга әверелүче сихерче кызлар турындагы төрле халыкларда киң таралган әкиятләр сюжетына нигезләнә. «Йокыга талган гүзәл» (1890) – балет-феерия, спектакль авторлары тарафыннан француз мәдәнияте тарафына реверанс буларак уйланылып, француз әкиятләре антологиясенә әверелде. Халык авыз иҗаты балет сәнгатенә органик рәвештә туры килде, соңгысы, үз чиратында, көнкүрештән аерылырга һәм гамәлләрне фантастик дөньяга күчерергә омтылды.

«Халыкның тарихи үткәненә, легенда, әкият һәм риваятьләре»нә [Алмазова, 1987, с. 16] нигезләнгән сюжет балет спектакленә яңа бию формалары булдырырга, ансамбль белән һәм ялгыз биюне үстерергә мөмкинлек бирә. Драматик хәрәкәтне реаль дөньядан фантастикага («Сильфида»да тылсымлы урман, «Жизель»да виллисларның теге дөньясы) күчереп, балет театры XIX гасырның икенче яртысында тәэсирлелек чараларының мөмкинлекләрен киңәйтте. «Баядерка» балетында төп герой Солор янына күләгәләр килгән күренештә балетмейстер Мариус Петипа «образны шигъри гомумиләштерә, бию темасын симфонияләштерә» [Красовская, 1978, с. 125], хореография геройларның хис-кичерешләрен һәм тойгыларын, вакыйгаларны һәм эчтәлекне чагылдыра. Геройларның күзаллаулары, хатирәләре, төшләре, хыяллары хатын-кызлар кордебалеты башкаруында бию өстенлек иткән күренешләргә, тулы бер актларга әйләнә. Бу алым XX гасырда реформаларга һәм новаторлык эзләнүләренә киң юл ача.

1920–1940 елларда совет сәхнәсендә милли балет спектакле барлыкка килә. Яшь республикалар театрлары пантомима һәм хореография аша халык сәнгатен, традиция һәм гореф-гадәтләрне аеруча җентекле чагылдырырлык сәхнә формаларын эзли башлыйлар. Сюжетлары эпос, риваять, әкиятләргә, фольклорга нигезләнгән балетлар куела. Бу этап милли балет XIX гасыр рус балеты традицияләрен, М. Фокин, А. Горский һәм Ф. Лопухов кебек экспериментаторларның XX гасыр башындагы эзләнүләрен дәвам итә һәм 1930–1950 еллар совет балет сәхнәсе казанышы – драма балеты рәвешендә оеша. Рус балет сәхнәсе тәҗрибәсенең бөтен арсеналыннан (пантомима, классик бию, фантастик дөньяларны үз эченә алган күренешләр) файдаланып, «милли балет», шартлылыктан һәм стилизациядән читләшеп, халык биюенә якыная.

Тарихи үткәнгә, фольклорга мөрәҗәгать итеп, беренче татар балетлары либретто авторлары тамашачыны халыкның көнкүрешенә

һәм мәдәният дөньясына тарттылар. Композиторлар сюжетны татар халкының күп гасырлык музыкаль фольклоры традицияләрен партитурага куеп «дәвам иттеләр». Музыкага ияреп, халык биюе дә үзгәрде. Балетмейстерлар, милли колоритны, музыкаль характерны хореографиядә чагылдырырга омтылып, татарларның бию фольклорын өйрәнә башладылар. Спектакльләр куйганда халык традицияләреннән файдаланып кына калмыйлар, ә фольклорга турыдан-туры мөрәҗәгать итәләр, аннан өземтәләр китерәләр, бу баштан ук милли балет спектакленең төп сыйфатларын билгели. «Шүрәле» беренче зур спектакль була һәм милли балетнын үсеш юлларын күрсәтә, аның нигезендә «рухи культураның һәм халык психологиясенең аеруча характерлы үзенчәлекләре, аның әхлакый идеаллары» ята [Алмазова, 1987, с. 3].

XX гасыр уртасында күпчелек милли совет балеты мәктәпләрендә татар композиторлары һәм балетмейстерлары иҗатында гомуми тенденцияләр барлыкка килә. «Фабуласы киңәйтелгән, сюжетлылыкка, вакыйгалылыкка, җентекләп эшләнгән сценарий интригасына аеруча игътибар биргән күпактлы, зур балет спектакле төре» туа [Алмазова, 1987, с. 142]. Тәэсирлелек чараларыннан пантомима беренче планга чыга, бу – XX гасырның 1930–1940 елларында совет балет сәхнәсендәге гомуми тенденция. Әлеге чорда Казан сәхнәсендә ике балет куела: 1945 елда – Ф. Яруллинның «Шүрәле»се (хореографлары Л. Жуков һәм Г. Таһиров); 1947 елда – Н. Җиһановның «Зөһрә» балеты (Ф. Гаскәров куелышында). Яңа формалар эзләү дәвам итә, Ә. Бакировның «Алтын тарак» (Л. Бродзиловская куелышында; 1957), Р. Гобәйдуллинның «Кисекбаш»ы (О. Тарасова куелышында; 1958), А. Ключаревның «Тау әкияте» спектакле (Л. Бродзиловская куелышында; 1959) һәм З. Хәбибуллинның «Раушан» балеты (Е. Дорофеев куелышында; 1961) тәкъдим ителә. 1970 елларда З. Хәбибуллинның «Сихерләнгән малай» (1974) һәм А. Монасыйповның «Үлемсез җыр» (1976) балетларын Д. Арипова куя һәм «Зөһрә» балетының яңа редакциясен тәкъдим итә (1972). Болар арасыннан «Шүрәле» балеты гына бәхетле сәхнә язмышына ия була. Ул озак вакытлар Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театры репертуарында бердәнбер милли балет спектакле булып кала һәм татар балет сәхнәсендә зур вакыйгага әверелә. Бары 2001 елда гына театр яңадан әдәби мираска мөрәҗәгать итә һәм «Кыйссаи Йосыф» балеты куела. «Шүрәле» һәм «Кыйссаи Йосыф» спектакльләре милли спектакльнең үсеш-үзгәрешен күзәтергә мөмкинлек бирә.

«Шүрәле» балетының премьерасы Казанда 1945 елның мартында була (Л. Жуков һәм Г. Таһиров куелышында).

Бөек Ватан сугышына (1941–1945) кадәр үк яшь композитор Фәрит Яруллин аның партитурасы өстендә эшли башлый, анда үзәк образ урман – албастысы – татар әкиятләре персонажы, шагыйрь Габдулла Тукай поэмасы герое. Г. Таһиров өчен «Шүрәле» күпьеллык тикшеренүләр нәтиҗәсен һәм практик тәҗрибәне гамәлгә ашырырга

мөмкинлек бирә. «Монда фольклор экспедицияләренең күпсанлы мәгълүматлары файдаланыла, халык биюләрен куючы белгечнең бөртекләп туплаган тәҗрибәсе тулысынча чагылыш таба, элеккеге еллардагы уйланулар гәүдәләнә» [Горшков, 2006, с. 32].

Г. Таһиров һәм Л. Жуков сәхнәгә куйган беренче спектакль берничә сезон бара. Соңыннан Ф. Яруллинның партитурасына хореографлар күп тапкырлар мөрәҗәгать итәләр, иң уңышлы постановка Ленинград хореографы Л. Якобсонныкы була.

Л. Якобсон «Шүрәле»нең үз версиясен 1950 елда Киров исемендәге театр сәхнәсендә күрсәтә. Ленинград хореографы әле Казанда вакытта ук балетны сәхнәгә кую юнәлешендә эшли башлый. Аны Казанга балетны декадага кую өчен чакырткан булалар. Әмма ул балетны тамашачыга Бөек Ватан сугышыннан соң гына күрсәтә ала. Якобсон үз спектаклендә ике – реаль һәм уйдырма дөньялар булдырган. Фантастик дөнья – кошка әверелгән кыз Сөембикә, Шүрәле һәм аның яраннары дөньясы. Вакыйга тылсымлы урманда бара, анда явыз затлар зур ботаклы агач ябалдашлары астына яшеренәләр. Икенчесе – чын дөнья, Батырның дөньясы, татар авылы тормышы.

Спектакльдә костюмнар һәм декорацияләр татар авылы образын тудырырга ярдәм итә. Сценографлардан тамашачыны «шартлы вазгыятьтән чынбарлыкка күчерү» [Березкин, 1976, с. 309], вакыйганы көнкүрешкә максималь якынайту, реалистик киңлекне торгызу һәм «тормыш дөреслеге» [Березкин, 1976, с. 309] белән шаккатыру таләп ителә. Таләпләр драмбалет законнары белән аңлатыла. 1930–1950 елларда совет сәхнәсендә балетның әлеге төре өстенлек итә. Күп актлы спектакльдә әдәбият беренче урынга куела, еш кына режиссерлар балет авторларының берсе буларак чыгыш ясый. Сюжет пантомима һәм бию күренешләре аша җәелдерелә, әмма драмбалетта пантомима беренче планга чыга.

Якобсон «Шүрәле»дә балет сюжетын нәкъ менә бию, балет театрына хас шартлылык аша ачарга омтыла, озак дәвам иткән пантомима күренешләреннән читкә китә. Якобсон Шүрәлене бай пластикага күмә, аның мәгънәле, бормалы хәрәкәтләре Г. Тукайның шигъри юлларын чагылдыра.

«Милли балет» күренеше совет чорыннан соң да бик актуаль була, әмма дистә еллардан соң, без хореографларның беркадәр башка алым белән эшләвен күрәбез.

2001 елда Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры өч актлы «Йосыф кыйссасы» балетының премьерасын тәкъдим итте. Спектакльгә музыканы М. Любовский иҗат итә, либретто авторы – Р. Харис. Аны Петербург хореографлары Н. Боярчиков һәм Г. Ковтун сәхнәгә куя. Спектакль үз вакыты өчен Казан сәхнәсендәге зур яңалык буларак кабул ителә.

Ныклап урнашкан кануннардан – балет сәхнәсендә традицион халык сәнгатен интерпретацияләүдән баш тарткан хореографлар, пластикага нигезләнгән заманча сөйләмнән файдаланып, тамашачыны

борынгы эпосның шигъри юллары белән таныштыралар һәм аның мәгънәсен төшендерәләр.

Н. Боярчиков – үзенең фәлсәфи спектакльләрендә төп геройның эчке дөньясын ачарга, тәфсилле психологик портрет булдырырга омтылган хореограф. XIII гасыр лирик эпосын ул изге кеше җаны турында хикәяләү рәвешендә тәкъдим итә. Спектакльдә вакыйгалар Йосыф тирәсендә бара. Төп герой абсолют миһербанлыкны һәм кешеләрне яхшы якка үзгәртергә сәләтле ярлыкауны гәүдәләндерә. Йосыфның үзен әлеге саф сыйфатлар ирекле итә.

Балетмейстерлар Йосыфның рухи азатлыгын махсус ассызыклыйлар, һәм тамашачы да төп игътибарын шуңа юнәлтә. Аны ярсыган абыйлары яки ачулы тоткыннар чолгап алалар, әмма якын килә алмыйлар. Йосыф гүя күзгә күренми торган түгәрәкнең үзәгендә. Бу «түгәрәк» – аның «киңлеге», ул күзаллаулар белән тулы була ала. Төп геройның иреге – ул игелеклелеккә, аңа югарыдан җибәрелгән нурга тугрылыкта. Аңа абыйларының кансызлыгы да, фиргавен хатынының мәкере дә, тоткыннарның мыскыллаулары да тап төшерә алмаган.

Либретто авторы Кол Гали фикерен дәвам итеп, Йосыфта «Аллаһка, атага, бурычка тугрылык гәүдәләнеше»н күргән. Көй авторы Леонид Любовский үз персонажына бераз башкачарак яңгыраш бирә: «Йосыф язмышына – бер пәйгамбәр, Аллаһ тарафыннан аерып һәм җәмгыять тарафыннан тартып алынган бер кеше язмышы буларак» [Любовский, с. 4] туктала. Ул « көнчелек, хыянәт һәм дөньяны коткарачак матурлык» [шунда ук] турында балет иҗат иткән. Кешеләрнең йөрәкләрен явызлыктан һәм мәрхәмәтсезлектән арындырырга сәләтле, бөтен нәрсәне гафу итүче игелек турында балет-притча, балет-кыйсса килеп чыккан.

Структурасы буенча спектакль новеллаларның чиратлашуыннан тора кебек. Балетның һәр өч актының үз атамасы бар. Беренче акт – «Йосыф һәм аның абыйлары», икенчесе – «Йосыф һәм Зөләйха» һәм соңгысы – «Йосыф һәм фиргавен». Әмма тулаем алганда, спектакльне «Йосыф һәм Йагкуб» дип атарга мөмкин булыр иде. Төп геройның әтисе аның шәүләсе кебек, тормыштагы авыр минутларында яки хатирәләрендә һәрвакыт аның янәшәсендә. Йагкуб образы барлык өч актны берләштерә һәм үтәли эш-хәрәкәт сызыгын барлыкка китерә. Бу – балетның индивидуаль үзенчәлекләреннән берсе. Хореография стилистикасы буенча төрле актларны тамашачыга таныш төп геройлар берләштерә.

Балет – кеше язмышларын хәл итүче изге коңгызлар биюе (дуэт) белән ачыла, алар Йосыф артыннан ияреләр һәм аның тормышында яңа вакыйгаларга юл ачалар. Шулай ук балетның башыннан ахырына кадәр Йосыф кордебалет башкаруындагы «кечкенә йолдызчыклар өере» чолганышында кала. Алар төп геройның күңелен чагылдыралар сыман, күкләрдән җибәрелгән тынычлану, кичергән газаплары өчен бүләк кебек аның бу дөньяга килүен сәламлиләр һәм мәңгелеккә озаталар.

Икенче актта Йосыф авырулардан савыктыручы фиргавенгә юлыга. Бүләк урынына Йосыфны төп герой тарафыннан кире кагылган Зөләйханың (фиргавеннең хатыны) яла ягуы һәм зиндан көтә. Өченче акт караңгылыкка чумган: фиргавен патшалыгын кабахәтлек һәм авырулар каплаган. Патша, үзенең ялгышын аңлап, Йосыфны азат итә һәм аннан гафу үтенә.

Һәр акт, үзенчәлекле аталышыннан тыш, хореографик стилистикасы белән дә аерылып тора. Беренче актта бертуганнарның биюе өстенлек итә. Ачу һәм нәфрәтләре ташып, алар бердәм организм кебек синхрон эш итә. Беренче акт дәвамында аларның хореография тексты ирексез рәвештә чагыштырып барыла. Геройларның конфликты аларның контрастына корылган. Йосыфның хореографик тексты озын сызыклардан, салмак хәрәкәтләрдән торса, туганнарының хәрәкәтләре таркау, «куллары төрле якка караган япьле тырмаларны хәтерләтә». Органик салмак сикерүләр урынына – тупас адымнар. Иске-москыдан киенгән бертуганнарның караңгы фигураларына контраст рәвешендә алтынга күмелгән кәрван пәйда була: анда затлы киемнәр кигән сәүдәгәрне гүзәл биючеләр уратып алган.

Икенче һәм өченче актлар «Мисырга» якынайтылган. Тамашачыга «профиль»дә күрсәтелгән аяк һәм кул чуклары, юри турайтылган яки график бөгелгән тезләр тәкъдим ителә.

Геройларның хореографик темалары индивидуаль. Төп герой партиясе биюдән тора һәм ул иксез-чиксез арабескалардан, салмак хәрәкәтләрдән үрелгән кебек. Беренче күренешләрдә аның биюе балаларча беркатлы һәм ихлас, шуның аркасында фәрештә җанлы герой образы туа, абыйлары Йосыф фонында тупас һәм вульгар булып күренә.

Тамырлары белән XIX гасыр академик спектакленә барып тоташкан (биюләрдән торган дивертисмент) күп актлы спектакль, низагтан, персонажларның эшләнгән характерларыннан, тасвирлы музыкадан, капма-каршы көчләр үсешеннән һәм бәрелешеннән, күптөрле хореографик формалардан (массакүләм биюләр, дуэтлар, монологлар) торып һәм геройларның психологик образларына тирәнтен төшенеп, Кол Гали эпик поэмасының гүзәл образларын гәүдәләндерә. Татар халкының тарихи үткәненә мөрәҗәгать итү тәҗрибәсен үзләштереп, XXI гасыр балет сәхнәсендә эпос пластик текст һәм классик бию синтезы аша гәүдәләнә. «Йосыф кыйссасы» Казан труппасының милли репертуарын баета, һәм шуның белән алга таба милли балет спектакленең яңа формаларын эзләү һәм гамәлгә ашыру юнәлешендә мөмкинлекләрне арттыра.

Легендаларга, хикәятләргә, мифларга, эпоска мөрәҗәгать итү балет театрына зур мөмкинлекләр тудыра. Уңышлар, эзләнү нәтиҗәләре, хореографик драматургиядәге трансформация, пластика телендәге новаторлык, балет спектакльләрен генә түгел, гомумән, әлеге сәнгать төрен баета.

**Әдәбият**

*Алмазова А.А.* Фарид Яруллин и Татарский балет. Казань: Татар. кн. изд-во, 1982. 158 с.

*Березкин В.* Художник в советском балете // Советский балетный театр: 1917–1967. М.: Искусство, 1976. С. 291–351.

*Гайнутдинов М.* Дастанная литература // История татарской литературы нового времени (XIX – начало XX в.). Казань: Фикер, 2003. С. 46–56.

*Горшков В.Н.* Гай Тагиров – основоположник татарского сценического танца (к 100-летию со дня рождения) // Народный танец и хореографическое искусство: традиции и современность. Материалы Междунар. науч.-практ. конф., посвящ. 110-летию Гая Тагирова. С. 32.

*Горшков В.Н.* Из истории татарского балета // Татарский академический театр оперы и балета имени Мусы Джалиля / под общ. ред. Г.М. Кантора. Казань: КГК, 1994. С. 89–106.

*Горшков В.Н.* Гай Тагиров – основоположник татарского сценического танца (к 100-летию со дня рождения) // Вестник Казанского государственного университета культуры и искусств. Казань, 2006. № 5. С. 6–12.

*Донина Л.Н.* Татарский костюм в театре: проблемы интерпретации и реконструкции: автореф. дис. ... канд. искусствоведения. М., 2010. 28 с.

*Исанбет Ю.Н.* Словарь музыкально-сценических произведений татарских композиторов, поставленных на казанской сцене. Казань: Магариф, 2003. 158 с.

*Кантор Г.М.* Начало пути (1939–1950) // Татарский академический театр оперы и балета имени Мусы Джалиля / под общ. ред. Г.М. Кантора. Казань: КГК, 1994. С. 7–36.

*Красовская В.М.* История русского балета. Л.: Искусство, 1978. 231 с.

*Любовский Л. //* Сказание о Йусуфе. Программа к балету.

Обсуждение оперы «Алтын чеч». Казань, 1941 // Архив СТД РТ. Ф. 10. П. 6. 90 с.

П.Т. Сперанский, Л.Л. Сперанская-Штейн. От эскиза к спектаклю / авт.-сост. Л.Н. Донина. Казань: Татар. кн. изд-во, 2010. 464 с.

*Чернова Н.Ю.* Балет 1930–1940-х годов // Советский балетный театр. 1917–1967. М.: Искусство, 1976. С. 106–154.

***Петрова Луиза Раниф кызы,***

*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Сәнгать белеме үзәге фәнни хезмәткәре*

УДК 398

***А.К. Җәләлиева***

# ХӘМИТ ЛАТЫЙПОВ – МИЛЛИ ТРАДИЦИЯЛӘРНЕ ҮСТЕРҮЧЕ

Статья посвящена творчеству челнинского художника Хамита Латыпова – графика, живописца, скульптора, мастера декоративного искусства. Автор статьи анализирует произведения Х. Латыпова, выполненные в художественной обработке дерева и керамике, рассматривает использование им в творчестве фольклорных сюжетов. В художественной обработке дерева мастер сочетает в основном выемчатую (трехгранную, контурную, и др.) и рельефную виды резьбы. Кроме этого, Хамит Латыпов расписывает дерево в авторской узнаваемой манере. Также им создан ряд национальных сувениров, декоративных ваз и скульптурных композиций в керамике.

**Ключевые слова:** декоративное искусство, резьба по дереву, роспись по дереву, керамика, интерпретация, фольклор.

The article is devoted to the work of the Chelny artist Khamit Latypov – graphic artist, painter, sculptor, master of decorative art. The author of the article analyzes the works of Kh. Latypov, made in the artistic woodworking and ceramics and studies his using of folklore stories in his work. In the artistic woodworking the master combines mainly notched (triangular, contour, etc.) and relief types of carving. In addition, Khamit Latypov paints the tree in the author's recognizable manner. He also created a number of national souvenirs, decorative vases and sculptural compositions in ceramics.

**Keywords:** decorative arts, wood carving, wood painting, ceramics, interpretation, folklore.

Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе Хәмит Нәҗип улы Латыйпов – декоратив һәм сынлы сәнгатьнең (нәкыш, графика, скульптура) төрле юнәлеш һәм төрләрендә милли сәнгать алымнарын үстерүче һәм әйдәп баручы осталарның берсе.

Рәссам профессиональ сәнгатькә урау һәм авыр юллар аша килә. Х. Латыйпов 1949 елда Пермь өлкәсенең Половинка бистәсендә туа, тиздән аның әти-әнисе Башкортстанның Илеш районы Бүләр авылына күченеп китә. Ул бик яшьли ятим кала. 1964 елда Х. Латыйпов Уфа музыка-педагогия училищесына укырга керә. Ләкин матди хәле начар булу сәбәпле, беренче курста ук укуын ташлап, Семилетка бистәсендә нефтьче булып эшли башлый. Бүләргә кире кайткач, аны авыл клубы мөдире итеп куялар, ә 1967 елдан Югары Яркәй район үзәгендә чыгып килгән «Маяк» газетасында бизәүче вазифасын үти башлый [Латыйф, б. 161]. Уфа төзелеш техникумында берьеллык балта осталары курсларын тәмамлагач, 1968 елда Дүртөйле районындагы нефть чыгару берләшмәсенә эшкә килә [Латыйп]. 1972–1973 елларда Мәскәү өлкәсе Богородское авылында агачны кисеп-уеп бизәк

төшерү осталары әзерләүче курсларда белем ала [Даутов, Рахмани, с. 14]. Һөнәри осталыгын камилләштерү теләге аны Уфа сәнгать училищесына алып килә, 1978 елда ул «агачны сәнгати эшкәртү» белгечлеге буенча әлеге уку йортын тәмамлый.

Х. Латыйповның сәнгать училищесында укыган вакытта иҗат ителгән эшләре яссы рельефта уеп эшләү техникасында башкарылган. Алар арасында татар халык әкиятләренә багышланган «Шүрәле» (1975), «Сандугач» (1978) дивар паннолары һ.б. бар. Шулай ук «Г. Тукай әкиятләре» дип исемләнгән ике якка ачыла торган ишек (1983) – рәссамның тәүге эшләреннән берсе [Валеева-Сулейманова, с. 574].

Квадрат форматындагы «Шүрәле» панносы композициясе үзәгендә әлеге әкияти персонаж урын алган. Аның тирәсендә стильләштерелгән кеше, кош һәм үсемлек сурәтләре ясалган. Уеп эшләнгән яссылыкта әкиятнең соңгы эпизоды чагылыш тапкан. Анда Шүрәленең аптырашта калуы, ә авыл егетенең, тапкырлыгы аркасында, урманнан исән-имин өенә кайтып китүе тасвирлана. Әкият персонажларын чолгап алган талгын һәм болыт сыман орнамент мотивлары (яфраклар, чәчәкләр, үләннәр, агачлар) татар күн мозаикасы бизәкләрен хәтерләтә. Алар караңгы фонда булулары белән игътибарны аеруча җәлеп итәләр.

Рәссам иҗатының тәүге чорында язылган панно яки кисеп-уеп бизәкләп эшләнгән ишек өстендәге кәкре сызыклар татар чигешендәге бизәкләргә ошаган. Алар, органик төстә үрелеп, бердәм декоратив яссылык хасил итәләр.

1984 елдан алып 1990 еллар уртасына кадәр Х. Латыйпов Башкортстанның Туймазы шәһәре фарфор заводында рәссам-дизайнер булып эшли. Аның эскизлары буенча милли сувенир эшләнмәләре күпләп җитештерелә (декоратив вазалар, сервизлар, кечкенә сыннар). Форма һәм фактура белән уңышлы тәҗрибәләр «Беренче авангардчыларга» (1992), «Диңгез суүсемнәре» (1992) һ.б. кебек скульптур вазаларда чагылдырыла. Мәсәлән, «Беренче авангардчыларга» дип аталган өч авызлы, түгәрәк скульптур вазалар аналитик кубизм стилендә башкарылган. Аларның кыска һәм гади аклы-каралы бизәлеше Каземир Малевич нәкышен хәтерләтә. «Диңгез суүсемнәре» сериясендәге ике вазаның форма һәм фактуралары аеруча кызыклы: берсе – шома, икенчесе – рельефлы (фактурасы катып калган су тамчылары кебек). Алар икесе дә суүсемнәрнең сыгылмалы-бөгелмәле ботаклары рәвешендә башкарылган. «Сагыш. Картлач» (1991) керамик скульптурасында Х. Латыйпов фәлсәфи темага мөрәҗәгать итә: өлкән яшьтәге бер карт, күзләрен ярым ачкан хәлдә, уйга чумган, ул үзенең үткәндәге хатирәләрен барлый. Бу сын формасы һәм төсе белән борынгы кабер ташларын хәтерләтеп, тамашачыны мәңгелек хакындагы уйлануларга этәрә.

Сәнгать белгече Р.Г. Шаһиева билгеләп үткәнчә, Х. Латыйповның Туймазы фарфор заводында эшләгән вакыты, шулай ук 1990 еллар

башында майлы буяу һәм графика белән мавыккан чоры «аның композицияләренә кыюлык, тәвәккәллек өсти», «ул сәнгати образларны яңача аңлый һәм аңлата башлый». Агачны кисеп-уеп бизәк төшерүче һөнәрчедән чын скульпторга һәм олы рәссамга әйләнә ул [Шагеева, с. 7] 1995–2005 елларда Хәмит Латыйпов пастель («Суга бару», «Батыр», «Атка атланган кыз» (1995); «Курай» (1996); «Көтүче», «Чәй эчү» (1997)), шулай ук линогравюра һәм офорт техникаларында эшли башлый. Бу әсәрләрендә рәссам милли темага мөрәҗәгать итеп, татар һәм башкортларның гореф-гадәтләрен, тормыш рәвешен, мифологиясен чагылдыра.

2000 елда Х. Латыйпов яңадан агач белән эшләүгә әйләнеп кайта. Ул Казандагы «Туран» мәдәни үзәге остаханәсе белән уңышлы хезмәттәшлек итә: заказ буенча сандыклар, декоратив тәлинкәләр һәм паннолар ясый. Бу эшләрендә ул борынгы төрки риваятьләргә, татар халык иҗатына мөрәҗәгать итә («Тынычлыкны саклаучылар», «Гармунчы» һ.б.). «Туран» фонды өчен ясалган түгәрәк панно формасындагы әсәрләр төрлелеге һәм катлаулылыгы белән сокландыра. Х. Латыйповның композицион чишелешләре дә төрле. Алар ритмлы һәм асимметрияле урнашкан образларны колачлый («Чокырда», «Тыныч ау», «Күзәтү», «Чибәркәй»). Шул ук вакытта көзге симметриясе принциплары да кулланыла («Соло», «Кышкы кичтә», «Кошлар ашату», «Парлап» һ.б.) [Кривошеева, 2017, с. 284].

2000 еллар башыннан бүгенге көнгә кадәр рәссам агачтан һәм балчыктан сувенирлар эшли. Алар арасында еш кына өлкән яшьтәге кешеләрнең силуэтларын, музыкантларны, хатын-кыз һәм мифологик образларны күрергә мөмкин. Сәнгать белгече Р.Р. Солтанова бу яссы фигураларда борынгы таш балбаллар[1] белән охшашлык бар, дип саный [Галиуллина]. Чыннан да, балбаллар белән охшашлыкны яссы, фронталь фигураларның монолит формасында да табып була. Форма һәм фактура белән бәйле эксперименталь эзләнүләр дә әлеге чорның үзенчәлеге булып тора.

2006 елда Х. Латыйпов түгәрәк форма белән эшләүгә күчә. Бал һәм кымыз салу өчен чарланып эшләнгән цилиндрик вазага төшерелгән сюжет мотивлары татар халкы тормышыннан алынган шигъри картиналар (мәсәлән, милли кием кигән егетләрнең урман эчендә курайда уйнаулары) яки урман җәнлекләре һәм кошлар белән бәйләнгән. Бу эшләнмәләрдәге бизәкләр кыска һәм төгәл, күбесе Болгар һөнәрчеләренә һәм Казан ханлыгы чоры осталарына ук билгеле булган яссы уем белән сырлап эшләнгән [Шкляева, б. 112]. Агач өслектә уйгыч белән гаҗәеп төгәллектә эшләү, артык детальләр булмау җиңеллек хисе тудыра [Кривошеева, 2022, с. 125]. Бу Х. Латыйповның югары профессионализмга ия булуы турында сөйли.

---

[1] Борынгы төрки халыкларда кабер ташы өстендәге сыннар.

Рәссам агачка бизәк төшерүдә шулай ук камиллеккә ирешә, шул рәвешле үзенә генә хас стиль тудыра. Үзәктә кеше яки мифик хайван, кош фигуралары урын алган кечкенә үлчәмле бизәкле такталар дикъкатны аеруча үзләренә җәлеп итә. Фон татар орнаментларындагы үсемлек-чәчәк мотивлары (лаләләр, канәферләр, тукранбашлар, пальметталар, агачлар һ. б.) белән тутырыла. Бизәк төшергәндә рәссам локаль, чиста, ачык буяулар куллана. Бу эшләрендә ул татар халкының көндәлек тормышын һәм бәйрәмнәрен чагылдыра. Мәсәлән, курайда уйнаучы яшь егетләр, җайдаклар, көянтә аскан кызлар һ.б. сурәтләнә. Шулай ук әкиятләрдән һәм риваятьләрдән алынган сюжетлар («Сак-Сок», «Зилант», «Умай» һ.б.) тасвирлана. Әлеге ачык, якты рәсемле тактачыклар төсләр гаммасы, композицион чишелеше буенча рәссамның нәкыше белән аваздаш.

Х. Латыйпов үз осталыгын камилләштереп кенә калмый, агачны кисеп-уеп бизәк төшерү сәнгатен пропагандалау буенча да актив эшчәнлек күрсәтә. 1999 елда аның инициативасы буенча 49 нчы номерлы Туймазы һөнәр лицеенда агачны уеп бизәк төшерүче белгечлеге буенча 3 еллык бүлек ачыла. Ә 2020 елда рәссамның эскизлары буенча Алабуга сәнгать училищесы базасында студентлар тарафыннан акрил буяулар белән бизәкле паннолар эшләнә.

Х. Латыйпов рәссамнарның гына түгел, әдәбиятчыларның да тирән ихтирамын казанды. Ул – Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. Ул үз хисабына татар һәм рус телләрендә дистәгә якын китап нәшер итте. Бу китапларда аның шигырьләре, фәлсәфи фикерләре, иллюстрацияләре урын алган.

Татарстанның хәзерге заман декоратив сәнгате үсешендә Х. Латыйпов гаять мөһим роль уйный: ул агачны кисеп-уеп бизәк төшерү ысулларын камилләштерде, профессиональ сәнгатьтә гомумтөрки фольклор образларын, татар һәм башкорт халкының тормышын киң яктырта.

Хәмит Латыйпов – татар халкының сәнгатен бик нечкә тоемлый һәм аңлый, аны үз иҗатында чагылдыручы иҗатчы. Ул үзен иҗатның төрле юнәлешләрендә – керамикамы ул, нәкышме, агачны кисеп-уеп бизәк төшерүме, сынлы сәнгатьме яки шигъриятме – һәммәсендә дә үзен фәлсәфи мәгънәле әсәрләрен бизәкләр теле белән баетучы оста итеп танытты.

### Әдәбият

*Валеева-Сулейманова Г.Ф.* Латыпов Хамит Назипович / гл. ред. М.Х. Хасанов.Татарская энциклопедия. Казань: Институт Татарской энциклопедии Академии наук Республики Татарстан, 2006. Т. 3: К–Л. С. 574–575.

*Галиуллина М.* Шигърияттә – рәссам, рәсемдә шагыйрь ул // Мәдәни җомга. 2022. 8 нояб. URL: http://madanizhomga.ru/news/cngat/sigieriiatta-rassam-rasemda-sagyir-ul (мөрәҗәгать көне: 26.04.2023).

*Даутов Р.Н., Рахмани Р.Ф.* Әдипләребез: биобиблиографик белешмәлек. Казань: Татар. кн. изд-во, 2009. Т. 2: Л–Я. 734 с.

*Кривошеева Т.Н.* Корни и крона пластики Хамита Латыйпова // Искусство резьбы по дереву в тюркском мире: история и современность: материалы Междунар. симп., Казань, 19–20 декабря 2017 г. / сост. Р.Р. Султанова, Л.М. Шкляева; под ред. Р.Р. Султановой. Казань, 2017. С. 282–284.

*Кривошеева Т.Н.* Скульптура Татарстана: альбом / Т.Н. Кривошеева, Д.Д. Хисамова; [науч. ред. Р.Р. Султанова]. Казань: Татар. кн. изд-во, 2022. 319 с.: ил.

Латыйп Хәмит // Татарстан Республикасы Язучылар берлеге. URL: https://sptatar.com/latyyp-h-mit (мөрәҗәгать көне: 26.04.2023).

Латыйф Хәмит. Галәми гамь: сынлы сәнгать һәм шигырьләр / [кереш сүз язучы Р. Шаһиева]. Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. 168 б. Текст парал.: татар, рус.

*Шагеева Р.Г.* Уелган бизәкләр = Резьба по дереву: альбом. Казань: Татар. кн. изд-во, 2021. 197 с.

*Шкляева Л.М.* Народное искусство домовой резьбы у татар Среднего Поволжья середины XX – начала XXI века: семантика и стилевые особенности. Казань: Татар. кн. изд-во, 2020. 127 с.

***Җәләлиева Айгөл Кәниф кызы,***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Сәнгать белеме үзәге фәнни хезмәткәре*

УДК 792

***Ш. Әхмәдиев***

## «ТИГЕЗСЕЗЛӘР» ПЬЕСАСЫ

Изучение татарской периодической печати начала XX в. позволяет выявить новые источники по истории татарской литературной критики. Одним из них является рецензия Шагита Ахмадиева (1888–1930) на пьесу классика татарской литературы Фатиха Амирхана (1886–1926) «Неравные» («Тигезсезләр», 1914). При этом Ш. Ахмадиев оценивает не только саму пьесу, но и игру актеров, задействованных в постановке пьесы. Таким образом, рецензия названного автора дает сведения не только для исследователей татарской литературы, но и для театроведов.
**Ключевые слова:** татарская периодическая печать, татарская литературная критика, Фатих Амирхан, Шагит Ахмадиев, татарское театральное искусство.

The study of the Tatar periodical press of the early twentieth century allows us to identify new sources on the history of Tatar literary criticism. One of them is Shagit Akhmadiev's (1888–1930) review of the play by the classic of Tatar literature Fatih Amirkhan (1886–1926) «Unequal» («Tigezsezlar», 1914). At the same time Sh. Akhmadiev evaluates not only the play itself but also the performance of the actors involved in the production of the play. Thus, the review of the named author provides information not only for researchers of Tatar literature but also for theater critics.
**Keywords:** Tatar periodical press, Tatar literary criticism, Fatih Amirkhan, Shagit Akhmadiev, Tatar theatrical art.

*Татар әдәбияты классигы Фатих (Мөхәммәтфатих) Зариф улы Әмирханның (1886–1926) «Тигезсезләр» пьесасы беренче тапкыр 1915 елда «Әхмәтгәрәй Хәсәни вә шөрәкясе» наширлегендә басыла. Шул ук елның 9 февралендә пьесаның кульязмасы буенча «Сәйяр» труппасы тарафыннан «Новый клуб» сәхнәсендә спектакль уйнала. Озак та үтми татар вакытлы матбугатында Г. Кәрам (1878–1947), Ш. Әхмәдиев (1888–1930), Ф. Сәйфи-Казанлы (1888–1937), Х. Искәндәров (1888–1958) кебек алдынгы татар зыялыларының әсәргә, уенга карата мәкалә-бәяләмәләре күренә башлый. Шулар арасында язучы, журналист, күренекле җәмәгать эшлеклесе Шәһит Гыймадетдин улы Әхмәдиевнең (1888–1930) рецензиясе игътибарга лаек. Ш. Әхмәдиев пьесаны гына түгел, аны сәхнәгә куюда катнашкан артистларның уенын һәм осталыгын да бәяли. Шул рәвешле, рецензия әдәбият галимнәренә генә түгел, ә театр белгечләре өчен дә кызыклы мәгълүмат бирә.*

*Әлеге язма гарәп графикасыннан гамәлдәге язуга күчерелеп, сүзлек һәм аңлатмалар белән тулыландырылып тәкъдим ителә.*

9 февральдә, Новый Клуб залында Фатих әфәнде Әмирханның кульязмасы буенча «Тигезсезләр» атлы яңа әсәре беренче мәртәбә

сәхнәгә куелды. «Тигезсезләр» – өч пәрдәлек, татарның иң соңгы елlардагы (мөхәррир сүзе[1]) тормышыннан алынып язылган пьесасы.

Беренче пәрдәдә: Насыйбуллин гаиләсе, гаилә атасы Сафа Насыйбуллин фикере белән тәмам яңа тормышның бер әгъзасы булып бетсә дә, гамәлдә алай ук түгел, ул һаман ата-бабасыннан калган мануфактур сәүдәсенә ябышып ята, үзе – төпле фикерле, гакыллы Казан сәүдәгәре. Салиха – балаларын бертигез сөя, бервакытта да аларны кысмый торган бала җанлы, мөлаем табигатьле ана. Зур угыл Гомәр – мөселманча, русчадан уртача гына мәгълүматлы яшь сәүдәгәр. Ул үзенең теләве вә ышануы буенча, татарга бөтенләй башка – ят булган оптика[2] кәсебенә керешә. Гакыллы алып баруы аркасында аның сәүдәсе көннән-көн яхшылана, зурая бара. Ул тар милләтче, татар балаларын да үзе кебек яңа юлга, файдалы кәсепкә кертәсе килеп, үзенә кирәк булган хадимнәрне дә татарлардан гына алырга тели, хөрриятпәрвәр бер егет. Сеңелләре Сәлимә белән Рокыяның һичбер хөрриятләренә кагылмый, аның аларга мөгамәләсе – чын европалашкан гаиләдә генә була торган мөгамәләдер.

Зур кыз Сәлимә – яшь вакытта гимназиягә бирелмичә, соңыннанрак русча укырга тотынган төпле, эшчән кыз, Рокыя – аның сеңлесе. Рокыя яшьтән гимназиягә бирелгән, матур гына укып бара, ул гына түгел, пианино дәресләре алып, музыкага да бик һәвәс мәхәббәт белән өйрәнә һәм рәссам булуны да хыял кыла.

Икенче пәрдә һәм соңы 2–3 ел вакыт үткәч башлана. Гаилә атасы Сафа үлгән. Варис Гомәр үзенең яңа сәүдәсен дә бик яхшы тәрәккый иттереп, һәм атасыныкын да яхшы алып бара. Пьеса икенче пәрдәдән үзенә төс ала башлый: Гомәрнең гаять матур дачасында Рокыяның гимназия бетерү шатлыгы бәйрәм ителә. Мәҗлескә татар мөхәррире, тар милләтче Сөләйман, күрше дачада торган, татарның бар эшенә дә өмидсез караган Мәскәү студенты Габдулла һәм башка белештанышлардан берничә кеше чакырыла. Бигрәк тә Рокыя өч еллар элек бик якын таныш-дуст абзый булган һәм әсәрләрен сөеп укый торган Сөләйман мөхәррирнең Казанга килүенә һәм үзләренә кунакка чакырылуына шатлана.

Сәлимә студент Габдулланы сөя башлый һәм сөя, тик аны үзе генә белә. Габдулла Рокыя белән танышкач, аның артыннан йөрергә, ухаживать[3] итәргә, аңар ярарга тырыша. Ләкин беренче танышуда ук Рокыя Габдулладан бөтенләй бизә, аңар тәхкыйрь[4] күзе белән карый башлый. Чөнки Рокыя – чын тар милләтче кыз, татар тәкъдире хакында әйтелгән күңелсез сүзләрне бер дә күтәрми, үзенең бәхетсезлегенә каршы Габдулла студент Рокыяга карап: «Татарның хәзерге эшләре барысы да – вакытлы бизгәк шикелле эшләр генә, мәктәпләре дә, литературасы да – барысы да бервакыт хлам булып

[1] Мөхәррир сүзе – язучы, автор сүзе.

[2] Сүз чыганакта кириллицада бирелгән.

[3] Сүз чыганакта кириллицада бирелгән.

[4] Тәхкыйрь – түбән күрү.

кына калырлар», – димәсенме. Шуннан соң Рокыя Габдулла белән сөйләшми дә, утырышмый да. Дөресте генә, аны күрәсе дә килми, чөнки Габдулла Рокыяның иң нечкә, иң газиз, иң мөкатдәс милли авыруына инә белән чәнчеде. Рокыя кире какса да, студент Рокыяны сөяргә тотына һәм сөя, әүвәлге фикерләре өчен гафулар үтенә. Үзе мең төрле тәүбә-истигъфар[1] кылып, татар баласы булырга көчләнеп, Рокыяга хатлар яза. Ләкин ничек тә аның нәфрәтеннән башка һичбер дикъкатьне җәлеп итә алмый, чөнки Рокыяның бар уе, бар фикере татар мөхәррире Сөләйманга күчкән. Тик ул Сөләйман алдында гына матураясы, аның алдында гына иркәләнәсе килә. Тик Сөләйман белән булган утырыштан гына тәм-ләззәт таба һәм Габдулланың татарга карашы хакында бик кайгырып, Сөләйманга зарлана. Сөләйман Рокыяны юата, өмидләндерә, шуннан инде «тигезсез»лек башлана. Күбрәк өй тәрбиясе күргән Сәлимә студент Габдулланы сөя, Габдулла Рокыяга мәхәббәт баглый. Рокыя чәченә чал кергән мөхәррир Сөләйманны һәм Сөләйман Рокыяны сөя башлыйлар һәм сөешәләр. Сәлимә үзенең Габдулла, Габдулла исә Рокыядан сөелә алмауларына газаплансалар, мөхәррир Сөләйман Рокыяның сөюен белеп газаплана. Чөнки Рокыя – бер фәрештә, ачылган бер чәчәк. Ул яшь, матур. Ул яхшы тәрбия күргән, инде гимназия бетереп, хикәяләрдәге каһарманнарны тасвир итәрлек дәрәҗәдә хыялга малик булган. Сөләйман – дөнья белән изелгән, чәченә шактый чал кергән ир уртасы кеше. Рокыя мәхәббәтен изһар кылганда[2]: «Рокыя мин синең минем чал чәчләремне дә гафу итәргә хәзер икәнлегеңне белмим. Шуларны белешкән минуттан безнең икемезгә дә җәһәннәм туар, мин сине, Рокыя, шул минуттан чәчләренә чал кермәгән бөтен кешеләрдән көнләшә башлармын... Икемез өчен дә җәһәннәм туар», – ди Сөләйман...

Мәсьәлә, Сәлимәнең Габдулладан өмид өзеп, бер сәүдәгәргә кияүгә чыгарга разый булуыннан, Габдулланың да Рокыядан тәмам өмид өзүеннән һәм Сөләйман белән Рокыяның бер-берсен яхшы аңлашып, бик матур, бик якын дустлашуларыннан гыйбарәт булып бетәдер. Әсәрдәге идея – татарның яңа тормышында көч, зур өмид күрсәтүдер. Мин үземнең әсәргә һәм андагы идеягә, идеянең ясалуына карашымны әлегә әйтмим.

«Тигезсезләр» сәхнәдә күңелле, тәэсирле генә чыкты. Ялыгуфәлән бер дә хис ителмәде. Артистлар хакында әйтeләчәк сүзем булса, Сафа – Сакаев[3] муаффәкыятьле уйнады. Аның үзен иркен тотып, алган ролен аңлап уйнавы дикъкатьне җәлеп итәрлек. Гомәр – Иманский[4] аерым осталык – мәһарәт белән уйнады. Ул әсәрдә биреләчәк

[1] Истигъфар – ярлыкауны сорау, гафу үтенү.

[2] Изһар кылганда – белдергәндә.

[3] Сакаев – Нури (Нуретдин) Нәбиулла улы Сакаев (1885–1927), драма актеры, режиссер, Хезмәт Герое (1926).

[4] Иманский – Вәлиулла Гайназар улы Мортазин-Иманский (1885–1938), драма актеры, режиссер, БАССРның халык артисты (1922), РСФСРның атказанган артисты (1935).

Гомәрне чын мәгънәсе белән ясап чыгарды. Сәлимә – Болгарская[1] хакында да матур гына сүз әйтергә мөмкин: ул һичбер урында уенына кимчелек хис иттермәде. Габдулла – Үтәйнең тупас, Галиев – Мангушев[2] уены бик төче килеп чыкты.

Иң мәсьүлиятле[3], зур рольләрне Таҗдарова[4], Сөләйман мөхәррир үтәделәр. Таҗдарованың аз вакыт эчендә бик күп тәрәккый иткәнлеге сизелсә дә, мәгаттәәссеф[5], әсәрдә бирелерлек, ясалырлык Рокыяны эшләп чыгара алмады. Сөләйманны Тинчурин[6] канәгатьләнерлек уйнады дип булмый. Ул, бердән, сүзне йота, икенчедән, хәрәкәт вә кыланышларында даирәсеннән чыга, аннан соң гримы да муаффәкыятьсез[7]. Гөлчәһрә – Иманская[8] өмид иткәннән дә, гадәттәгедән күп яхшы уйнады. Ул үзенең фаҗигалы хатирәләре хакында булган сүзләрне ерып чыгар дип уйлау бик читен төсле иде.

*Ә.Ш.*
*(«Йолдыз». 1915. 12 февраль (№ 1368))*

*Басмага әзерләде:*
***Ханнанова Гөлчирә Мәхмүт кызы,***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының текстология бүлеге фәнни хезмәткәре*

[1] Болгарская – Гөлсем Болгарская, чын исем-фамилиясе – Өммегөлсем Муса кызы Мостафина (1891–1968), драма актрисасы, ТАССРның халык (1923), РСФСРның атказанган артисткасы (1925).

[2] Мангушев – Габдрахман Габделкәрим улы Мангушев (1887–1919) – актер, журналист, драматург.

[3] Мәсьүлиятле – җаваплы.

[4] Таҗдарова – Нәгыймә Таҗдарова (Нәгыймә Әхмәдулла кызы Әхмәдуллина, 1888–1947), драма актрисасы, ТАССРның халык (1939), РСФСРның атказанган (1940) артисты.

[5] Мәгаттәәссеф – кызганычка каршы.

[6] Тинчурин – Кәрим Гали улы Тинчурин.

[7] Муаффәкыятьсез – уңышсыз.

[8] Иманская – биредә сүз Мәрфуга Иманская (Мәрфуга Мортазина, 1890–1928) турында бара булса кирәк.

УДК 81'373

***Э.Х. Кадирова***

## ГАЛИМӘНЕҢ ЮБИЛЕЕ УҢАЕННАН

***(Резеда Рәхимовага – 90 яшь)***

Трудовая биография Резеды Каюмовны Рахимовой, которой 2 мая 2023 года исполнилось девяносто лет, связана с Институтом языка, литературы, искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан. Статья посвящена изучению научной деятельности ученого, имеющего монографии, многочисленные статьи, относящиеся к области лексикологии, лексикографии и терминологии.

**Ключевые слова:** Резеда Каюмовна Рахимова, татарский язык, языковед, лексикология, лексикография, терминология.

The work biography of Reseda Kayumovna Rakhimova who turned ninety on May 2, 2023, is associated with the Institute of Language, Literature, Art. G.Ibragimov of the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan. The article is devoted to the study of the scientific activity of this scientist who has monographs, numerous articles related to the field of lexicology, lexicography and terminology.

**Keywords:** Reseda Kayumovna Rakhimova, Tatar language, linguist, lexicology, lexicography, terminology.

Резеда Каюм кызы Рәхимова үзенең ярты гасырга якын гомерен фәнгә багышлады. Ул Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының тел белеме бүлегендә лаборант вазифасыннан башлап өлкән фәнни хезмәткәр дәрәҗәсенә кадәр үсеп, бай фәнни мирас калдырды. Галимә татар халкы арасында күпсанлы фәнни экспедицияләрдә катнашып, халкыбызның борынгыдан килгән һөнәрләрен өйрәнеп, үзенең хезмәтләре аша, аларны яңадан халыкка кайтарды.

Резеда Каюм кызы Рәхимова 1933 елның 2 маенда ТАССРның Арча районы Урта Пошалым авылында дөньяга килә, авылдагы җидееллык мәктәптә, Казан һәм Арча педагогия училищеларында белем ала. 1952–1954 елларда Иске Төрнәле, Урта Пошалым җидееллык мәктәпләрендә укытучы булып эшли.

Булачак галимә 1954 елда Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетына татар теле һәм әдәбияты бүлегенә керү имтиханнары бирә. Ул I–II курсларда укыганда ук Латыйф Җәләй рекомендациясе белән Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты фәнни хезмәткәрләре Нәҗия Борһанова, этнограф Рәмзия Мөхәммәдовалар белән бергә, Мордовиядә яшәгән татарларның сөйләшен, көнкүреш, гореф-гадәтләрен өйрәнү экспедициясендә катнаша. 1959 елда университетны тәмамлагач, Л. Җәләй яшь белгечне әлеге институтның тел секторына эшкә чакыра.

Резеда Рәхимова 1965 елда аспирантурага кабул ителә. Ул аспирант елларында, республика районнарына экспедицияләргә барып, һөнәрчелек һәм кәсепләр турында бай материал туплый. Тикшеренүләр нәтиҗәләре буенча, 1975 елда ул күренекле галимә Ләйлә Таһир кызы Мәхмүтова җитәкчелегендә «Татар теленең тукучылык, кием-салым, баш киемнәре белән бәйле профессиональ лексикасы (Казан арты материалында) (Профессиональная лексика татарского языка по ткачеству, одежде, головным уборам (на материале Заказанья)» темасына кандидатлык диссертациясен тәкъдим итә. Ул аны уңышлы яклаганнан соң да күпчелеге кул хезмәте белән бәйле булган югалып баручы һөнәрләр һәм кәсепләр турында материал җыюын дәвам итә, алар турында күләмле, тирән эчтәлекле мәкаләләр бастыра. Мәгълүм булганча, һәр төр хезмәтнең яки һөнәрчелекнең үзенә хас сүзләре бар. Ә һөнәрчеләр эшендә махсус мәгънәдәге бу сүзләр шул профессия кешесенә, шул һөнәрчегә генә билгеле, аларның үз эш процессында гына кулланыла. Мондый сүзләр – профессиональ сүзләр дип аталалар һәм аларның кулланылышы чикле, еш кына аерым һөнәр өлкәсе белән чикләнгән. Галимәнең һөнәрчелекнең төрле өлкәләренә караган күпсанлы мәкаләләре бар. Аларда татар сөйләшләрендә сакланган кыйммәтле материаллар, кызыклы фактлар урын ала һәм алар татар тел белемендә, татар диалектологиясендә булган аерым мәсьәләләрне ачыклауда зур әһәмияткә ия. «Казан арты сөйләшләрендә тукучылык лексикасы» [Рәхимова, 1974], «Названия головных уборов» [Рәхимова, 1980], «Из древнетюркского пласта кожевенной лексики татарского языка» [Рахимова, 1986], «Татар телендә мех һәм күн эшкәртү лексикасы» [Рәхимова, 1999], «Мамык шәл бәйләүгә караган лексика» [Рәхимова, 2000] кебек мәкаләләрендә галимә сүзнең диалекталь вариантларын да калдырмыйча өйрәнә, аларны әдәби вариантлары белән чагыштыра, лексеманың этимологиясенә, килеп чыгу тарихына экскурслар ясый. Авторның хезмәтләре бай фактик материалга нигезләнә. Мәсәлән, «Мамык шәл бәйләүгә караган лексика» мәкаләсендә Арча районы Яңа Кенәр, Иске Кенәр, Урта-, Югары-, Түбән Пошалым, Күлтәс һ.б.; Балык Бистәсе районы Котлы Бөкәш, Зәңгәр Күл, Күгәрчен һ.б.; Мамадыш районы Ишки; Саба районы Шәмәрдән; Чистай районы Иске Шәйморза, Мөслим; Буа районы Черки Кильдураз; Зеленодол районы Олы Карауҗа; Октябрь районы Киекле; Лаеш районы Пәрәү; Әгерҗе районы Исәнбай; Минзәлә районы һ.б. авыллардан җыелган мисаллар чыганак булып хезмәт итә [Рәхимова, 2000, б. 125]. Әлеге мәкаләдә бу һөнәрнең тарихы һәм таралышы турында бай һәм кызыклы мәгълүмат китерелә һәм шул өлкә атамаларына анализ бирелә.

Татар халкы тарихында ат мөһим урын алып тора. Борын заманнарда көндәлек тормышны аттан башка күз алдына да китереп булмаган. Алар йөк ташу, транспорт хезмәтен үтәгәннәр. Татар телендә атның төсенә, тышкы кыяфәтенә, җенесенә, яшенә, токымына бәйле лексиканың бай булуы, атка караган гыйбарәләрнең күплеге күренә.

Р. Рәхимованың Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты җыентыкларында басылган «Терминология сняряжений верховного коня в татарском языке» [Рахимова, 1992] һәм «Терминология сняряжений упряжного коня в татарском языке» [Рахимова, 1998] мәкаләләре лексиканың шушы әһәмиятле төркемен өйрәнүгә багышлана. Бу тикшеренүдә соңгы елларда, атны техникага алыштыру сәбәпле, юкка чыгып барган сүзләр төркеменә автор тарафыннан тирән анализ бирелә.

Галимә һөнәрчелек атамаларының тәрҗемә әдәбиятта, фәнни мәкаләләрдә, сүзлекләрдә бирелешенә дә игътибар итә [Рәхимова, 1976; Рахимова, 1990], очраган ялгышларның төрләрен билгели, аларны дөрес куллану мәсьәләсен карый. Автор фәнни һәм матур басма әдәбияттан, экспедицияләрдә җыелган материаллар буенча кайбер һөнәри атамаларның әдәби стиль өчен уңышлы вариантларын тәкъдим итә: Мәсәлән, «Татарча-русча сүзлек» тә [ТРС, 1966] тә *торбыча* (см. тубырча) сүзен *моталка, мотовило* дип тәрҗемә иткәннәр. Р. Рәхимова *дуплянка* (яки *тюрик*) вариантын тәкъдим итә. Автор киләчәктә сүзлектә аларны аңлатканда искә алынырга тиеш дип тапкан кайбер фикерләре белән дә уртаклаша [Рәхимова, 1976, б. 52–64].

1983 елда Татарстан китап нәшриятында Р.К. Рәхимованың «Татар теленең һөнәрчелек лексикасы» дигән китабы басыла [Рәхимова, 1983]. Аерым профессия, һөнәр-кәсеп ияләренең сүзләрендә төрле чорлардагы теге яки бу халыкның тарихы, культура дәрәҗәсе чагыла, ул сүзләр кыйммәтле тарихи-этнографик материал булып хезмәт итәләр. Хезмәт 1965–1970 елларда Казанда, Лаеш, Мамадыш, Алабуга районнарында оештырылган экспедиция материалларына нигезләнә. Моннан тыш, Р. Рәхимова этнографик, тарихи, сәнгать белеме, техник әдәбиятка караган хезмәтләрдән файдалана. Автор тукучылыкка, тегү кәсебенә, баш киемнәре һәм аяк киемнәре эшләүгә караган терминнарны мәгънә ягыннан төркемли, атамаларның ясалу ысулларын актырта, башка төрки телләрдәге, диалектлардагы вариантлары белән чагыштыра. Китапның гомуми кыйммәте шунда: биредә татар теленең профессия атамалары бай тел материалларына таянып, тиешле фәнни югарылыкта карала. Кушымтада һөнәрчелек лексикасы кулланылган халык мәкальләре, табышмаклар һәм җырлар китерелә. Китап бизәк һәм чигү үрнәкләре белән тасвирланган.

Күп кенә башка галимнәребез кебек үк Резеда Рәхимова үзенең лексикологик тикшеренүләрен лексикографик практика белән ныгытып бара. Резеда Каюм кызы тикшеренү процессында экспедиция юлы белән һәм төрле басма чыганаклардан туплаган тукучылык һәм тегүчелек атамаларын җыеп, «Татарча-русча тармак сүзлеге»н әзерләп тәкъдим итә [Махмутова, 1986, с. 5]. Хезмәт шактый еллар узгач, яңа материал белән баетылып, 2018 елда «Татарча-русча тукучылык һәм тегүчелек атамалары сүзлеге» исеме белән басылып чыга [Рәхимова, 2018]. Хезмәттә тукучылык һәм тегүчелек атамалары – тукыма төрләрен, кием-салым һәм аның өлешләрен, эрләү, туку, тегү

коралларын һәм әсбапларын, аларның өлешләрен, тукыма әзерләүдә кулланыла торган үсемлекләр, чималны тукуга әзерләү, бизәкләрне, җепләрне, аларның төрләрен, тегү эшенең төрле стадияләрен атаган 2844 берәмлек теркәлгән. Бу сүзлекнең беренче өлешендә – тукучылык атамалары, икенчесендә тегүчелек атамалары китерелә. Шул рәвешчә, сүзлек халык телендә яшәп килгән бай лексик катламны теркәве, югалып барган атамаларның семантикасын ачып бирүе белән әһәмиятле. Сүзлеккә кушымта итеп теркәлгән туку үрнәкләренең фотолары һәм төрле станнарның рәсемнәре киң катлам укучыларда да, тармак белгечләрендә дә зур кызыксыну уята.

Татар теле бүлегендә лаборант булып эшләү дәвереннән үк тел тарихына караган кулъязмаларны уку, гарәп хәрефе белән язылган китапларны өйрәнү Резеда Рәхимованың күз уңында була. Ул һөнәрчелек лексикасын тикшерү барышында К. Насыйриның «Санаигъ галвания» китабына мөрәҗәгать итә. Бу хезмәт гарәп әлифбасы алмашыну сәбәпле, озак еллар укучыга тәкъдим ителми килә. Анда зәркән сәнгатендә кулланыла торган даими гальваник электр тогы ярдәмендә металл әйберләрне затлы металлар (алтын, көмеш, җиз) белән каплату технологиясе турында мәгълүмат китерелә. Осталар үз һөнәрләре серләрен саклаган ул чорларда Каюм Насыйриның бу китабы кабатланмас хезмәт була. Максатчан рәвештә профессиональ лексиканы өйрәнгән Р. Рәхимова хезмәтнең кыйммәтен аңлап, язылуына 100 ел уңае белән аны рус графикасына нигезләнгән гамәлдәге әлифбага күчереп бирә. Шулай ук гарәп алынмаларының үз битендә үк аңлатмаларын китерә, текстны русчага тәрҗемә итә, К. Насыйри кулланган терминнарның русчага тәрҗемәсен бирә. К. Насыйриның бу хезмәтенә Р.К. Рәхимованың ювелир лексиканы анализлауга багышланган монографиясе килеп тоташа. Аның «Лексика и словарь татарского ювелирного дела» [Рахимова, 2002] монографиясендә татар зәркән эшенең тарихы чагылдыра. Ювелирлык лексикасын ювелир металлар, кыйммәтле ташлар, минераллар, эшләнмәләр, инструментлар, эш процессларын берләштерүче тематик төркемнәргә бүлеп, лингвистик күзлектән анализ бирелә. Китапта ювелирлык терминнарының татарча-русча сүзлеге, алар кергән халык авыз иҗаты үрнәкләре кушымта рәвешендә китерелә.

Туган телнең төзеклеге, камиллеге мәсьәләләре каралган «Бер чиктән икенче чиккә (Үзгәртеп кору чорында публицистик терминнар)» [Рәхимова, 1990], «Общественно-политические термины в публицистике в период перестройки и развитие терминологии татарского языка за последние два десятилетия» [Рахимова, 1991], «Татар теле терминологиясенең формалашуында тарихи факторларның роле» [Рәхимова, 1992], «Яңа шартларда алынма сүзләрнең ялгыш кулланылышы турында» [Рәхимова, 2002] мәкаләләрендә Р. Рәхимованың эчтәлекле күзәтүләре, кыйммәтле фикерләре урын ала. Мәсәлән, санап киткән мәкаләләрнең соңгысында галим татар теле терминологиясенең үсеш юнәлешләренә тарихи факторларның йогынтысы

турында сүз алып бара һәм социаль-тарихи факторларның борынгы һөнәрчелек терминнарында чагылуына туктала. Кайчакта аерым һөнәрчелек терминнары үзләре дә билгеле бер тарихи проблемаларны, мәсәлән, халыкның культурасын, башка халыклар белән мөнәсәбәтен аңлату чыганагы булып торалар. Шуңа мисал итеп, автор болгар күне атамасын китерә [Рәхимова, 1992: 414].

Галимә озак еллар Институтның лексикография бүлегендә эшли. Үз чоры өчен татар әдәби теленең иң тулы сүзлек хәзинәсе булган «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»н төзүче авторлар исемлегендә Р.К. Рәхимова да бар [ТТАС, 1977]. Ул шулай ук бертомлык «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге», ике томлык «Татарча-русча сүзлек»ләрне [ТРС, 2007] төзүдә катнаша.

Резеда Каюм кызы Рәхимованың татар гуманитар фәнендә, аерым алганда тел белемен үстерүдә лаеклы өлеше бар, аның монографияләре, мәкаләләре, алардагы фәнни табышлар киләчәк буын галимнәр өчен бу өлкәдә нигез булып тора.

**Әдәбият**

*Махмутова Л.Т.* Татарское языкознание в ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова КФАН СССР за 25 лет (1961–1986). Краткий обзор // Исследования по лексике и грамматике татарского языка. Казань, 1986. С. 3–13.

*Рахимова Р.К.* Названия головных уборов // Советская тюркология. 1980. № 4. С. 91–99.

*Рахимова Р.К.* Из древнетюркского пласта кожевенной лексики татарского языка // Исследования по лексике и грамматике татарского языка. Казань, 1986. С. 57–70.

*Рахимова Р.К.* Наблюдения над подачей и переводом некоторых терминов в толковом и двуязычных словарях татарского языка // Двуязычие: типология и функционирование. Казань, 1990. С. 112–121.

*Рахимова Р.К.* Общественно-политические термины в публицистике в период перестройки и исследования по терминологии татарского языка за 70–90 гг. XX столетия (XX) // Функциональное развитие татарского языка в период перестройки. Казань, 1991. С. 34–45.

*Рахимова Р.К.* Терминология сняряжений верховного коня в татарском языке // Формы взаимодействия татарского и русского языков на современном этапе. Казань, 1992. С. 43–55.

*Рахимова Р.К.* Терминология сняряжений упряжного коня в татарском языке // Проблемы функционирования, диалектологии и истории языка. Казань: Фикер, 1998. С. 90–97.

*Рахимова Р.К.* Книга Каюма Насыри «Санаигъ галвания»: транслитерация, лексика и словарь. Казань: Изд-во «Иман», 2002. 116 с.

*Рахимова Р.К.* Лексика и словарь татарского ювелирного дела. Казань: Фикер, 2002. 192 с.

*Рәхимова Р.К.* Казан арты сөйләшләрендә тукучылык лексикасы // Материалы по татарской диалектологии. Казань, 1974.

*Рәхимова Р.К.* Һөнәрчелек атамаларының тәрҗемә әдәбиятта кулланылышы һәм сүзлекләрдә бирелеше // Вопросы лексикологии и лексикографии татарского языка. Казань, 1976. С. 52–65.

*Рәхимова Р.К.* Татар телендә һөнәрчелек лексикасы. Казан: Татар. кит. нәшр., 1983. 160 б.

*Рәхимова Р.К.* Бер чиктән икенче чиккә (Үзгәртеп кору чорында публицистик терминнар) // Социалистик Татарстан. Казан. 1990. 7 окт.

*Рәхимова Р.* Татар теле терминологиясенең формалашуында тарихи факторларның роле // Языки, духовная культура и история тюрков: Традиции и современность: Тр. междунар. конф. (9–13 июня, 1992. Казань): в 3-х томах: Т. 1. Казань., 1996. С. 211–214.

*Рәхимова Р.К.* Яңа шартларда алынма сүзләрнең ялгыш кулланылышы турында // Актуальные вопросы татарского языкознания. Казань, 2002. Б. 142–147.

*Рәхимова Р.К.* Татарча-русча тукучылык һәм тегүчелек атамалары сүзлеге = Татарско-русский словарь лексики ткачества и швейного дела. Казань: ИЯЛИ, 2018. 208 с.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: өч томда. 1 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 1977. 476 б.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Казан: Матбугат йорты, 2005. 521 б.

Татарско-русский словарь: в 2-х томах. Т. 1. Казань: Магариф, 2007. 726 с.

***Кадирова Энҗе Хәнәфи кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының гомуми лингвистика бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

# ГАЯЗ ИСХАКЫЙ КӨНДӘЛЕКЛӘРЕ

**(Исхакый Г. Көндәлекләр: 3 китапта. 1 нче китап: 1919–1920 / төз., текст., иск. һәм аңл. әзерл.: Ә.Х. Алиева, Ф.Г. Фәйзуллина, Г.М. Ханнанова; кереш сүз авт. Д.Ф. Заһидуллина. – Казан: ТӘһСИ, 2023. – 300 б. китабына рецензия)**

Күренекле язучы, җәмәгать эшлеклесе, сәясәтче Гаяз Исхакыйның мирасын татар халкына кайтару эше дәвам итә. Бу юнәлештә әдипнең тууына 145 ел тулу уңаеннан Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты фәнни хезмәткәрләре Ә.Х. Алиева, Ф.Г. Фәйзуллина һәм Г.М. Ханнанова тарафыннан әзерләнгән Г. Исхакый көндәлекләренең беренче томы басылып чыгу – күркәм эшләрнең берсе.

Билгеле булганча, язучы гомеренең яртысын диярлек үз Ватаныннан читтә уздыра. Яңа басылып чыккан көндәлекләр Г. Исхакыйның нәкъ менә шушы дәвер язмышының бер өлешен яктырта. Китапка барлыгы 16 дәфтәр тупланган. Биредә әдипнең 1919 елның 26 апреленнән алып 1920 елның 10 мартына кадәр Токиодан Парижга барганда юлда күргәннәре тасвирлана. Шуңа күрә бу басмага кергән язмаларны юлъязма көндәлекләр дип атарга да мөмкин. Бу уникаль көндәлекләрдә гадәти сәфәр бәян ителеп кенә калмый, ә милләтенең бәйсезлеге өчен көрәшкә кузгалган юлда татар әдибенең төрле газаплар аша узуы да сөйләнә: *«Без хәзер, үземезгә йөкләгән вазифаны үтимез дигән булып, Европага чыгып барамыз. Андагы мәнфәгатемезгә каршы аз гына булса да, бер эш эшли алырмызмы, әллә юкмы – бер Алла белә. Менә хәзер чиләкләп коя торган ягмур астында хатты истиваның (экваторның) даирәсенә кереп барамыз. Без хәзер үземезнең Казаннан утыз биш дәрәҗә җәнүбтә (көньякта), Кытай диңгезендә хатты истивага таба хәрәкәт итәмез. Тыш, безнең милләтнең истикъбале (киләчәге) кебек, дөм караңгы... Утырырга, торырга урынымыз юк. Язарга, укырга йиремез юк. Бу хатны чүгәләп язам. Менә инде тугыз тәүлектән бирле юлда. Әле барамыз дигән бер ноктага барып җиткәнемез юк. Бу тыгызлык, бу сасылык, бу эсселектә, бу начар ашау, начар йоклау, көн буе аягүрә торып баруга күпмегә чыдармыз?»* (б. 161–162). Бу – ачынып язган юлларның бер өлеше генә. Шулай булуга да карамастан, Г. Исхакый үз эшенә, идеясенә, көрәшче дусларына ышана, өмет баглый. Ул татар милләтенең якты киләчәге турында хыяллана һәм бу максатка ирешүдә үзенең җаваплылыгын тоеп эш итә, алга бара.

Көндәлекләрнең беренче дәфтәре сакланмаса да, шунысын билгеләргә мөмкин: әлеге дәфтәрләрне Г. Исхакый туган җирен калдырып чыгып китәргә туры килгәч яза башлаган. Әйтерсең лә әдип күңеле белән әлеге сәфәрнең үз язмышында яңа бер этапны башлап җибәрүен сизенә. Кереш сүздә галимә Д. Заһидуллина Г. Исхакыйның интуициясе зур булу, аның вакыйгаларны алдан белдергән төшләр

күрүе, аларга ышанычы сизелеп торганын да ассызыклап уза. Болар барысы да язучының үзенчәлекле шәхес, татар халкының кабатланмас бер вәкиле булуын раслап тора. Кайда гына булмасын, язучы үзен татар милләтенең горур улы буларак тәкъдим итә, кирәк икән, шул уңайдан үзенең кырыс һәм туры сүзен әйтми калмый. Әлбәттә, көндәлекләрне укыганда укучыны авыр бер халәт баса, чөнки Гаяз Исхакый Япониядән Франциягә юл тоту барышында һәрдаим бу эшләрне тәмам иткәннән соң туган иленә, туган нигезенә кире кайту турында хыяллана. Укучы исә алдан белеп тора: язучы туган җиренә инде беркайчан дә әйләнеп кайтмаячак.

Көндәлекләрнең тагын бер уникаль ягы – мәгълүматка бай булуда. Биредә төрле илләр, милләтләр, аларның яшәеше, мәдәнияте, мәгарифе, менталитеты һ.б. турында «татар күзе» аша бәян ителә. Әлбәттә, бу – катгый, тәнкыйди караш. Г. Исхакый башкача булдыра да алмый. Тик шулай да, тәнкыйть сүзе барыбер үз милләтеңнең җитешсез якларын аңлау, алга таба тәрәккыят итү юлында хаталарны булдырмау һәм кимчелекле якларны төзәтү рәвешендә кабул ителә. Көндәлекләр Г. Исхакыйның ни дәрәҗәдә киң карашлы, эрудицияле, белемле, укымышлы булуын тагын бер раслап тора.

Юлъязма көндәлекләрдә Г. Исхакыйның язучылык сәләте ачык сиземләнә. *«...әдип нечкә күңелле, зәвыклы, матурлыкка сизгер чын рәссам булып калкулана... Көндәлекләр әдәби әсәр кебек укылалар»,* – дип билгеләп уза кереш сүз авторы (б. 15). Табигать, диңгез, шәһәр күренешләрен тасвирлаганда язучының тел байлыгына тагын бер кат сокланасың: *«Көн бик матур, диңгез гомердә дуламаг кебек тын, саф. Һава елы, кояш йомшак, мәхәббәтле. Җил бик аз, ул диңгезгә сөеп кенә, кичәге дулаудан алган җәрәхәтен төзәтер өчен кебек кенә, акрын гына, өф итеп кенә өрә. Диңгез дә аңгарга каршы иркәләнеп, назланып, елмаеп кына җавап бирә»* (б. 220–221). Шул ук вакытта ул үзенең күңелен төшергән күренешләрне дә урап узмый, ә ачык итеп тасвирлап бирә.

Бүгенге көнгә кадәр Г. Исхакый укучыга, нигездә, язучының унбиш томлыгына кертелгән әсәрләре, публицистик язмалары, хатлары аша таныш иде. Көндәлекләрдә тупланган мәгълүмат исә томнарга кергән кайбер материалларны яңача аңлатырга, бәяләргә мөмкинлек тудыра. Әдип тормышының хронологиясен булдыру юнәлешендә эш башлап җибәрүгә юл ачыла, Г. Исхакый энциклопедиясе өстендәге эшнең нигез ташлары салына.

«Әлбәттә, һәр шәхси документ кебек үк, Г. Исхакый көндәлекләре дә – субъектив чыганак. Шулай да традицион мөселман тәрбиясе алган, милли азатлык хәрәкәте юлбашчыларының берсе булган киң карашлы татар зыялысының күзәтүләре шактый кызыклы», – дип билгеләп уза көндәлекләрне басмага әзерләүдә катнашкан галимә Г.М. Ханнанова [Ханнанова, б. 152]. Көндәлекләр язучының холкын аңлауда, аны шәхес буларак ачуда ярдәм күрсәтәчәк. Шул ук вакытта әдип үзе әлеге көндәлекләрнең әһәмиятен васыятьнамәсендә

билгеләп узган була. Бу хакта басманың беренче битләрендә үк мәгълүмат бирү аеруча мөһим.

Әлеге көндәлекләр Г. Исхакый иҗатын өйрәнүчеләр өчен генә түгел, ә киң катлау укучылар – телчеләр, тарихчылар, җәмгыять фәне белгечләре һ.б. өчен дә кызыклы чыганак булып тора. Алар татар эмигрантлары, чит илләрдә яшәгән татар һәм башка төрки халыкларның язмышы турында да мәгълүмат бирәләр. Моннан тыш, 100 ел элек булып узган хәлләрне Г. Исхакый белән бергә күрергә, кичерергә ярдәм итәләр. Милләт тарихына, язмышына, аның бөек улы Г. Исхакый һәм күп кенә милләттәшләребезнең күркәм шәхесләренә битараф булмаган һәрбер укучы, бу көндәлекләр белән танышканнан соң, үзе өчен шактый күп мәгълүмат туплар, рухи ризык алыр дип ышанасы килә.

Төрле шартларда язылган дәфтәрләрне гарәп графикасындагы кулъязма рәвешеннән кирилл хәрефләренә күчергән, текстларга аңлатма һәм искәрмәләрне әзерләгән текстология бүлеге хезмәткәрләренә аерым рәхмәт әйтеп узарга кирәк. Китап ахырында урнаштырылган Кушымта да әлеге басманы баетып тора. Ышанасы килә, Г. Исхакый көндәлекләренең калган ике томы да тиз арада җәмәгатьчелеккә тәкъдим ителеп, каләм остасының тормыш юлын һәм эшчәнлеген яктырту, өйрәнү, халыкка кайтару юлында үз бурычын үтәрләр.

**Әдәбият**

*Ханнанова Г.М.* Гаяз Исхакый көндәлекләрендә чит ил иҗтимагый-мәдәни тормышы һәм вакытлы матбугаты // Татароведение в ситуации смены парадигм: теория, методология, практика: материалы Международного научно-практического семинара, посвященного 145-летию со дня рождения классика татарской литературы Гаяза Исхаки / сост. Л.Р. Надыршина. Казань: ИЯЛИ, 2023. С. 152–155.

***Галиева Ләйсән Шәүкәт кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әдәбият белеме бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

# ШАЛЯПИН В КАЗАНИ. ЖИВОПИСЬ, ГРАФИКА, СКУЛЬПТУРА. КАТАЛОГ. К 150-летию со дня рождения Ф.И. Шаляпина. – Казань: ИЯЛИ, 2023. – 80 с.: ил. китабына бәяләмә

Ф.И. Шаляпинның тууына 150 ел тулуны бәйрәм итүгә әзерлек һәм аны үткәрү буенча Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнехановның 2022 елның 26 июлендәге Указы белән расланган төп чаралар планы нигезендә нәшер ителгән китап басмага Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Сәнгать үзәге хезмәткәрләре тарафыннан әзерләнде. Төзүчеләр һәм каталогның кереш мәкалә авторлары – сәнгать фәннәре докторы Р.Р. Солтанова һәм сәнгать фәннәре кандидаты О.Л. Улемнова. Каталогны әзерләүдә сәнгать фәннәре кандидатлары Н.В. Герасимова һәм Л.М. Шкляева катнашты. Макеты Институтның нәшрият бүлегендә Д.-М. Р. Галиуллина һәм Н.Т. Абдуллина тарафыннан эшләнде. Китап Татарстан Фәннәр академиясе нәшриятында басылып чыкты.

Каталогта беренче тапкыр нәкыш, графика һәм скульптура әсәрләре бергә туплап бирелә, аларда Казанда туып үскән бөек рус җырчысы Ф.И. Шаляпин (1873–1938) образы һәм тормышының төрле сәхифәләре ачыла, аларның бер өлеше бөек җырчының туган каласы белән бәйле булып, Казан музейларында һәм шәһәр киңлегендә тәкъдим ителгән, шулай ук Татарстан рәссамнары тарафыннан әлеге басма өчен махсус язылган.

Каталогта тасвирый материал «Нәкыш», «Графика», «Скульптура. Мультимедиа» бүлекләре эчендә хронологик тәртиптә бирелә. Бу Татарстан тасвирый сәнгатендә төрле тарихи этапларда Ф.И. Шаляпин образын шәрехләү үзенчәлекләрен ачык күрсәтергә мөмкинлек бирә. Альбом-каталог өлеше О.Л. Улемнованың «Федор Шаляпин Казанның тасвирый сәнгатендә», Р.Р. Солтанованың «Скульптурада, медальер сәнгатендә Ф.И. Шаляпин образы» кереш мәкаләләре белән ачыла.

Каталогта тәкъдим ителгән әсәрләрнең төп өлеше А.М. Горький һәм Ф.И. Шаляпин музее фондларында (ТР Милли музее бүлекчәләре), шулай ук ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда саклана. Нигездә, бу – совет чоры Татарстан тасвирый сәнгатенең әйдәп баручы осталары – рәссамнар В.И. Куделькин, Р.В. Нурмөхәммәтов, А.М. Родионов, Е.А. Симбирин, графиклар Р.А. Госманов, И.К. Колмогорцева, Ю.Б. Лысогорский, Э.Г. Ситдыйков, скульпторлар Н.П. Тузов һәм П.И. Макаров эшләре. Бу әсәрләрнең күбесе А.М. Горькийның һәм Ф.И. Шаляпинның 100 еллык юбилейлары уңаеннан иҗат ителә. А.М. Горькийның Казандагы әдәби-мемориаль музеенда әлеге уңайдан зур чаралар үткәрелә. Совет чорында әлеге музей Ф.И. Шаляпин шәхесенә, А.М. Горькийның дусты буларак,

зур игътибар бирә. Әсәрләр, нигездә, музей заказы буенча языла. Болар – җырчының портретлары, биографиясенең төрле эпизодларына багышланган тематик картиналар, шулай ук Ф.И. Шаляпин тормышы белән бәйле Казан күренешләре. Аларның барысында да Ф.И. Шаляпинның А.М. Горький белән дуслыгына аерым басым ясала.

Совет чорыннан соң Татарстан рәссамнары арасында Ф.И. Шаляпин шәхесе белән кызыксыну кимеде. Музей фондларында В.К. Федоровның ике картинасы (Ф.И. Шаляпин портреты һәм Ф.И. Шаляпин белән А.М. Горькийның икесенең портреты) һәм Ф.Г. Халиковның «1883 елда Казанда Май чабу» дигән киң күләмле матур полотносы гына саклана. Соңгысында халыкның бәйрәм итүе һәм кечкенә Федя Шаляпинның шунда катнашуы күрсәтелә. Казан рәссамнарының остаханәләрендә әлеге тема буенча тагын берничә әсәр булуы ачыкланган, алар арасында Россиянең атказанган рәссамы И.С. Айдаров тарафыннан язылган Явыз Иван образындагы Ф.И. Шаляпин портреты аерылып тора.

Каталогка кертелгән хәзерге әсәрләрнең күп өлешен махсус Россия Рәссамнар берлеге һәм Россия рәссамнары иҗат берлегенең Татарстан бүлекчәләре рәссамнары тарафыннан әлеге проект өчен махсус язылган картиналар тәшкил итә. Төрле буын осталары – ТРның халык рәссамы М.И. Кузнецов, ТРның атказанган рәссамнары И.М. Самакаев, М.В. Самакаева, И.В. Антонова Ф.И. Шаляпин портреты образларын һәм биографиясендәге аерым эпизодларны үзләренчә шәрехләделәр, Казандагы аның исеме белән бәйле урам һәм биналарны сурәтләделәр. Җырчының биографиясен турыдан-туры гәүдәләндерү һәм фоторәсемнәрен күчереп ясау юлыннан китәргә теләмәгән рәссамнарга, башкаларның әсәрләреннән өземтәләр китереп, билгеле образлар һәм символлар белән постмодернистик уенга мөрәҗәгать итү хас. Бу А.Н. Егоров, Е.С. Ермолина, В.В. Карасева, А.Н. Лопаткин, А.А. Петров полотноларында һәм яшь рәссамнар В.Г. Баранов, Е.Ю. Васильева, Р.Л. Маврина графикасында да күренә. Визуаль сәнгатьнең актуаль формалары А.Р. Саргинның (Ильясова) мультимедия композициясендә тәкъдим ителә, аны шул биттәге QR-код ярдәмендә карап була.

О.Л. Улемнованың «Федор Шаляпин Казанның тасвирый сәнгатендә» дигән кереш мәкаләсендә Ф.И. Шаляпинга багышланган музей коллекцияләре (нәкыш һәм графика), шулай ук проект өчен булдырылган хәзерге заман әсәрләре гомумиләштерелә һәм анализлана. Автор Федор Шаляпинның Казан мәдәниятендәге роле һәм урыны, аны тану һәм эндәшмәү тарихының аларда ни рәвешле чагылуын, төрле тарихи чорларда Шаляпин темасын гәүдәләндерүдәге художество алымнарын, рәссамнар кулланган сәнгать чараларының киң палитрасын ачып бирә.

Казан сынлы сәнгатенең Ф.И. Шаляпинга багышланган өлешендә скульптура аерым роль уйный. Ф.И. Шаляпинга беренче һәйкәл 1998 елда нәкъ менә Казанда куела. Аның авторы – Мәскәү

скульпторы А.В. Балашов. Ул шәһәр пространствосының аерылгысыз өлешенә әверелде. Р.Р. Солтанова сүзләренә караганда, скульптор һәйкәл-күзаллау, һәйкәл-идея торгызып, Ф.И. Шаляпин шәхесенең тарихи, гомуммәдәни кыймммәтен күрсәтә алган. Казанда М. Җәлил исемендәге Татар академия опера һәм балет театры тарафыннан үткәрелә торган Ф.И. Шаляпин исемендәге (башта бөтенроссия, аннары халыкара) опера фестивале медальер сәнгате үсешенә яңа этәргеч бирде. Фестиваль өчен кайбер истәлекле медальләр (хәзер алар театр музеенда саклана) эшләгән Казан скульпторы И.Н. Башмаков – аның күренекле вәкилләренең берсе. Хәзерге этапта бу традицияләр яшь скульптор Т.С. Тюрин тарафыннан үстерелә. Ул плакеткада Ф.И. Шаляпин образын гәүдәләндерде. Шулай ук 2023 елда бөек җырчының юбилеен бәйрәм иткән көннәрдә ачылган мемориаль тактаның да авторы – Т.С. Тюрин. Такта урнаштырылган йортның (хәзерге вакытта сакланмаган) флигелендә Ф.И. Шаляпин дөньяга килгән була. Каталогта скульптор З.Х. Мөхәммәдьянованың Ф.И. Шаляпин бюсты өстендә эшләве дә чагылыш тапкан. Бу бюст каталогны әзерләгән вакытта тәмамлану алдында торып, бүгенге көндә А.М. Горький һәм Ф.И. Шаляпин музеена килүчеләрне каршы алып тора.

Р.Р. Солтанованың «Скульптурада, медальер сәнгатендә Ф.И. Шаляпин образы» дигән кереш мәкаләсе Ф.И. Шаляпинның Казандагы дөнья күләмендә беренче һәйкәлен төзү тарихына, совет һәм постсовет чорлары Казан скульпторларының Ф.И. Шаляпин образы өстендә эшләвенә багышлана. Эшнең барлык этап һәм формаларын анализлап, мәкалә авторы болай дип ассызыклый: «...на современном этапе в раскрытии образа великого певца в мелкой пластике наблюдается значительное расширение круга выразительных средств (контррельеф, углубленный контур, чернение), усложнение композиций, пластического языка и фактуры круглых медалей, включение философских, социальных, публицистических аспектов современности».

Шулай итеп, ТР Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге ТӘһТИнең яңа басмасында Татарстан тасвирый сәнгатендә бөек рус җырчысы Ф.И. Шаляпин образын шәрехләү тарихы ачыла, XX гасырның икенче яртысыннан башлап ул Казан рәссамнары иҗатының мөһим өлешенә тәшкил итә, Россиянең һәм Татарстанның хәзерге заман сәнгатендә кабат актуальләшә.

А.Б. Шляпкин тарафыннан башкарылган бизәлеш басманың дәрәҗәсен тагын бер баскычка күтәрә. Ул Казанның борынгы һәм хәзерге фоторәсемнәре нигезендә альбом-каталогның тышлыгын һәм шмуцтитулларын эшләгән: компьютер графикасы чаралары ярдәмендә үзгәртелеп, алар Шаляпин яшәгән чор шәһәрен сагыну атмосферасы тудыралар.

***Тулузакова Галина Петровна,***
*сәнгать фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Сәнгать белеме үзәге фәнни хезмәткәре*

УДК 347.156

***Л.Р. Мортазина***

# ТӨРЕК ГАЛИМНӘРЕ ХЕЗМӘТЛӘРЕНДӘ ТАТАР ХАТЫН-КЫЗЛАРЫ МӘСЬӘЛӘСЕ (Адилхан Адилоглуның «Ceditçilik Dönemi Kazan Tatar Edebiyatinda Kadin Hak VE Hürriyetleri Meselesi» китабына бәяләмә)

В статье дается оценка монографии турецкого исследователя, преподавателя кафедры турецкого языка и литературы Университета Акдениз (Анталия, Турция) Адилхана Адилоглу «Ceditçilik Dönemi Kazan Tatar Edebiyatında Kadın Hak ve Hürriyetleri Meselesi» (Анкара, 2020). Определены концептуальная основа исследования, роль ученого в изучении истории просвещения, проблемы прав и свобод татарских женщин в начале XX века, его вклад в популяризацию татарской литературы и духовного наследия татар в Турции.

**Ключевые слова**: татарские женщины, женский вопрос, права и свободы женщин, татарская литература, просвещение, Адилхан Адилоглу.

The article evaluates the new monograph by Turkish researcher, teacher of the Department of Turkish Language and Literature at Akdeniz University (Antalya, Turkey) Adilkhan Adiloglu «Ceditçilik Dönemi Kazan Tatar Edebiyatında Kadın Hak ve Hürriyetleri Meselesi» (Ankara, 2020). The conceptual basis of the study, the scientist's contribution to the study of the history of education, the problems of the rights and freedoms of Tatar women at the beginning of the twentieth century, as well as to the popularization of Tatar literature and the spiritual heritage of the Tatars in Turkey are determined.

**Keywords:** Tatar women, women's issue, women's rights and freedoms, Tatar literature, education, Adilkhan Adiloglu.

XIX гасыр ахырында мөселман хатын-кызы һәм аның хокуклары, иреге мәсьәләсе Идел-Урал буе, Кырым, Кавказ һәм Урта Азиядә башланып киткән җәдитчелек хәрәкәтенең иң мөһим юнәлешләреннән берсе булып әверелә. Бу күренеш революция елларында аеруча зур яңгыраш ала һәм «хатын-кыз мәсьәләсе» дип атала башлый. Ләкин аңа кадәр үк проблеманың бик күп яклары татар җәмәгатьчелеге, мәгърифәтчеләр тарафыннан күтәрелә. Мөселман хатын-кызларының гаиләдәге, җәмгыятьтәге хәлләре, хокуклары һәм бурычлары, азатлыгы, мәгарифе, бала тәрбиясенә керткән өлешләре кебек мәсьәләләр җәмгыятьтәге иң актуаль проблемаларның берсенә әйләнә. Алдынгы фикерле татар зыялылары белән беррәттән, мәгърифәтче ханымнар үзләре дә хатын-кызны укыту, белемле итү, аларга заманча тәрбия бирү, гаиләдәге хәлләрен яхшырту, бала тәрбияләүдә аңа ярдәм итү, киңәшләр бирүне үзләренең бурычлары итеп алып, шуңа багышланган мәкаләләр, китаплар язалар, вакытлы матбугатта чыгыш ясыйлар, мәктәпләр ачалар, кыз балаларга белем бирәләр.

XIX гасыр ахырында – XX гасыр башында хатын-кыз мәсьәләсенең иң тулы чагылыш тапкан ягы – хатын-кыз мәгарифе, кызлар тәрбиясе. Чөнки, И. Гаспралы сүзләре белән әйткәндә, «Бер милләтнең тәрәккые хатыннарның мәгариф юлына кертелүеннән башка мөмкин түгел» [Ф.К., 1912]. Беренче Россия революциясеннән соңгы елларда мәсьәлә киңәеп, хатын-кызларның гаиләдәге һәм җәмгыятьтәге хокукларын һәм ирекләрен яклау, аларны ирләр белән тигез хокуклы итү проблемаларын үз эченә ала.

Татар хатын-кызларының мәгарифе, азатлыгы, хокуклары, хатын-кызлар хәрәкәте мәсьәләсе М.Х. Гайнуллин, З.Х. Бурнашева, А.Х. Мәхмүтова, Т.Ә. Биктимирова, С.Ф. Фәизов, Д. Брилева, А.М. Хәбибуллина, А.Ә. Зиннәтуллина һ.б. тикшерүчеләрнең хезмәтләрендә шактый җентекле өйрәнелгән. Башка төрки халыкларда хатын-кызлар мәсьәләсенә Л.З. Чубукчиева, Р.А. Мирмаматова, И.А. Мамадалиев һ.б. авторлар игътибар иткән.

Бу мәсьәләнең тарихын өйрәнү татар хатын-кызларының XX гасыр башындагы проблемалары, мәгарифе, әдәбияты үсешенең татарлар арасында гына түгел, башка милләтләр, әйтик, төрек тикшеренүчеләрендә дә кызыксыну уятканлыгын күрсәтә. 2020 елда Төркиядә Адилхан Адилоглуның татар әдәбиятында хатын-кыз азатлыгы мәсьәләсен өйрәнүгә багышланган китабы дөнья күрде [Adiloğlu, 2020]. Автор проблеманы, беренче чиратта, әдәбият белеме фәне күзлегеннән чыгып тикшерә һәм аны XX гасыр башы татар әдәбияты үсешендәге төп үзенчәлекләрнең берсе буларак карый. Ләкин хезмәт гомумән алганда шул чор, татар җәмгыяте, татар хатын-кызы проблемаларына башка милләт, бу очракта бер үк диндәге кардәш халык вәкиле күзлегеннән чыгып якын килүе ягыннан кызыклы. Мәсьәләнең икенче ягы да бар. Проблеманың башка милләт тикшеренүчеләрендә дә кызыксыну тудыруы аның чыннан да төрки дөнья өчен әһәмиятле булуын, игътибарга, һәрьяклап өйрәнүгә, башка милләтләр даирәсендә күрсәтергә лаеклы булуын раслаучы фактор булып тора.

Гомумән алганда, татар халкының мәгарифе, тарихы, теле һәм әдәбияты темасы төрек галимнәренең игътибар үзәгендә торган фәнни проблемаларның берсе дисәк, һич тә ялгыш булмас. Бу уңайдан бер-ике хезмәтне атап китик. Эфе Окчуның, мәсәлән, Россиядәге төрки халыкларда хатын-кызларның хокукларына багышланган хезмәте билгеле [Efe Okcu, 2022]. Фәйза Шаһинның «Сөембикә» журналы материалларына таянып язылган, Идел-Уралда хатын-кызлар хәрәкәтенә багышланган магистрлык диссертациясе шулай ук төрек галимнәре тарафыннан югары бәя алган. Анда «Европада хатын-кыз хәрәкәтенең барлыкка килүе», «Ислам дөньясында хатын-кызлар хәрәкәте», «Идел-Уралда хатын-кызлар хәрәкәте», ««Сөембикә» журналы һәм андагы мәкаләләргә анализ» дигән темалар яктыртыла, журналның библиографиясе тәкъдим ителә [Feyza Şahin, 2012]. Әле бу вакытта «Сөембикә» журналының татар телендә басылган

библиографиясенең дә булмавын искә алганда, бу хезмәтнең никадәр зур әһәмияткә ия булуын күз алдына китерергә мөмкин. Әнкарадагы Хаҗи Бәйрәм Вәли Университетыннан Догукан Өзейнең «Казан татарларының һәм Кырым татарларының теле һәм әдәбияты буенча Төркиядә төрек телендә басылган хезмәтләрнең библиографиясе» [Dogukan Özey, 2019] дигән мәкаләсендә Казан татарлары һәм Кырым татарлары буенча гомуми мәгълүмат (кыскача тарихлары) һәм әлеге милләтләрнең теле, әдәбияты буенча Төркиядә дөнья күргән китаплар (барлыгы 96 исемдә), мәкаләләр һ.б. хезмәтләрнең исемлеге тәкъдим ителә. Алар арасында төрек авторларының, Төркиядә яшәп иҗат итүче татар галимнәре һәм язучыларының (Н. Дәүләт, Р. Яруллина-Йылдырым, Ч. Зариф-Четин һ.б.), шулай ук Ф. Ганиев, Ф. Урманче, И. Надиров һ.б. галимнәребезнең хезмәтләре, татар классикларының (Ф. Кәрими, Г. Исхакый, Г. Тукай һ.б.) соңгы елларда басылып чыккан китаплары бар. Боларга өстәп, татар тематикасына язылган хезмәтләр авторы Исмәгыйль Төркуглының китап һәм мәкаләләрен дә күрсәтергә мөмкин.

Адилхан Адилоглуның «Ceditçilik Dönemi Kazan Tatar Edebiyatında Kadın Hak ve Hürriyetleri Meselesi» дигән китабы, исеменнән күренеп торганча, җәдитчелек чорында татар әдәбиятында хатын-кызларның хокуклары һәм ирекләре мәсьәләсенең чагылышын өйрәнүгә багышланган. Автор әлеге китапта Идел-Урал татарлары тарихының XIX гасыр урталарыннан алып XX гасыр башына кадәр булган чорын – яңарыш хәрәкәтен тикшерә. Шул ук вакытта бу чорга кадәрге һәм соңгырак дәверләр – татар халкының бик борынгыдан алып хәзерге көннәргәчә булган тарихын сурәтләүгә дә зур әһәмият бирә. Темадан бераз читкә кителсә дә, китапның төрек телендә язылуы, һәм, димәк, төрек укучысына адреслануы ягыннан якын килгәндә, бу үз-үзен аклый.

Кереш өлешендә (б. 15–38) Адилхан Адилоглу казан татарлары һәм Татарстан Республикасы, татар халкының этник тарихы, мәгърифәтчелек хәрәкәте, җәдитчелек, кадимчелек, татар хатын-кызларының эмансипациясе кебек мәсьәләләргә бик җентекле тукталa.

Җәдитчелек хәрәкәте турында сүз алып барганда, автор аның, фәндә кабул ителгәнчә, Исмәгыйль Гаспралы исеме белән бәйле булудан элек, Госманлы дәүләтендә, Истанбулда мәйданга чыккан һәм уйлап табылган, бөтен төрки дөньясын каплап алган яңарыш хәрәкәте, яңа уку-укыту системасы булуына басым ясый [Adilhan Adiloğlu, 2020, s. 25, 26]. «Ягъни, – ди ул, – Исмәгыйль Гаспралы бу яңа белем бирү системасын Госманлыдан алган һәм, әлбәттә, үзенең кайбер үзгәрешләрен кертеп һәм беркадәр яхшыртып, үзенең мәмләкәтендә тормышка ашырган» [Adilhan Adiloğlu, 2020, s. 25]. Бу фикерне инкяр итәргә сәбәпләр юк. Чөнки, билгеле булганча, яңа аваз ысулына корылган укыту системасын гамәлгә китергәнче, И. Гаспралы Европада, Төркиядә була, аларның мәктәп, уку-укыту өлкәсендәге тәҗрибәләрен өйрәнә, чит ил педагогларының һәм рус галимнәренең

белем бирү өлкәсендәге иң уңышлы дип тапкан тәҗрибәләренә таянып, төрки халыкларны укытуда яңа ысулга нигез сала.

Беренче бүлек «Идел-Урал төбәгендә татар хатын-кызлары хәрәкәте» дип атала һәм анда автор хатын-кызларның хокуклары һәм ирекләре (хөррияте), татар кызларын укыту, мәктәпләр проблемалары (мөгаллимәләргә булган ихтыяҗ һ.б.), татар хатын-кызлары җәмгыятьләре, Беренче Бөтенроссия мөслимәләр съезды, Төркия матбугатында татар хатын-кызлары хәрәкәтенең чагылышы кебек темаларга мөрәҗәгать итә. Автор китапта киңрәк мәгънәгә ия булган «мөслимә» терминына түгел, ә локаль яктан якын килеп, конкретлаштырып, «татар хатын-кызлары» атамасына өстенлек бирә.

Хезмәттә хатын-кыз мәгарифе, хокуклары мәсьәләләрен күтәреп чыккан татар зыялыларыннан Р. Фәхретдин, Г. Баруди, Ф. Кәрими, М. Бигиев, Г. Буби, З. Кадыйри хезмәтләренә, Камилә Касыймованың 1908 елда басылып чыккан «Ханымнар ислахы» дигән китабына анализ ясала.

Татар мөгаллимәләре һәм кызлар мәктәпләре, мөгаллимәләр җәмгыятьләре һәм конференцияләре, курслары турында язганда, Адилхан Адилоглу Т.Ә. Биктимирова, А.Х. Мәхмүтова, А.Ә. Зиннәтуллина хезмәтләренә, Казанда басылып чыккан «Татар педагогик фикере антологиясе» кебек академик басмалардагы мәгълүматларга таяна, тема белән яхшы таныш булуын күрсәтә.

Татар укучысы өчен китапның «Татар хатын-кыз хәрәкәтенең Госманлы матбугатында чагылышы» дигән өлеше аеруча кызыклы. Автор әлеге мәсьәләгә мөрәҗәгать иткән «Төрек йорты»[1] («Оренбургта кыз сәнәви мәктәбе», «Төрек кызларының мәгариф һәвәсе»), «Сәбилүришад»[2] журналларында басылып чыккан мәкаләләргә тукталып уза. Хәзерге заман төрек тикшеренүчеләреннән Балкан сугышында катнашкан дүрт татар кызы – Өммегөлсем Камалова, Рокыя Юнысова, Мәрьям Якупова, Мәрьям Поташевалар турында язган Шәфика Курназ, XX гасыр башы татар матбугаты материалларына таянып, Россиядәге төрек конгресслары (1905–1917) эшчәнлеген өйрәнгән Нәҗип Хаблемитоглу кебек авторларның хезмәтләренә басым ясый.

«Әдәбиятта һәм матбугатта хатын-кызлар» дип исемләнгән икенче бүлектә автор татар әдәбиятында хатын-кызларның хокуклары һәм ирекләре мәсьәләсенең бирелешенә туктала. Әсәрләрендә хатын-кызлар мәсьәләсенә мөрәҗәгать иткән танылган язучылар Г. Кандалый, М. Акъегетзадә, Г. Ильяси, Ф. Халиди, З. Бигиев, Р. Фәхретдин, С. Максуди, Г. Исхакый, Ф. Кәрими, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов һ.б. белән беррәттән, җәмәгатьчелеккә аз билгеле булган Я. Мамишев,

[1] «Türk Yurdu» журналы – 1911 елдан башлап, Истанбул, Әнкара шәһәрләрендә төрек телендә чыгып килгән басма. Баштагы елларда Йосыф Акчура мөхәррирлек иткән.

[2] «Sebîlürreşâd» – 1908 елда Истанбул шәһәрендә «Sırat-ı Müstakim» исеме астында басыла башлаган журнал. Мөхәррире – Мехмет Акиф. Төрле елларда Йосыф Акчура, Әхмәдмөнир Ибраһимов һ.б. татар авторлары мәкаләләрен бастырганнар.

М. Казанлы кебек авторларның әсәрләренә тәфсилле анализ ясый. «Сөембикә» журналы турында мәгълүмат, татар шагыйрәләре һәм язучы ханымнар, педагоглар Хәнифә Гыйсмәтуллина, Галимә Рәхмәтуллина, Газизә Сәмитова, Галимәтелбәнат Биктимерия, Маһруй Мозаффария, Мәхбүбҗамал Акчурина, Фәхрелбәнат Сөләймания, Хәдичә Сөнгатьзадә (Хәдичә Сәйфетдинова-Шаммасова), Хәбирә Насыйрия һ.б.ның (барлыгы 17 хатын-кыз) тормыш юлларын шактый җентекләп тасвирлый, әдәби әсәрләреннән өзекләр тәкъдим итә. Карашыбызча, китапның шул ягы бик уңышлы: төрек укучысын таныштыру максатында автор текстларны төрек теленә тәрҗемә итеп бирә, шул ук вакытта татар теленең аһәңен тою мөмкинлеген тудыру өчен, татар телендәге вариантны (латин хәрефләре белән) тәкъдим итә. Адилхан Адилоглу шигырьләрнең күбесен әдәбият галиме Мөхәммәт Гайнуллинның «Өмет йолдызлары» (1988) җыентыгыннан алганлыгын әйтә.

Югарыда искәртелгәнчә, Адилхан Адилоглу татар хатын-кызларының азатлыгы һәм хокуклары мәсьәләсен җәдитчелек хәрәкәтенең бер өлеше, юнәлеше буларак карый. Аның нигезендә баштагы чорда кыз балаларны укыту һәм хатын-кызларның гаиләдәге хәлен яхшырту мәсьәләләрен хәл итүне тикшеренүче интеллектуаль хәрәкәт дип атый. 1905 елгы революциядән соң бу хәрәкәт морза (аксөяк) гаиләләреннән булган кайбер ханымнарның, махсус оешмалар һәм җәмгыятьләр төзеп, бу эшне җайга салулары, кыз балаларны укыту, хатын-кызларның социаль хәлләрен яхшыртуга басым ясаулары белән билгеләнә. Алга таба бу оешмалар хатын-кызларның ирләр белән бер үк дәрәҗәдәге хокуклары, хөррияте өчен көрәшне максат иткән хатын-кыз хәрәкәте булып әверелә. Шулай итеп, авторның бик дөрес искәртүенә караганда, XX гасыр башында Идел-Урал буенда татар хатын-кызларының үз инициативалары нигезендә корылган, җәдитчелекнең бер өлеше булып әверелгән хәрәкәтләре барлыкка килә [Adilhan Adiloğlu, 2020, s. 35–37].

Шуңа бәйле рәвештә, дип ассызыклый автор, татар хатын-кызлары арасында язучылар, шагыйрәләр үсә. Моңарчы бары тик ир-атларның хезмәтләрендә генә күтәрелгән хатын-кыз хокуклары һәм хөррияте темасы әдәбият дөньясына аяк баскан хатын-кызларның әсәрләренә үтеп керә. Инде ханымнар үзләре үк кыз кардәшләренә хатын-кыз дөньясындагы проблемаларны, аларны хәл итү юлларын күрсәтәләр. Бу чордагы әдәби әсәрләр татар хатын-кызларының хокуклары һәм азатлыгы мәсьәләсен татар җәмгыяте тормышының көн кадагына чыгаруда зур роль уйныйлар [Adilhan Adiloğlu, 2020, s. 149].

Алда әйтелгәннәргә өстәп, китапның эшләнеше, тышкы кыяфәте турында да берничә сүз әйтергә кирәк. Китапның тышлыгы зәвык белән эшләнгән, күләме шактый зур – 454 битле, фотосурәтләргә бай. Әлбәттә, алар арасында татар укучысына таныш булмаган рәсемнәр юк. Әмма басманың төрек укучысына адреслануын искә

алган очракта, бу фотоларның нинди әһәмиятле роль уйнауларында шөбһәләнергә туры килми.

Китап бик уйлап, фәнни стильнең барлык таләпләренә туры китереп язылган. Анда файдаланылган фәнни әдәбиятка һәм чыганакларга астөшермәләр (текстта) бирелгән, китапның ахырында кулланылган хезмәтләр исемлеге тәкъдим ителгән.

Адилхан Адилоглуның «Ceditçilik Dönemi Kazan Tatar Edebiyatında Kadın Hak ve Hürriyetleri Meselesi» дигән китабы мәгърифәтле татар хатын-кызлары хәрәкәтенең уникаль тарихын барлый, аларның төрки дөньяда тоткан урыннарын билгеләргә мөмкинлек бирә, бүгенге көндә дә төрки кардәшләребезгә үрнәк булып торуларын раслый. Татар халкын һәм аның тарихын, әдәбиятын һәм рухи мирасын дөньякүләм танытуда бу хезмәтнең роле биниһая зур.

**Әдәбият**

*Adilhan Adiloğlu*. Ceditçilik Dönemi Kazan Tatar Edebiyatında Kadın Hak ve Hürriyetleri Meselesi. Анкара: 2020. 454 s.

*Efe Okcu.* Rusya türklerinde kadin haklari meselesi // Genel Türk Tarihi Araştırmaları Dergisi. Cilt 4. Sayı 8. Temmuz 2022. S. 827–838.

*Dogukan Özey.* Kazan tatar ve Kirim tatar türkçesi ve edebiyati üzerine yapilan çalişmalarin bibliyografyasi Türkiye'de // Uluslararası Türk Lehçe Araştırmaları Dergisi (TÜRKLAD). Cilt 3. Sayı 1. 2019. S. 160–206.

*Feyza Şahin.* İdil-Ural'da Kadın Hareketi: Süyümbike Dergisi (1913–1918), Marmara Üniversitesi Türkiyat Araştırmaları Enstitüsü. İstanbul 2012. 153 s.

*Ф.К.* Һиндыстанда беренче ысул саутия мәктәбе // Вакыт. 1912. 29 март.

***Мортазина Ләлә Рәис кызы,***
*педагогика фәннәре кандидаты, ТР ФА Ш. Мәрҗани исемендәге*
*Тарих институтының әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

**2023 елның 15–23 июлендә** Болгарда «Яшәү стиле – Мәдәни код» Этно-Fashion фестивале, «Яңарыш: дастанның заманча укылышы» фестивале белән берләштерелеп, Болгар музей-тыюлыгы территориясендә үткәрелде. «Ага-базар» этнофестивале дә шушы зур чара кысаларында оештырылды. 23 июльдә ачык һавада «Кара пулат» операсы күрсәтелде. Фестиваль кысаларында этномаркет, эшлекле форум, белем бирү чаралары узды, «Хәзинә» галереясында «Мирас һәм традицияләр» күргәзмәсе эшләде.

**2023 елның 1 августында** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Президенты Рифкат Нургали улы Миңнеханов белән очрашу узды. Чара вакытында коллективның төп эшчәнлек юнәлешләре һәм үсеш перспективалары билгеләнде. Институт директоры К.М. Миңнуллин үзенең чыгышында ТӘһСИнең бүген Россиядә татар филологиясе һәм сәнгате мәсьәләләрен һәрьяклап өйрәнү белән шөгыльләнә торган бердәнбер академик оешма булуын ассызыклады, коллектив эшчәнлегенең төп юнәлешләре турында сөйләде. Р.Н. Миңнеханов тел, әдәбият һәм сәнгать мәсьәләләре буенча Татарстанның башка фәнни-тикшеренү оешмалары, югары белем бирү оешмалары һәм Россия Федерациясенең башка субъектлары, төрки илләр, шулай ук республика министрлыклары, ведомстволары белән уртак проектларны тормышка ашыру һәм үзара хезмәттәшлек итү буенча максатчан эш алып бару зарурлыгын аерым билгеләп үтте.

**2023 елның 10 августында** Казан шәһәренең 183 нче гимназиясендә Татарстан Республикасы педагогик хезмәткәрләре август киңәшмәсенең «Яңартылган федераль дәүләт белем бирү стандартларын гамәлгә ашыру шартларында туган телләрне укытуның методик аспектлары» темасына милли мәгариф секциясе утырышы оештырылды. Чарада республика мәгариф һәм фән оешмаларының эш тәҗрибәсе тәкъдим ителде, 2022/2023 уку елына нәтиҗәләр ясалды, яңа уку елына максат һәм бурычлар билгеләнде.

**2023 елның 16 августында** Казанда Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов катнашында «Татарстан Республикасы мәгарифе: төп бурычлар, әхлакый ориентирлар, сыйфатлы күрсәткечләр» темасына мәгариф һәм фән хезмәткәрләренең традицион республика август киңәшмәсе узды. Киңәшмәдә Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, Мәскәү мэрының Мәскәү Хөкүмәтендә социаль үсеш мәсьәләләре буенча урынбасары Анастасия Ракова, Россия Дәүләт Думасы һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары, югары уку йортлары ректорлары, мәгариф оешмалары хезмәткәрләре, укытучылар

катнашты. Киңәшмәдә узган уку елында эшчәнлек нәтиҗәләре анализланды һәм 2023/2024 уку елына бурычлар билгеләнде, мәгариф һәм фән хезмәткәрләре дәүләт һәм тармак бүләкләре белән бүләкләнде.

**2023 елның 16 августында** Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әдәбият белеме бүлеге мөдире, филология фәннәре докторы Әлфәт Закирҗанов татар халкының телен, мәдәниятен үстерүгә һәм саклауга зур өлеш кертүе өчен «Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе» дигән мактаулы исемгә лаек булды. Әлеге югары бүләкне аңа Казанда «Бәшир Рәмиев исемендәге IT-парк» югары технологияләр өлкәсендәге технопаркта узган мәгариф һәм фән хезмәткәрләренең традицион август киңәшмәсендә Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов тапшырды.

Әлфәт Мәгъсүмҗан улы Закирҗановны әлеге мәртәбәле бүләк белән чын күңелдән котлыйбыз һәм алга таба да аңа иҗади уңышлар, ныклы сәламәтлек һәм иминлек телибез!

**2023 елның 16–23 августында** XVI Бөтенроссия мөселман яшьләре форумы үткәрелде. Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтендә ачылып киткән чара бер атна дәвамында Болгар җирлегендә узды. Мөселманнар арасындагы хәйрия эшчәнлегенә багышланган җыенны Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте Ислам мәдәнияте, фәне һәм мәгарифенә ярдәм күрсәтү фонды белән берлектә оештырды. Чарада Индонезия, Мисыр, Кыргызстан, Үзбәкстан, Таҗикстан, Кырым, Башкортстан, Кабарда-Балкар (Нальчик), Чувашстан һәм Татарстан республикалары, Пермь крае, Мәскәү, Әстерхан, Владикавказ, Свердловск өлкәләре, Ижау, Йошкар-Ола, Самара һәм Ханты-Мансийск шәһәрләреннән 18–30 яшьлек 130 мөселман катнашты. Форум программасына дини юнәлештә белем бирү чаралары, фәнни-танып белү өчен лекцияләр, тренинглар, мастер-класслар һәм практикумнар, TED һәм диспутлар, квестлар һәм экскурсияләр кертелгән иде.

**2023 елның 16 августында** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе тарафыннан мәгариф һәм фән хезмәткәрләренең республика август киңәшмәсе пленар утырышының панель күргәзмәсе кысаларында тәкъдим ителгән презентациядә Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты эшчәнлегенә киң чагылыш тапты. Чарада катнашучылар ТӘһСИ галимнәре тарафыннан татар теле һәм әдәбияты буенча эшләнгән яңа программалар, дәреслекләр, татар филологиясе өлкәсендәге электрон проектлар, аерым алганда, сүзлекләрнең электрон фонды белән таныштылар. Киңәшмә кысаларында панель күргәзмәдә тәкъдим ителгән экспозицияләр Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов тарафыннан югары бәяләнде.

**2023 елның 17 августында** Казан шәһәренең «Мир» кинотеатрында Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артисты Әзһәр Шакировка багышлап төшерелгән «Җылак» фильмын тәкъдим иттеләр. Нәфис фильмның режиссеры – Алмаз Нургалиев. Фильмда артистның язмышы, иҗади тормышы чагылдырыла. Премьерага татар зыялылары, артистлары һәм журналистлар килгән иде.

**2023 елның 18 августында** филология фәннәре докторы, профессор, Татарстан Фәннәр академиясе академигы, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе, Татарстан Республикасының фән һәм техника өлкәсендәге дәүләт премиясе лауреаты, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының 1986–2000 еллардагы директоры Мирфатих Зәки улы Зәкиев (1928–2023) вафат булды. Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнең балаларының һәм туганнарының тирән кайгысын уртаклашты.

Галим Казанның Мамадыш трактындагы Мөселман зиратында җирләнде.

**2023 елның 19 августыннан 30 августка кадәр** Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының комплекслы фәнни экспедициясе Кемерово өлкәсендә эшләде. Тикшеренүләр төбәкнең Юрга, Яшкино, Ижморский һәм Тисуль районнарында алып барылды. Экспедиция эшендә төрле юнәлештәге галимнәр катнашты: төркем җитәкчесе, филология фәннәре докторы Олег Хисамов – авыллар тарихын, топонимиясен һәм диалектларны, филология фәннәре докторы Илсөяр Закирова – халык авыз иҗатын, филология фәннәре кандидаты Алинә Хөсәинова өлкә татарларының сөйләм үзенчәлекләрен тикшерде, сәнгать белеме кандидаты Наталья Герасимова – урындагы халыкның декоратив-гамәли сәнгатен, атказанган мәдәният хезмәткәре Гөлназ Гыйлемҗанова җыр һәм бию үрнәкләрен өйрәнде. Моннан тыш, сакланып калган борынгы китаплар һәм кулъязмаларны өйрәнү буенча эш алып барылды. Экспедицияләр вакытында җыелган материаллар Институтның Язма мирас үзәге фондларын тулыландыра, «Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән» сериясе җыентыкларында басылып килә, монографияләр язганда файдаланыла. Галимнәрнең Кемерово өлкәсендәге эш нәтиҗәләре буенча да махсус җыентык әзерләп бастыру күздә тотыла.

**2023 елның 22 августында** Горький исемендәге Үзәк мәдәният һәм ял паркында Казан мэриясенең «Древо жизни» («Байтирәк») мәгърифәти проектының дүртенче йомгаклау чарасы үтте. Биредә Татарстанның 7 төп җирле халык вәкилләре катнашты. Казан мэриясе һәм Татарстан халыклары ассамблеясе тарафыннан Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы

татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе ярдәме белән 2022 елдан бирле гамәлгә ашырылучы әлеге проектның төп максаты – Идел буе халыкларының туган телләрен һәм традицион мәдәниятен саклау һәм популярлаштыру. Проектның фәнни җитәкчесе – Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Ф.Х. Җәүһәрова. Төрле халыклар мәдәниятенә багышланган быелгы чаралар июль һәм август айларында узды, бәйрәмгә килгән кунаклар татар, рус, чуваш, башкорт, мари, удмурт, мордва халыкларының традицион мәдәнияте белән танышты.

**2023 елның 24 августында** «Казан ярминкәсе» күргәзмә үзәгенең тарихи паркында «Россия – минем тарихым. Татарлар Ватанга хезмәттә» күргәзмәсен ачылды. Татарстан Республикасы көненә багышланган әлеге экспозиция дәүләт хезмәтендә, фәлсәфә һәм иҗтимагый фикер, әдәбият өлкәсендә зур уңышларга ирешкән татар морзалары нәселләренең танылган вәкилләре белән таныштыра. Проект Бөтендөнья татар конгрессы, Татарстан Республикасы дәүләт архивы, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты, ТР ФАнең башка институтлары тарафыннан Татарстан Республикасы Хөкүмәте патронажы астында гамәлгә ашырылды.

**2023 елның 29 августында** Казан Кремлендә «Казан Идел буе: халык мәдәнияте образлары» күргәзмәсе ачылды. Әлеге вакыйга кысаларында XIX–XX гасырларда Идел буе халыкларының традицион костюмын торгызу буенча тарихи-этнографик проектның нәтиҗәләренә йомгак ясалды. Тантаналы чарада Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты хезмәткәрләре, әлеге проектның фәнни консультантлары – Сәнгать белеме үзәге мөдире, сәнгать фәннәре докторы Рауза Солтанова һәм шул ук үзәкнең өлкән фәнни хезмәткәре, сәнгать белеме кандидаты Людмила Шкляева, матди мирасны өйрәнүгә һәм саклауга зур өлеш керткән өчен, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының Рәхмәт хаты белән бүләкләнделәр.

**2023 елның 30 августында** Республика көне уңаеннан Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры каршында «Уйнагыз, гармуннар!» XXXVIII Республика халык иҗаты фестивале узды. Әлеге бәйрәмдә 30 лап өлкәдән 700 гармунчы катнашты. Чарада катнашучыларны Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессы Милли Шурасы рәисе Васил Шәйхразыев сәламләде.

**2023 елның 1 сентябрендә** «Казан Кремле» Дәүләт тарихи-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгында элеккеге Спас-Преображенский монастыренда, «НАУКА крупным планом» дип

аталган фәнни-популяр күргәзмә узды. Күргәзмәне оештыручы – Казан (Идел буе) федераль университеты һәм «Казан Кремле» музей-тыюлыгы. Стендларда стратегик академик лидерлык «Приоритет – 2030» программасын тормышка ашыру кысаларында Казан (Идел буе) федераль университеты галимнәре башкарган эш нәтиҗәләре тәкъдим ителде.

**2023 елның 5 сентябрендә** Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында XIX Казан халыкара мөселман киносы фестиваленең ачылу тантанасы үтте. Чарада Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессы Милли Шурасы рәисе Васил Шәйхразыев чыгыш ясады. Ул фестиваль кунакларын сәламләде һәм Татарстанның, Россиядәге алдынгы төбәкләрнең берсе буларак, иҗтимагый тормышка кагылышлы күп темаларны, шул исәптән ислам мәсьәләләрен күтәрүен искәртте, 2022 елда Идел буе Болгарында ислам дине кабул ителүгә 1100 ел тулуга багышланган зур тантаналар узуын да искә төшереп үтте.

**2023 елның 7–8 сентябрендә** «Казан-Экспо» халыкара күргәзмә үзәгендә Россиядәге беренче зур «РОСТКИ» халыкара форумы булып узды. Форумда өч меңнән артык кеше, шул исәптән Кытай провинцияләреннән (Шаньдун, Хунань, Сычуань, Аньхой, Хэйлунцзян, Чжэцзян, Чунцин) килгән кунаклар да катнашты, алар белән Татарстанның төбәкара хөкүмәтара килешүләре имзаланды. Халыкара форум катнашучыларга тәҗрибә уртаклашу, элемтәләрне киңәйтү һәм Россия белән Кытай арасында төрле өлкәләрдә хезмәттәшлекне үстерү мөмкинлеге бирде. Форум кысаларында IT, машина төзелеше, нефть химиясе, транспорт, туризм, мәдәният, сәламәтлек саклау, спорт, мәгариф, инвестицияләр, яшьләр фестивале, шулай ук шәһәрләрне берләштерүче форум һәм башка юнәлешләр буенча 40 тан артык эшлекле сессия уздырылды.

**2023 елның 18 сентябрендә** Казан федераль университетының Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында галим һәм җәмәгать эшлеклесе, Татарстан фәннәр академиясе академигы, филология фәннәре докторы Рүзәл Йосыповның 85 яшьлек юбилей кичәсе үтте. Чарада академикның шәкертләре, хезмәттәшләре, якыннары катнашты.

**2023 елның 18 сентябреннән 27 сентябрьгә кадәр** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының комплекслы фәнни экспедициясе Татарстанның Ютазы районында эшләде. Экспедиция җитәкчесе – филология фәннәре докторы, халык иҗаты бүлегенең әйдәп баручы фәнни хезмәткәре, фольклор белгече Ләйлә Дәүләтшина. Составында филология фәннәре докторы, халык иҗаты бүлегенең баш фәнни хезмәткәре Лилия Мөхәммәтҗанова (фольклор), Сәнгать

белеме үзәге фәнни хезмәткәре, сәнгать фәннәре кандидаты Дәүләт Умеров (халык биюләре һәм музыкасы), Сәнгать белеме үзәге фәнни хезмәткәре Айгөл Җәләлиева (халык һөнәрләре), ареаль лингвистика бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре, филология фәннәре кандидаты Әлфия Булатова (сөйләм үзенчәлекләре), Язма мирас үзәге фәнни хезмәткәрләре Айгөл Хәсәнова (иске язулы кульъязмалар һәм басма китаплар) һәм Венер Усманов (эпиграфика) Ютазы районына караган татар авылларында комплекслы эш алып бардылар. Кыр тикшеренүләре барышында галимнәр татар халкының милли-мәдәни мирасын өйрәнделәр, аның авыз иҗаты, теле, сәнгате, музыкасы, археографиясе, эпиграфикасы, шулай ук традицион мәдәнияте буенча материал тупладылар.

**2023 елның 20 сентябрендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәгенә Якын Көнчыгыш һәм Көньяк Азиядән Коръән белгечләре, текстологлар, археографлар һәм каллиграфларның зур делегациясе килде. Мирасханәдә саклана торган Көнчыгыш кульъязмалары һәм иске басмалары коллекциясе төрле илләрдән килгән тикшеренүчеләрдә зур кызыксыну уята. Әлеге визит «Россия – Ислам дөньясы» стратегик күзаллау төркеме чаралары эгидасы астында уза торган «Изге Коръән хезмәтендә технологияләр: каләмнән алып компьютерга кадәр» IX Халыкара ислам дини конференциясе эше кысаларында оештырылды. Галимнәрне «Мирасханә» үзәге хезмәткәре Н.Г. Гәрәева Идел буе территориясендә кульъязма һәйкәлләрнең барлыкка килү тарихы белән таныштырды. Үзәк кунаклары тәкъдим ителгән документларның кульъязма һәм кәгазь үзенчәлекләре һ.б. белән бәйле файдалы киңәшләр бирделәр. Әлеге киңәшләр документларның барлыкка килү урынын һәм вакытын төгәлрәк билгеләргә мөмкинлек бирә.

**2023 елның 21 сентябрендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтында «Татарстан Республикасының эпиграфик мирасы: саклау һәм өйрәнү проблемалары» темасына түгәрәк өстәл узды. Чарада галимнәр, дәүләт хакимияте органнары вәкилләре, мөселман руханилары, экскурсоводлар һәм киң җәмәгатьчелек вәкилләре катнашты.

**2023 елның 22 сентябрендә** Габдулла Тукайның Казандагы әдәби музеенда күренекле фән эшлеклесе, әдәбият галиме, текстолог Зөфәр Рәмиевкә 85 яшь тулуга багышланган «Олы галим, зыялы шәхес» дип исемләнгән әдәби чара узды. Чараны оештыручылар – Габдулла Тукайның Казандагы әдәби музее һәм Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты. Кичәдә галимнең фикердәшләре, бергә эшләгән хезмәттәшләре, шәкертләре катнашты, шулай ук әдә-

бият тәнкыйтьчеләре, артистлар чыгыш ясады.

**2023 елның 20–22 сентябрендә** Казанда «Казан-Экспо» халыкара күргәзмә үзәгендә Kazan Digital Week – 2023 халыкара форумы узды. Чара кысаларында югары технологияле эшләнмәләр, программа тәэминаты, программа-аппарат комплекслары, техника һәм җиһазларның гамәлдәге үрнәкләре күргәзмәсе оештырылды. Катнашучылар интеллектуаль транспорт системалары, яңа заман кибер куркынычсызлыгы, дәүләт идарәсендә цифрлы технологияләр, мәгариф, мәдәният, медицина, авыл хуҗалыгы һәм башка темалар турында фикер алышты. Дискуссияләр офлайн һәм онлайн форматта узды. Форумны Россиянең Цифрлы үсеш, элемтә һәм массакүләм коммуникацияләр министрлыгы һәм Татарстан Хөкүмәте оештырды.

**2023 елның 27 сентябрендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Иран Ислам Республикасының Азад ислам университетының вәкиллекле делегациясен кабул итте. Азад ислам университеты – штаб-фатиры Тәһранда урнашкан шәхси Университет системасы, аңа 1982 елда нигез салынган. Ул зурлыгы буенча дөньядагы зур комплекслы университетлар арасында алтынчы урында тора, анда 1 миллионнан артык студент белем ала.

Азад ислам университеты вәкилләре белән эшлекле очрашуда Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты Р.Н. Миңнеханов, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе вице-президентлары А.Л. Абдуллин, А.Ә. Тимерханов, В.В. Хоменко, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры К.М. Миңнуллин, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты директоры Р.Р. Салихов һәм Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе академигы Ә.М. Мазһаров катнашты.

Очрашу барышында Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе һәм Иранның Азад ислам университетының эш тәҗрибәсе, социаль-икътисади һәм гуманитар өлкәләрдәге уртак фәнни мәсьәләләр турында сүз барды, хезмәттәшлек турында килешү төзү турында карар кабул ителде.

**2023 елның 29 сентябрендә** Г. Тукайның Казандагы әдәби музеенда «Тукай – Санкт-Петербургта» Бөтенроссия арт-пленэры вакытында иҗат ителгән әсәрләр күргәзмәсе ачылды. Әлеге чара агымдагы елның июнь аенда ТӘһСИнең Сәнгать белеме үзәге тарафыннан оештырылган иде.

Күргәзмәнең ачылыш тантанасын проектның кураторы, Сәнгать белеме үзәге җитәкчесе, сәнгать фәннәре докторы Рауза Солтанова алып барды. Тамашачылар һәм кунаклар алдында сәламләү сүзе белән Г. Тукайның Казандагы әдәби музее директоры Гүзәл Фәрдинова чыгыш ясады. Күргәзмә турында үз тәэсирләре белән Татарстан Республикасы

Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының чагыштырма татар белеме лабораториясе мөдире, филология фәннәре кандидаты Марсель Ибраһимов, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Ислам тикшеренүләре үзәге өлкән фәнни хезмәткәре, тарих фәннәре докторы Илдус Заһидуллин, филология фәннәре докторы Зөфәр Рәмиев уртаклашты. Арт-пленэрда катнашучылар үзләренең әсәрләре, бирелгән теманы ачу үзенчәлекләре турында сөйләделәр.

Күргәзмәдә 2023 елның 20–30 июнендә Санкт-Петербург шәһәрендә узган арт-пленэр вакытында Татарстанның профессиональ рәссамнары тарафыннан төрле жанрларда (тематик картина, пейзаж, портрет, натюрморт) иҗат ителгән 50 дән артык картина һәм графика әсәре тәкъдим ителгән, шулай ук арт-пленэр барышы белән видео аша да танышу мөмкинлеге тудырылган. Санкт-Петербургта Р.Р. Солтанова тарафыннан язылган аутентик тавышларны кулланып эшләнгән «Петербург – XX гасыр башында» тавыш инсталляциясе шәһәр атмосферасын тулырак тоярга мөмкинлек бирә (режиссёры – П.М. Иванов).

Күргәзмә 2023 елның 28 ноябренә кадәр эшләячәк.

***Мөхтәрәм авторлар!***

«Фәнни Татарстан» журналы татар теле, әдәбияты, тарихы, сәнгате һәм иҗтимагый-фәлсәфи фикере темаларын яктырткан мәкаләләрне бастырып, киң җәмәгатьчелеккә таратуны күздә тота.

Материалларга түбәндәге таләпләр куела:

Мәкалә тексты *.doc форматында җыела, аерым хезмәтләрдән алынган өзекләр, сылтамалар автор тарафыннан җентекләп тикшерелә. Файл автор фамилиясе белән исемләнә (Әхмәтов. doc).

Мәкаләгә түбәндәге мәгълүматлар өстәлә:

– авторның фамилиясе, инициаллары
– мәкалә исеме (татар һәм рус телендә)
– аннотация (рус һәм инглиз телендә)
– төп сүзләр (рус һәм инглиз телендә)
– сылтамалар.

Мәкаләдән тыш, *.doc форматында аерым файлда автор турында мәгълүмат җибәрелә (исеме, әтисенең исеме, фамилиясе, гыйльми дәрәҗәсе, эш урыны, вазифасы, электрон адресы һәм телефоны).

Сылтамалар текст азагында ГОСТ Р 7.0.5-2008 таләп иткәнчә алфавит тәртибендә урнаштырыла.

Мәкалә белән бергә аңа карата фән докторы яки фән кандидаты тарафыннан язылган рецензия җибәрелә.

Редакциягә килгән мәкаләләр шулай ук бәйсез рецензияләүгә тәкъдим ителә, мәкаләне басмага алу-алмау аның нәтиҗәсеннән чыгып билгеләнә.

Редакция адресы:
420111, Казан шәһ., К. Маркс ур., 12, 1 нче кат, 10 нчы бүлмә
«Фәнни Татарстан» журналы редакциясе
Тел. (843) 590-55-93
E-mail: f_tatarstan@mail.ru

*Уңышлар теләп һәм Сезнең белән хезмәттәшлек итүебезгә өмет баглап,*
*«Фәнни Татарстан» журналы редакциясе*

Научное издание

**НАУЧНЫЙ ТАТАРСТАН**

На татарском языке

Фәнни басма

**ФӘННИ ТАТАРСТАН**

2023. № 3

Бизәлеш авторы – А. Шляпкин
Компьютерда биткә салучы – Н. Абдуллина

Басарга кул куелды: 29.09.2023. Басылды: 16.10.2023.
Офсет кәгазе. Кәгазь форматы 70×108 1/16.
Гарнитура «Times».
Басма табак 12. Тираж 300 данә. Заказ

Журнал ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында әзерләнде

Редакция адресы:
420111, Казан шәһ., К. Маркс ур., 12
«Фәнни Татарстан» журналы редакциясе
Тел. (843) 590-55-93
E-mail: f_tatarstan@mail.ru

Журнал Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшриятында басылды
(нәшрият адресы – 420111, Казан шәһ., Бауман ур., 20)

Журнал бушлай таратыла